Рашат Низами
Тормыш трамвае

*Шигырьләр, поэма*
КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)–5
Н 55

**Низами Рашат**

Тормыш трамвае: Шигырьләр, поэма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. — 238 б.
Рашат Низаминың яңа китабына моңа кадәр дөнья күргән шигырьләре белән бергә соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре, «Ике мөһаҗир» дип исемләнгән сәяси поэмасы урын алды.

ISBN 5–298–04068–3
©Татарстан китап нәшрияты, 2005

ЭНҖЕ БӨРТЕКЛӘРЕН ЭЗЛӘГӘНДӘ

Очрашулар вакытында безгә еш кына бер үк сорауны ишетергә туры килә: шигырьләр ничек һәм ни өчен языла?

Һич кенә дә аптыраганнан, эч пошканнан түгел, шигырьләр фәкать күңел сызланудан языла! Гамь уйлата, әйтер сүзең ашыктырып-сагынып көтеп тора сине. Иҗат эше, асылда, дөньяны һәм үз-үзеңне танып белүнең хикмәтле бер төре.

Кеше күңеле — дәрья, диләр. Чыннан да, анда нинди генә тетрәнүләр, кичерешләр, мәхәббәт фасыллары, хакыйкатьне аңларга тырышу мизгелләре булмаска мөмкин.

Кыскасы, һәммәбезнең дөньяны, тормышны үзенчә танып беләсе, хакыйкатьнең бер генә бөртек энҗесен булса да замандашларга җиткерәсе килә. Шигырь яисә чәчмә әсәрләр язу, иҗатка омтылыш — менә шуның бер чагылышы булса кирәк.

Үзебез яшәгән җәмгыятькә игелек эшләргә уйласак, туган телебезне, милли мәдәниятне һәм татарлыгыбызны саклап калырга теләсәк, бу эшкә олысыннан алып кечесенә кадәр үз өлешен кертергә бурычлы. Берәүләр — дәүләт урамын, икенчеләр гавам урамын чиста тотканда гына, без алга таба бара алачакбыз. Монда инде зур әдәп, әхлак, батырлык һәм тормыш тәҗрибәсе сорала. Ходай кушып, безнең моңа көчебез җитсә иде.

Төрле кешедә төрле холык бит. Трибуналарда, митингларда әйтеп булмаганны кайчак шигырьдә шәбрәк һәм үтемлерәк итеп әйтеп була. Шигырь ул — үз-үзең белән сөйләшү генә түгел, дусларың яки дус булмаганнар белән дә бәхәсләшү, уй-хисләрнең кайнар тупланышы. Шигырь ул — тормыш өчен, яшәү өчен, дөнья матурлыгы өчен көрәш...

Укучым! Менә шундый уй-фикерләр, теләкләр белән мин тагын юлга чыктым.

*28 декабрь, 2002*
*Автор*

# Тормыш трамвае

## *Шигырьләр*

ТОРМЫШ ТРАМВАЕ

*Барган шәпкә сикердем дә мендем,*
*Үз-үземә урын барладым.*
*Кеше икән — ул белергә тиеш*
*Кая таба үзенең барганын.*

*Әй җилдерә тормыш трамвае!*

*Көннәр, еллар кала сибелеп.*
*Яшьнәп яшәр өчен — бу тормышта*
*Гашыйк булу кирәк иң элек.*

*Тукталышлар күтеп тора безне*
*Туктап-туктап уйлап алырга.*
*Баш иясең яки дөреслеккә,*
*Яки инде дөнья малына.*

*Биеклектә калыр өчен кеше*
*Күтәрелеп менә түбәннән.*
*Бу сәфәрнең хакы әллә кайчан*
*Әнкәң каны белән түләнгән.*

*Зурлыгына, акылына карап*
*Или язмыш адәм баласын.*
*Коры кибәк булсаң, эшләр харап:*
*Җил уңайга төшеп каласың.*

*Семафорда утлар җемелдәшә...*
*Таңнан алып таңга кадәри*
*Вакыт рельслары буйлап әнә*
*Тормыш трамвае тәгәри.*

*Күкрәк белән ерып бара КЕШЕ,*
*Этеп бара еллар киртәсен.*
*Сизми ләкин... соңгы тукталышка*
*Кайчан, ничек килеп җитәсен.*

## КОЯШКА ТАБА

Уйсыз-гамьсез малай булып
Тәгәрәдем чирәмдә.
Чук канатлы күбәләкләр
Уйнап очты тирәмдә.

Йөгердем таңнар каршына
Кочар өчен кояшны.
Хыялый садә җаныма
КОЯШ әллә сыймасмы?!

Сукмакларым алып китте
Борма-борма юлларга.
Еларга кушмады яшьлек,
Кушты бары җырларга!

Хисләрдә алдашмаска дип,
Сүз бирдем өлкәннәргә.
Вакыт әнә заман җилен
Тутырды җилкәннәргә.

Корабым диңгезгә таба
Кузгалып китте минем...
Күзләрем күлеп торса да,
Сүзләрем җитди минем.

## ЯЛГЫЗЛЫК

Иң якты бер йолдыз идең
Күгемдә күңелемнең.
Метеор кук атылдың да

Яктылык чәчеп сүндең.

Зәңгәр күлгә төштең микән
Юарга сагышларың?
Ишетәм ялгыз аккошның
Моңайган тавышларын.

Өй түремдә каеннарым
Сары сагыш бөркәнде.
Диңгезләрдән эзлим сине,
Җил каера җилкәнне.

## ПОЛИГОНДА

Хыяллана чәчәк: эх шушында
Үстерергә гөлләр диңгезе!
Яраларын каплап, бәйләп куйсак,
Булыр әле, Җирне тергезеп...

Шартлау булган җирдә хәят йоклый,
Чикерткәләрнең дә җыры тынган.
Берьялгызы үскән мәгърур чәчәк
Яңгыр көтә тузан болытыннан.

Кай тарафтан килә юлларыгыз? —
Ул тынычлык сорый җилләрдән.
Гүя җирнең миллион чәчәкләре
Илче итеп аны җибәргән.

## ТОЛЫМНАР

Син яңадан кайттың күңелемә,
Күзләреңдә — шомырт төсе исән.
Сүзләреңдә — сөю, сагыну назы,
Толымыңнан иркәләргә дисәм...

Сискәнәм дә тынып калам кинәт,
Ах бу җансыз кайчы, нишләгән!
Тәүге мәхәббәтем гөлен кискән —
Синең толымнарны кисмәгән!

Башын игән топольләргә карыйм,
Аларга да сагыну моңы тулган.
Мин бит сине элеккечә итеп
Иркәләргә телим толымыңнан!

Йөрәгемне кысып ала хәтер,
Газапланам,
                    янам,
                    кулым бармый...
Элеккечә сөя белү өчен
Кайтарыгыз миңа,
Кайтарыгыз ташкын толымнарны!

## ЧИТ ҖИРДӘ

Яңгыр суы туфрак юа,
Чыклы үлән тамчы коя.
Чит туфрак бу, чит үләннәр —
Кире кайтмый шул үлгәннәр.

Окоптагы табан эзе —
Әйтерсең лә соңгы сүзе...
Йөрәктәге кайнар уттан
Ядрә эреп юкка чыккан.

Көтә илдә гел бер ана,
Ә кабердә йолдыз яна.
Язлар аңа туган җирдән
Кызыл гөлләр алып килгән.

## БУРАН

Гайрәт чәчеп, дулап йөри буран,
Алмакчы ул мине якадан.
Хәл җыя да абзар ышыгында,
Томырылып чаба яңадан.

Сузыла да җитез бүре сыман,
Сикерә дә уза койманы.
Рәшәткәләр арасына сыйды,
Урамнарга менә сыймады!

Дулкын булып актарыл син, буран,
Киңлекләрне әле табарсың...
Күпме генә карлар ташысаң да,
Язлар каршысына чабасың.

## САБАНТУЙДАН МОҢСУ КҮРЕНЕШ

Оча малай — аерылган җирдән,
Сары чәчләренә җил тула.
Бәйгеләрдә чапкан атларда да
Бер-берсеннән көнләү зур була.

Каерылып очты, очты толпар,
Канатларын җәйгән лачын күк.
Таш ватылды тояк асларында...
Уйнаклады камчы — яшен күк.

Каерылып бер сикерү җитә —
Басу капкасына керәчәк!
...Шатлыкларны кайчак йөзтүбәнгә
Әйләндереп каплый күрәчәк.

Тилергән кан сукты йөрәгенә,
Йөрәгенә сукты толпарның.
Чәрдәкләде нидер мускулларын,
Бер мизгелгә дөнья тын калды.

Ә аннан соң берсен-берсе куып
Әйләнеште, ауды барчасы, —
Ак сөлгеле бирнә колгалары,
Баганалар, басу капкасы.

Офыктагы кешнәү кайтавазын
Йөрәгенә кысты бер болыт.
Зәңгәрлектә очкан тоякларның

Рәшәсе калды җыр булып.

## МӘРСИЯ

*Күршем Әхмәтвәлигә*

Яңа кабер... Гүя авыртудан
Нәни сөял чыккан җиремә.
Гасырларны кичкән карт имән дә
Йөзен чыткан төсле күренә.

Тез башларын җиргә салган берәү,
Кабер аны тота, җибәрми.
Туфрак белән чәче аралашкан...
Үзе һаман улын битәрли:

— Үз-үзеңә ничек кул салгансың —
Егалырлык малай диюне?..
Чегән төсле кара бер кыз, имеш,
Кире каккан синең сөюне.

Сөюдән үч алып буламы соң,
Их, син, көчсез, их, син, юләрем!
Тормыш көтте кеше булуыңны —
Шулмы инде синең түләвең?

Тәмуг дигәннәре дөрес икән,
Шунда кертер сине Алласы...
Исән чагың булса менә хәзер —
Тотып кыйнар идем, валлаһи!

Орышсам да, яратам бит сине,
Ни әйтсәң дә инде, үз балам...
Яшьлегеңә ачу саклап йөрим,
Тик үзеңне, улым,
Тик үзеңне менә кызганам!

## СИНЕҢ ГАРМУНЫҢ

Сабагыннан өзеп алсаң,
Сүнә чәчәк, көлми шул.
Исәннәрнең хаты килә,
Үлгәннәрнең килми шул.

*Әткәй дәфтәреннән*

Каеннардан йокы качты хәзер,
Җырларыңны сагына ак каен!
Кич җиттеме, авыл урамыннан
Эзләп йөри җырчы малаен.

Өстәлдәге ак төймәле баян —
Синең төсең, синең истәлек.
Телләренә барып кагылдыңмы,
Сагыну гына тора өстәлеп.

Без һаман да шулай — бәйрәм җитсә,
Өстәлләрдә тора шешәбез.
Шатлыгын да, кайгысын да шулай
Бер савытка салып эчәбез.

Без һаман да шулай — яшь егетләр
Урамнарны кичен урыйбыз.
Йоклап яткан авыл карчыкларын

Уятып ла кала җырыбыз.

Без һаман да шулай — никрутларны
Озатабыз җырлап авылдан...
Сыгылып-сыгылып нидер сөйли гармун,
Хуҗасынмы шулай сагынган?

Мин хәтерлим әле ул хәбәрне,
Кәрнизләргә ятып җил йөрде...
Без — кешеләр — тумыштан ук сабыр,
Тик гармуның менә,
Тик гармуның... шашты, тилерде!

## ТАЙЛАР

Шаулый буран...
Җигелмәгән тайлар
Беренче кат керә тәртәгә,
Каеш дилбегәнең кытыклавы
Булмас әле соңгы мәртәбә.

Йә, кузгалыйк канатлы кош сыман,
Барасы юл булсын бик ерак!
Мускул тамырлары тартылган соң
Скрипка кыллары сымак...

Ташып төшкән көмеш ялларына
Ап-ак буран килеп уралды.
Шушы тайлар тартып бара кебек
Сихерләнеп чапкан буранны.

...Ыргып-ыргып чапкан тайларның да
Дәрманнары тиздән басыла.
Бураннар да, чабып арганнан соң,
Ятып кала ачык басуда.

Ә без менә — мәңге юлаучылар,
Иманыбыз китми тайпылып.
Дилбегәләр шартлап өзелгәнче,
Әй чабабыз ярсу тай кебек.

## ҮЗ БИЗӘГЕ АНЫҢ...

Чорма түгел, иске бер музейның
Басып торам кебек залында.
Кызык итеп хәтеремә алам
Шүрләвемне сабый чагында.

Шүрәленең мөгезе дигәннәрем
Сыңар теше булган тырманың...
Үз бизәге, төсе, үз дөньясы
Бар икән бит безнең чорманың.

Сер сөйләр күк миңа бабакайның
Чабатасы, тула оегы.
Ут сораптыр, ахры, бишле лампа
Бер почмакта тора боегып.

Агач табак олы бәхет булып
Кушылгандыр табын яменә.

Кычытканлы яшел шулпаларның
Төсе сеңеп калган тәненә.

Агач сука тимер куллар эзен
Тора икән әле гел саклап.
Шул бит инде коммун башланганда
Ызаннарны йөргән тураклап.

Әбекәйнең кул җылысын тоеп,
Урак сабын кысам учыма...
Тарих кадәр олы Тарихыңны
Ничек сыйдыралган бу чорма!

## ЗӘҢГӘР ШӘМ

Ай яктысын көнләштереп
Яна иде зәңгәр шәм.
Егет өчен ялкын теле —
Зәңгәр яулык, зәңгәр шәл.

Шәм яктысын кушып-кушып,
Шигырьләр язган егет,
Төнге тәрәзәдән карый,
Ай бүген — сынык өмет.

Йолдызларны көнләштереп
Никтер янмый зәңгәр шәм?..
Кыз онытылган. Тик офыкта
Зәңгәр яулык, зәңгәр шәл.

## ТОЛ ХАТЫН

Иңнәрне көянтә түгел,
Сагышлар баса кебек.
Бу карама көянтәсен
Ире ясады бөгеп...

Көянтәнең баш-башлары
Әйтерсең ике канат.
Шул канат, аудым дигәндә,
Саклады ничә кабат!

Җилләр исә, карлар күчә,
Гомер дә узып бара.
Көянтәнең чәчәкләре —
Бизәге тузып бара.

Тол хатынның иңнәренә
Тынгы бер дә булмады:
Суга барса — көянтәсе,
Төшкә керсә — куллары...

## КӨН УРТАСЫ

Үрли кояш, үрли һаман өскәре,
Кыскарадыр күләгәләр гаскәре.

Бал кортыдай син дә карап уз аны, —
Яфракларда бии чәчәк тузаны.

Рәшә җиле. Арыш исе. Кыр юлы.
Күпме башак сәлам бирә берьюлы!

Уйлый-уйлый көннәрнең алгысын,
Әй, дәртләнеп селти егет чалгысын.

Кыз балага сабырлыклар бирсәнә:
Күкрәгендә ике «кояш» тирбәлә!

## САБЫЙ ЧАКНЫҢ БЕР ИРТӘСЕ

Сабый чакның кышкы иртәсе,
Күңелдән юк шуның китәсе, —
Йоклап яткан җирдән тәнемә
Юрган аша җылы бәрелә.

Юрганымны ачам уянып:
Өйнең эче балкый нурланып.
Мондый чакта буламы йоклап,
Бер тәмле ис тора кытыклап —

Әнкәй мичтән ипи алган ич,
Ак җәймәгә тезеп салган ич!
Яңа пешкән икмәк исеннән
Гөлләремә кадәр исергән.

Бураннарга хәтле сөенгән —
Тәрәзәгә килеп сыенган!

## ӘЙ, ГАРМУНЫМ...

Өздер әле дәртле көйләреңне,
Әй, гармуным минем, гармуным!
Бер баетыйк әле күңелләрен
Җырга-моңга бераз ярлының.

Ничә тапкыр уздык бу юллардан,
Авыл урамнарын чыңлатып.
Бабайларны кайчак сагышлатып,
Әбиләрне кайчак елатып.

Безнең башка томырылган кайгы
Сине дә бит читләп узмады.
Кайгылардан кара көймәдек ич —
Җырлый гына идек без бары.

Тып-тын гына ләкин уза идек
Үзебезнең зират турыннан —
Егет чакның тыйнак законнары
Яшәп килә борын-борыннан.

...Өздер әле дәртле көйләреңне,
Әй, гармуным минем, гармуным!
Бер баетыйк әле күңелләрен
Җырга-моңга бераз ярлының.

Өздер әле яшьлек көйләренә,
Йөрәкләрне кызлар аңласын.
Бакчаларда — алма, зәңгәр күктә
Коелмаган йолдыз калмасын!

## ПАРАДОКС

Йөрим дисәң, зәңгәр юллар җитә,
Бушанырга дисәң — хыяллар.
Сокланырга җир төсләре җитә:
Җиде төскә дөнья буялган.

Сөйим дисәм, сылу кызлар җитә,
Биим дисәң, җитә мәйданнар.
Бер кирәксез хаталарым җитә,
Юкса әле мин ни майтарган?

Саныйм дисәң, йолдызлары җитә,
Багыйм дисәң — ае, кояшы.
Һәр почмагын җиткелекле итеп
Хәстәрләгән икән дөньясы.

Мин — оптимист.
Тик уйланам кайчак,
Күңелем көзгә керсә, нечкәрсә,
Соңгы мизгел урап алган чакта,
Җитми калыр миңа өч нәрсә:
Табаныма — бер уч туфрак,
Күкрәгемә — йотым һава,
Иренемә — бер тамчы су.

## ЧАГАН

Юл чатына төште орлык,
Үсеп чыкты яшь чаган.
Канат төрткән кош кебек, ул
Омтылды күккә табан.

Карлы-бозлы бураннарның
Килер әле ничәсе!
Күпме язны каршылыйсы,
Күпме җәйне кичәсе.

Күпме бөҗра ишәйтәсе,
Күпме яфрак коясы, —
Каршында тора чаганның
Башланмаган дөньясы...

Юл буеннан үтеп йөри
Җәяүлеләр, атлылар.
Чыбыркы сабына диеп
Яшь чаганны... чаптылар!

## ГОМЕР

Дөньяга килгәч тә кешене
(Ул әле җикмәгән пар атын)
Мендәргә салалар,
Баш белән
Көнчыгыш ягына каратып.

Дөньясын куйгач та кешене
(Ул инде тугарган пар атын)
Ләхеткә салалар,
Баш белән
Көнбатыш ягына каратып.

Көнчыгыш, көнбатыш арасы —
Кояшка бер көндә барасы!..

## ДИҢГЕЗДӘ

Инештәге бозлар
Агып китте ерак —
Диңгездә йөр менә:
Адашып һәм елап!..

«Монда дәрья, дәрья,
Юктыр иге-чиге,
Инешемнең яры
Иркенрәк иде.

Монда дөнья кысан,
Бозлар олы, эре:
Этә-төртә мине —
Йөзеп килгән бере...»

## ТЕЛСЕЗ

Яшисен яшәгән,
Ашыйсын ашаган...
Ә дөнья — тавышсыз аҗаган.

Күңел сак, күңел сак.
Күңелдә төрле чак...

Шатлыгың уралса җаныңа —
Эх, бер сүз!
Хәсрәтең тоз салса каныңа —
Эх, бер сүз!
Сүгенер чагыңда — бушанма,
Тешеңне кыс та түз,
Тавышның очмасын җиһанга...

Эх, бер сүз!..

## jjj

Була төрле: кәефле чак, кәефсез чак.
Бер үк җанга — йә татлы сүз, йә сүз-пычак.

Кайчакларда кыйналасың, үртәлә җан —
Яшәүләрдән ни мәгънә дә, безгә ни сан?

Бар өметем өзелдеме әллә дисәм,
Күңелдә нур — ышанычым-тәңрем исән!

Сатылма да, ватылма да, горур җаным,
Сынауларның иң зурысы — алда аның.

## ЕГЕТ

Йөгән үрә егет, йөгән үрә,
Үз иманы кушып, үз дене.
Ут эченә атылып кергәндә дә,
Өзелмәслек булсын тезгене.

Ияр тегә егет, ияр тегә,
Өзәнгеләр таза, нык булсын.
Аякларга терәк барда егет
Ничек иярennән егылсын!

Ат дагалый егет, ат дагалый,
Ташка бассаң — чыксын ялкыны.
Алып чыкса алып чыгар аны
Шушы аты еллар аркылы.

## КӨЗГЕ ПАНОРАМА

Урманнарда — алтын симфония!
Кыштыр-кыштыр... яфрак авазлары.
Яфракларның гомеренме саный —
Ялгыз бер кош дәшеп куя бары.

Кырлар буйлап ефәк җил йөгерә,
Тургайларның җыры тынып калган.
Камылларда яна пәрәвезләр,
Кояш нуры гүя сынып калган.

Баш очында — бала сыерчыклар,
Шундый тыгыз, куе сибелгәннәр!
Оча торган серле палас булып
Зәңгәр күккә гүя сибелгәннәр.

Түтәлләрдә тәгәрәшеп ята
Сентябрьнең соңгы кыярлары, —
Әйтерсең лә карт бер бакчачының
Онытылып калган хыяллары.

Сары яфрак — сары светофор...
Кешенең дә уйга талган чагы.
Керергәме-юкмы көзгә диеп,
Юл чатында туктап калган чагы.

## МУЗЕЙДА

Ни генә юк — таш энәдән алып
Чуен ядрә, тупка кадәрле!
Таш гасыр да, чуен гасыры да
Тарих өчен изге, кадерле.

Тып-тын тора сугыш байраклары,
(Байраклар да... әсир эләгә!)
Ерткаланып беткән... Диварларда
Үзе кебек ярты күләгә.

О, сугышлар булган заманында!
Ә музейда дөнья тып-тыныч...
Бишектәге сабый сыман ята
Яшен булып очкан бу кылыч.

Өнсез булып ята карт пушкалар,
Әйтерсең лә берни булмаган —
Стеналар күккә чөелмәгән,
Дошман башы гүргә чummаган...

Тып-тын тора сугыш байраклары,
Тып-тын ята сугыш алласы.
Бу ядрәләр гүя ботагыннан
Өзелеп төшкән сөю алмасы!

## «СЕБЕР ДӘФТӘРЕ» ЦИКЛЫННАН

### ТЕТРИ ТАЙГА

Я знаю — город будет!
*В.Маяковский*

I

Күчә тайга...
Төзелеш мәйданнары
Инде болын кадәр зурайган
Бер...
        Ике!..
                Өч!..
Калын тамырларны
Кисеп-кисеп керә субайлар.

Куе сазлык. Мондый сазлыкларга
Кешеме соң аяк басмаган!
Тирә-якта вакытлыча гына
Чыпырдашып ята басмалар.

Вакытлыча әле урам уты,
Каен баганалар тирәндә.
Табигатьнең керсез елмаюы —
Баганалар... яфрак җибәргән!

Шофер егет тешен кыскан әнә,
Сүгенүдән чак-чак тыелып,
Ачу белән педаленә баса:
— Кереп чумдык, брат, бу юлы!

Өстәп куя тагын:
— Ну, ничего,
Асфальт кына җитсен өлгереп,
Йөрисе бар әле бу юлларда
Яшен ташы кебек җилдереп!

II

Тракторлар юл тазартып йөри,
Ташларның да чыга ялкыны.
Бульдозерның батыр тавышлары
Тургай сыман күктә талпына!

Гөрли тайга...
Гөрли, көнләп түгел,
Бит сәгатьләп арта бизәге.
Әйтерсең лә шушы нәни тайга —
Җир кендеге, җирнең үзәге!

Нәкъ шушында, мәйдан уртасында,
Фонтан булыр, бәлки, кем белә —
Сварканың кайнар чаткылары —
Яңгыр булып күккә чөелә.

Берлин ташларына «автограф»
Язып йөргән кырыс бу агай
Тимер фәнен ай-һай яхшы белә,
Үзгә кеше үзе, сулагай.

Бу торбалар шәһәр йөрәгенең
Бер тамыры булып тибәчәк.
...Горизонтка Такташ күтәрелә:
«Һәрбер теләк — якын киләчәк!»

Һәр шәһәрнең була туган көне,
Хәерлегә тусын, яхшыга...
Тарих үзе ике куллап аңа
Туу таныклыгын тапшыра.

Көннәр — чаба...
Себер итәгендә
Мартеннары дөрли Уралның —
Сыңар күзле чая трамвайлар
Уртасына чыгар урамның.

Тайга йолдызларын көнләштереп,
Неон утлар монда кабыныр.
Шәһәр исә тәүге чатырларын
Ядкарь итеп кенә сагыныр.

Тормыш инде хыял чаптарларын
Куып җитте мәллә югыйсә? —
Болытларга горур башын чөеп,
Ай үсәсен шәһәр көн үсә.

Сөенегез, карта ясаучылар,
Тагын шатлык, тагын тантана!
Туып килгән яңа шәһәрчекне
Төшерәсез булыр картага...

jjj

Күктәге ак болыт сыман
Ил өстеннән гел агабыз.
Биштәр аскан малай килеш
Җир читенә олагабыз.

Берзаман кайтып авасың
Туган җирең кочагына...
Зәңгәр күген аның бизәп,
Карлыгачлар оча гына!

Аяклар нык тупасланган —
Чәнчемидер аны камыл.
Сүзсез калган ана кебек
Каршы ала сине авыл...

## ТОПОЛЬ

Ул да безнең кебек сабый бала:
Бер гөнаһсыз, керсез, хәйләсез.
Йөгерә дә төшә каршыбызга,
Толымнары яшел, ямь-яшел!

Шушы тополь мәхәббәтебезнең
Булсын, дидек, төсе, иманы.
Яшел һәйкәл, изге һәйкәл итеп
Саклап йөргән идек без аны.

Монда хәзер башка топольләрнең
Яфраклары җилдә сибелә.
Гаеплисем килми үткәннәрне,
Гаеплисем килми сине дә.

Якты булып калсын сөюебез,
Без бит чиста хисләр затыннан.
Ул көннәрне яратырга яки
Яратмаска синең хакың бар.

...Нигә андый тополь сайлаганбыз,
Еллар үткәч, кайтып карасам:
Каршы ала мине корыган тополь —
Безнең язмыш, безнең гарасат.

## СӨЮ АЛМАСЫ

Синең кулда алсу алма иде,
Түм-түгәрәк, пешкән кызарып.
Болындагы яшел тугайлыкта
Ял итәргә булдык без бары.

Яп-якты ай болыт асларыннан
Йөзеп чыкты безнең каршыга.
Ике битең — пешкән алма кебек,
Бер алмага карыйм, бер сиңа.

Мәхәббәтнең утлы учагыннан
Йөрәкләргә ялкын сикерде!
Иреннәрдә — яшел печән тәме...
Шушы көннән
Без олгаеп киттек шикелле.

Синең кулда алсу алма иде,
Орлыкларын җилгә ташладык.
Шул алманы болын кочагында
Урталайга бүлеп ашадык.

## КИЧ

Ашыкмый һәм кабаланмый гына
Кичке тынлык килә бу турга, —
Авыл карты капка кырындагы
Бүрәнәгә чыгып утырган.

Китеп бара менә түгәрәк көн,
Мәшәкатен төяп сыртына.
Моңсу уйлар чорнап ала хисне —
Әйтерсең лә матур җыр тына.

Көтү кайткан, урам тынган инде,
Көн кызуы беткән сүрелеп.

Рәшәткәгә кунган коры тузан
Болытларга карый үрелеп.

Вакыт белән тарткалаша кояш,
Таулар түбәсенә таянып.
Шушы җирне ташлап китү аңа
Аянычтыр, ахры, аяныч!

Җиле качкан, өрми этләре дә,
Уйга баткан чагы дөньяның.
Топольләргә хәтле тынып калган,
Карт философ кебек уйланып.

Ага гомер салмак дәрья сыман,
Ага гомер — булмый туктатып.
Рәшәткәле йортның түбәсенә
Сусыл алма коела тып та тып...

jjj

Күзләрем аера төсләрне:
Каеннар тарата яктылык.
Тын гына ял итә кара җир,
Талпына биектә ак болыт.

Колагым ишетә һәммәсен:
Челтери саф чишмә сулары.
Үләннәр сөйләшкән авазны
Тургайлар күтәрә югары.

Кулларым иркәли гөлләрне,
Кирәксә, тау-ташлар җимерә.
Аяклар санызйлар чакрымны —
Беркайчан кайту юк кирегә.

Кычкырып тормасын — сөюне
Йөрәкнең түренә яшердем.
Күзләрем дөньяны күргәндә,
Иренем һәрвакыт: «Яшим», — ди.

jjj

Тама торгач, нәни тамчы ташны тишә,
Кайный торгач, нәни дулкын ярны ишә.

Тик яттымы — сабан йөзе кояш күрмәс,
Күләгәдә үскән агач җимеш бирмәс.

Эчми торсаң, коеның да суы кибә...
Ә миндә бит теп-тере бер йөрәк тибә!

Җырла, йөрәк, дөнья җырга күмелгәнче,
Кабереңә кызыл гөлләр түгелгәнче!..

## СӨЮНЕ КӨТКӘНДӘ

*(Утлы хәбәр)*

Көтте кызый, мәхәббәтен көтте,
Яңгыр көткән кыргый дала сыман.

Чыкта коендырып тез башларын,
Чабып узды гөлләр арасыннан.

Күк астында оеп йоклап ята
Яшел болын, изүләрен ачып.
Кояш түгел, сөю күтәрелә! —
Офыкларга шулай тып-тын басып.

Чыклар кибә, күз яшьләре кибә...
Ялкынланып яна татлы сагыш.
Дәва булыр, таллар, кыз күкрәген
Дымсу яфрак белән капласагыз!

Син оялма, гаҗәпләнмә, чишмә,
Күреп кызның үзеңә иелгәнен, —
Тидерсен ул салкын суларыңа
Үбелмәгән кайнар иреннәрен.

Сөю булып кояш күтәрелә —
Мәхәббәттән гүя утлы хәбәр.
...Җиде диңгез кичәр иде егет
Шушы кызның барын белсә әгәр!

## ТАНЫШ ТҮГЕЛ КЫЗГА

Урман эчендәге ак каендай
Яктырдың син үтеп барышлый.
Ак күлмәкле, таныш түгел сеңлем,
Бу җырымны сиңа багышлыйм.

Сөю әле кагылмаган сиңа,
Кагылмаган ялкын, моң-сагыш.
Офыкларда көтеп тора сине
Мең шатлыгың белән мең сагыш.

Каршы бар син сөю җилләренә,
Акчарлактай очып-кагынып.
Алар сиңа бөек мизгел булып,
Якты бер наз булып кагылыр.

Кабындыңмы — берүк туктый күрмә,
Ахыргача янсын яшь йөрәк.
Мәһәббәттә, пыскып яшәгәнче,
Көл булуың мең кат яхшырак.

...Урман эчендәге ак каендай
Яктырдың син үтеп барышлый.
Ак күлмәкле, таныш түгел сеңлем,
Бу җырымны сиңа багышлыйм.

## БИРЧЕ, ДӨНЬЯ!..

Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә...

*Г.Тукай*

Әй, дөнья,
бирче миңа Тукай күзләрен!

Тукайдан соң
күпме йолдызлар атылган,
күпме тәхетләр ватылган —
егерменче гасыр һаман хәрәкәттә.

Җир һаман да
үз күчәре тирәсендә әйләнә:
көннәр — төнне,
төннәр көнне куып тора:
иске проблемалар үлә,
яңалары чәчрәп туып тора.

Илләр бәхәсләшә,
тәгълиматлар, хисләр бәхәсләшә.
Хакыйкатьне,
        гаделлекне яклап
планетада Намус дәшә!

Съездлар, парламентлар, конгресслар,
үз күчәрендә әйләнгән Җир кебек,
ике сүз тирәли әйләнә:
— Сугыш?
— Тынычлык!

Сабыйлар — Кояшка,
өлкәннәр бомбага сузылган заманда
миңа — күпне күрү,
күпне ишетү кирәк!
Кояш белән бомба арасына
метеордай
сүзем атылып керер
һәм аннары... йөрәк.

Әй, дөнья,
бирче миңа Тукай күзләрен!
Кыйтгалар өстендә
үткен хәнҗәр булып
ялтырасын кайнар сүзләрем!

jjj

Син миңа күзләр бирдең:
        чыктагы салават күперен,
        таш өстендәге гөлләрне,
        күлгә төшкән айны күрергә өйрәндем.

Син миңа тел бирдең:
        дөньядагы иң көчле,
        җирдәге иң татлы,
        иң назлы сүзләрне әйтергә өйрәндем.

Син миңа көч бирдең:
        өстеңә чөелгән дулкынны,
        юлыңа ишелгән ташларны
        читкә алып ташларга өйрәндем.

...Син пышылдап нибарысы:
— Яратам, — дигән идең.

ЭЗЛӘР

Һаваларда — кошлар эзе,
Кая очар юллары?
Канатлар астында тып-тын
Тирбәлә күк Җир шары.

Һаваларда — ядрә эзе,
Кая табан атылган?
Явызлыкмы үтерелгән,
Әллә шатлык ватылган?

Һаваларда — кеше эзе...
Йолдызлар уйда, сакта:
Атом белән селтәнеп ул
Уза күрмәсен таптап!

jjj

Җир — автографлар китабы.
Галиҗәнап Вакыт
Төрле төсләр белән уйган үз имзасын:
Зәңгәр кара белән —
　　диңгезләрен, елгасын...
Яшел кара белән — болын-урманнарны.
Һәм аннары —
Кызыл кара белән янар тауларны...

Табигать тудырган кешене.
Галиҗәнап Кеше
Җир-китапка төшергән тәүге автографын—
　　ялангач тәпи эзләрен...
Беренче куркыныч янау белән —
Баш мие күзәнәкләре
　　дәррәү хәрәкәткә килгән:
Кеше тау актарган,
　　бүрәнәне кискән, ярган, өйгән...
Йорт-куыш ясалган бер дигән!

Тора-бара Кеше
Зурдан кубып сырлаган үз имзасын:
　　ташлаган да мескен ызбасын —
Иҗат иткән якты шәһәрләрне,
　　гөлбакчалар, тимер юллар,
Хәтта... атом бомбасын!

Яшәп булмый,
Кемдә, диеп, кемнең ни эше?
Җир-китапта тагын автографың
　　нинди булыр, Кеше?!

jjj

Мин авылда авырып ятам.
Мендәрем, башым кайнар...
Күзге төн. Тәрәз каршымда
Чайкала моңсу таллар.

Юылган җәйге авазлар:
Кошлар җыры, чыр-чулар.
Гарешкә киткән һәммәсе —
Гамь-шатлыклар, борчулар.

Караңгылык үзенә йоткан
Авылның бар халәтен.
Әтәчләрне «телсез» иткән,
Юашлаткан кара төн.

Айны дерелдәтеп этләр
Ник бер өрсен, ичмасам!
Җанымны, сырхау тәнемне
Әллә ниткән үч баса.

...Мин авылда авырып ятам.
Өнме бу, әллә төшме? —
Төн карасын яңгыратып,
Кырда ак байтал кешни!..

## ЮГАЛГАН ТӨН

Шәм яктысы сеңгән төн иде ул!
Ике йөрәк керде ялкынга.
Бертуктаусыз пышылдады яңгыр
Дога укып тәрәз артында.

Диңгез исе килгән чәчләреңне
Ак мендәргә куйдың таратып.
Әкияттәге сөю эчемлеген
Салып бирде безгә кара төн.

Түшәмнәрдә шәүлә калтыранды,
Өй артында яшен уйнады!
Яктыра да шундук сүнә торган
Ялган учак булган ул бары...

Күктәге ай — янар яшен ташы,
Юл чатында калган суынып.
Төнге яңгыр эзәрлекли һаман,
Эзәрлекли биткә сугылып!

jjj

Азмы хәсрәтле уйларны
Кырга чыгып җилгәрдем...
Җиргә ятып елаганын
Күргәнем бар җилләрнең!

Күргәнем бар яңгырларның
Чәчрәп, балкып көлгәнен.
Нинди ләззәт, рәхәт җанга!
Ачыла күңел гөлләре.

Кышка керсәм, күмеләм мин
Ап-ак карга, буранга.
Сагышлардан шаша буран!
Сыймый җырга, урамга.

...Яшәүнең төмен белмәсә,
Һәм җансыз булса әгәр, —
Үксеп елар идемени
Бу җилләр таңга кадәр?!

## ИДЕЛ

Бабайларның моңын, рухын эзләп
Ослан тауларына менгән идем, —
Акчарлагы, ак җырлары белән
Килеп керде җанга кичке ИДЕЛ.

Табигатьнең изрәп яткан мәле,
Йоклый кошлар, сеңеп оясына...
Уяна да хәтер, кереп китә
Канлы хатирәләр дөньясына.

Ят байраклар җилфердәтеп илгә
Яулар килгән, килгән явыз каган.
Су белән кан бергә кушылса да,
Ике иман бергә кушылмаган!

Шаулый ИДЕЛ...
Дулкын арты дулкын
Нәкъ йөрәккә килә тәгәрәшеп.
Бик тирәннән, тарих төпкеленнән
Оран сала кемдер безгә дәшеп.

Су өстендә тибри акчарлаклар.
Җавап бирче, әйтче, и мәңгелек:
Фида җаннар калкып чыккан мәллә,
Шушы якты кошка әверелеп?

Үткәннәрнең телсез шаһитыдай
Карт манара ярга чыгып баскан.
Шаулый ИДЕЛ —
Кара елларда да
Ак җырларын югалтмаган дастан...

## jjj

Сау кеше үзенең йөрәге барлыгын сизмәскә тиеш...

*Бабам сүзләре*

Мин тауларга күтәреләм,
Җан тулы ап-ак теләк.
Көтмәгәндә күкрәгемдә
Сикерә башлый йөрәк.

Кош шикелле тыпырчына,
Әйтерсең канатлы ул!
Азмы, ташларга бәрелеп,
Ярасын канатты ул.

Күктә — яшен... Исән-саумы
Кырда калган юлчылар?
Көн буена ничәмә кат

Сорау ала борчулар.

Кайчак җирнең шатлыклары
Ачып керә капкаңны.
Ничек шулчак сизмисең ди
Шашып йөрәк какканны?!

Кайгы-шатлык арасында
Яши йөрәк тартышып, —
Гел сиздерә үзен!.. Ахры,
Түгелдер мин «сау кеше».

jjj

Кададың шашкын йөрәккә
Син мәхәббәт хәнҗәрен!
Чишмә төсле актарылып,
Ташып чыкты гамьнәрем.

Саркып-саркып җәрәхәттән
Әй тамчылый сагышым.
Сулык-сулык...
Офыкларда —
Минем йөрәк тавышы.

Кайчак төн урталарында
Аваз салам дөньяга...
Сызласын, тынмый сызласын —
Аһ, татлы соң бу яра!

Чәчелгән мәрҗән шикелле
Уем, зиһенем таралды.
Күзләреңнең нуры белән
Инде бәйлә ярамны!

## ВАКЫТ БЕЛӘН БӘХӘС

Малайлыктан дәшеп, чакырып алдың,
Маңгаема җыерчыклар салдың.
Чәчләремне инде сирәклисең,
Гомер җебен көн дә теткәлисең —
Мин синеке, Вакыт...

Илһамланып якты уйлар корам,
Гасырларны җилгә каршы борам.
Дүрт фасылны меңгә төрләндерәм,
Кысылалар еллар берәм-берәм, —
Син минеке, Вакыт!

jjj

Күз нурларын туфрак белән генә
Буламы соң күмеп, яшереп?!
Каберләрдә... исән хыял сыман
Гөл орлыгы ята чәчелеп.

Кеше белән бергә туа хыял,
Кала — күктә, җирдә, суларда.
Күпме өмет челпәрәмә килгән

Тузанлы һәм карлы юлларда!

Үч һәм мәкер кара почмакларда
Посып тора, гүя ябалак.
Үз-үзеңә хыянәт кыл гына —
Ялгышларың тора сагалап.

Исәннәргә, шөкер, бу дөньяда
Кайгы-шатлык, өмет — җитәрлек!
Яшәсәк тә җирдә, рухыбызны
Без бит кояшкача күтәрдек.

Зур шатлыклар канатлы кош булып
Сибелгәннәр барча тарафка.
...Гөрли мәҗлес. Тик берәүнең әнә
Күз яшьләре тама шәрабка.

## ЯРУЛЛА ЮКӘСЕ

Әй, алма бит, алма бит,
Алма битләр кала бит.
Алма битләр калмас иде,
Патша солдат ала бит.
*Халык җырыннан*

Тутырып егерме биш елын
Кайткан да төшкән ул авылга.
Шул кичтә бер килен ялгызы
Такмаклап елаган: «Ярулла-а...»

Винтовка дускаен, үчегеп,
Ыргыткан тузанлы чардакка.
Аракы-шайтанга кушып, ул
«Сөймәскә» ант эчкән аулакта.

Ни кала кып-кыска гомердән?
Югыйсә яшь бара, яшь үтә...
Бәрәңге бакчасы янына
Утырткан Ярулла яшь юкә.

Бервакыт шау килгән тын авыл:
Тоташ ут эчендә утарлар!
Атларны коткарган Ярулла,
Тик менә гәүдәсен ут алган.

...Кәүсәдә — мәңләгән җыерчык,
Карт инде Ярулла юкәсе.
Бозралап түшәлгән елларны
Эх, димен, кирегә сүтәсе!

Җилләрдә чайкала карт юкә,
Ачкан да йөрәген давылга.
Тамырдан күкләргә кадәрле
Моң ага: «Ярулла...
Ярулла-а...»

jjj

Әрәмәдә — сәер кош авазы,
Әллә төннең җаны кычкыра?
Август йолдызларын сискәндереп,
Тын утарда атлар пошкыра.

Бөек төн бу! Төпсез зәңгәр күктә
Алтын дуга ясап ай бата.
Керфекләрен йомып йоклый авыл,
Атлар гына һаман аякта.

Бәйгеләрдән килгән кыргый бер көч
Дулый канда, шаулый, ул — тере!
Кара төннең салкын кочагында
Йөзеп йөри атлар хәтере.

Кайнар сулыш каплый улакларны,
Коры салам куя кыштырдап.
...Батыр тавыш күмә урамнарны —
Тракторлар кайта буш кырдан.

Тиберченеп ала нәни колын.
«Без картайдык инде, син яшә...»
Гомер иткән ил картлары сыман
Тын утарда атлар сөйләшә.

## ЯҢГЫРЛАРЫҢ — ЯШЕЛ ДАСТАН

Туган якта әллә кар яктысы,
Әллә инде каен яктысы?
Урманнарда кар бөртеге саен
Чәчрәп яна кояш чаткысы.

«Сайрый» кырда чана табаннары,
Сәфәр чыккан, димәк, юлаучы.
...Көртлекләргә кулы күтәрелми —
Телсез калган яшь бер сунарчы.

Кар өстендә чыңлый салкын әрем,
Зеңләп тора җилдә куаклар.
Бабайларның җаны, рухы белән
Өретелгән, ахры, бу яклар.

Битләремә килеп тия төсле
Салкын карлар, бозлар аркылы, —
Көрт астында гына йоклап яткан
Яшел язның тере ялкыны.

Әй, туган як!
Җырымнан мин һәйкәл куяр идем
Йолдызларга, төнге аеңа...
Яңгырларың — яшел дастан синең,
Бураннарың — ап-ак поэма!

## ИКӘҮ

Кыр буйлатып икәү бара,
Тузанда пар эзләр кала:
Ялан тәпи — малай эзе,
Читеклесе — бабай эзе.

Тоташканнар куллар кулга...
Шаулый иген уңда, сулда.

Юл читендә — чуклы үлән.
Атлау рәхәт бабай белән!

— Сөйлә әле, бабакаем,
Ничек үскән кырда каен?
Кыштыр-кыштыр... Нинди тавыш,—
Сөйләшәме әллә арыш?

— Ап-ак җанын каеннарның
Турау гөнаһ, әй, оланым.
Шатлык, нәфрәт җиле бәрсә, —
Телгә килә һәрбер нәрсә.

Тоташканнар учлар учка...
Юллар озын, гомер кыска.
Юл читләре — чуклы үлән.
Атлау рәхәт онык белән!

## ЯРА

*Әткәйгә*

Таза беләгеңне терсәктән үк
Чабып өзгән сугыш балтасы.
Сыңар канат белән кайткансың да
Елаткансың... басу капкасын.

Төшләреңә һаман керә сугыш:
Тоташ шартлау анда, тоташ кан.
Нервыларың, бикфорд шнурыдай,
Чит туфракка барып тоташкан.

Исән кулың, җиңеп кайткан кулың,
Үч иткәндәй вәхши сугышка, —
Ничә еллар инде балта чаба,
Тирә-ягың ап-ак йомычка!

Селтәнәсең... Дары исе түгел,
Нарат исе тула дөньяга.
Син ясаган зәңгәр рәшәткәгә
Тияр-тимәс булып моң ага.

Кырыс чагың — гүя
кайгыларны
Тураклыйсың салып бүкәнгә.
Сыңар куллап печән чабасың син...
Алып көче бардыр бу тәндә.

Ерак булган сугыш.
Ә ялкыны
Безнең дә бит җанны ялмаган.
Әткәйләрнең кулын кискән фашист,
Илнең кулын кисә алмаган!

## АВЫЛ КАРТЫ

Үлгәннәр генә кала зиратта,
Исәннәр керә, чыга борылып.
Уйлана картлык: «Быелгы көздә
Билгеләп калыйм кабер урынын».

Ашъяулык тиклем җирне әҗәткә
Киртәләр белән ала уратып...
Таяк таянып каршылый язны:
Торналар кайта офык буйлатып!

Җыерчыкларга, күзләргә күчеп
Яшәү чаткысы уйный тамырда.
Быелгы болыт койды чиләкләп —
Киртәләр бүртә, чери яңгырда.

Тагын килә кыш: зират капкасын,
Йозаклагандай, авыр кар баса.
Ерактан бер өн ят тавыш белән,
Соңгы кышың бу, диеп алдаша!

Кырларга азмы чыгып китәчәк
Җылысын тоеп кояш нурының, —
Тормышта инде ул әллә кайчан
Билгеләп куйган яшәү урынын!

## КАЙТА ҖАВАП...

Җәйге чиллә. Тир агызып күкрәгемнән
Ургый-ургый печән чабам карурманда.
Чү! Зәңгәр күк дер селкенде — үткен чалгым
Килеп тиде йөз яшәгән тамырларга...

Куркытылган кошлар очты пырхылдашып,
Күркә яуды ике нарат арасына.
Нигә әле моңсуланып калды урман:
Кагылдымы берәрсенең ярасына?

Әллә вакыт, әллә хәтер — тиен сыман
Сикереп уза агачларның башларыннан.
Кемдер яккан учакларның төсе булып
Кайта җавап, кайта туфрак асларыннан.

Акыл сатып көн иткәндер, яшәгәндер
«Ахырзаман» минутларын юраучылар.
Мәңгелекнең арбасына салып безне
Киләчәккә озаткан бит юлаучылар.

Сүнгән алар... Җиргә карап, күккә карап
Булды микән нәкъ минемчә уйлаганы?
Учлам-учлам йолдызларга, яфракларга —
Һәммәсенә йогып калган кеше җаны!

Тоташтырып сагышларны, әйтерсең лә
Басып торам ике заман арасында.
Нигә әле моңсулыкка чумды җиһан:
Кагылдымы берәрсенең ярасына?

## ТАТАРЛЫК КӨЗГЕСЕ

Илен яклап кулга кылыч алган,
Сөте белән каны кушылып тамган,
Тарихларда бетмәс эзе калган —

шулдыр татарлык көзгесе.

Бу халыкны ачы язмыш көткән;
Тузганактай ул таралып беткән,
Күңелләрдән дога сүзе киткән —
шулдыр татарлык көзгесе.

Оныкларга иман нуры салсак,
Туган телне яңгырата алсак,
Үлемсезлек михрабында калсак —
шулдыр татарлык көзгесе!

## КЕЛӘМДӘГЕ БОЛАН РӘСЕМЕНӘ КАРАП...

Урмандагы ерак кардәшеңнән
Таш пулатлар тора аерып.
Син дивардан сикереп төшәрсең дә
Чабарсың күк тездән кар ерып.

Хәрәкәткә, назга сусап тора
Сылу гәүдәң, көмеш тояклар...
Үзең кебек мәңгелеккә шулай
«Туктап» калган гөлләр, куаклар.

Еллар аша моңсу күңел белән
Рәсемеңә кабат мин багам:
Мөгезеңне, яшел үләннәрне
Йорт тузаны әнә каплаган!

## КУРКЫТЫЛГАН ПОШИ

Җиле белән яфракларны чөеп,
Дулап чыкты урман эченнән.
Нинди тәкъдир аны эзәрлекли,
Качып бара кемнең үченнән?

Урманның ул, бәлки, йөрәгедер —
Дүрт аяклы, күзле, яралы...
Рәшәләрне айкап чаба җанвар,
Арышларда кызыл кан табы.

Мәрмәр сыман шомарган ул җилдә,
Кача-кача бүре күзеннән.
Авылгамы барып сыенырга —
Сунарчылар килсә эзеңнән?

Мәңгелеккә озата бара аны
Үлән исе, усак кайрысы.
Ул егылса — кара яңгыр булып
Түгелер күк җирнең кайгысы!

Катлы-катлы урман өсләрендә
Зәңгәр төтен тора беленеп.
Чатлы мөгез, сорау билгеседәй,
Офыкларда калды эленеп...

## УЕН

Уйный идек җирдә, суда, күктә...
Күк дигәнем — агач башлары.
Ак парашют итеп күлмәкләрне,
Рәхәт иде аска ташлану!

«Чебиләгән» ялан тәпи белән
Буразнадан йолдыз эзләдек.
Җәен — яңгыр, кышын карлар булып
Сокландырды һәрбер үзгәлек.

«Ташкалага кем баш кала?» — диеп
Кайный идек, гүя кырмыска.
Уйный-уйный тап-тар тыкрыклардан
Чабып кердек олы тормышка!

Безнең җиңү, безнең алданулар
Чынлап уен булган лабаса...
Ә тормышта тәртип-кагыйдәләр
Карап торсаң — үзе тамаша!

Тормыш — уен, шундый җитди уен,
Яшеренеп битлек артында,
Күпләр әнә матур сүзләр сибә
Гаделлек һәм намус хакында.

Алтыннарын биреп сыный дөнья,
Йә күрсәтеп сыный сылуын.
...Бу тормышта, ниләр кылансаң да,
Иң кыены — Кеше булуың...

## ОЧЫШ

Кош каурые тамган зәңгәрлектән
Бер өн килә, килә чакыру!
Мин — очышта. Күңел канатымның
Болытларга ашкан чагы бу.

Аста — киңлек, сәер күренешләр:
Таулар чүгә, эри, югала.
Кан тамыры сыман кабарынып,
Тармакланып ята елгалар.

Һәр тарафтан хикмәт, мәгънә эзлим,
Авылларны күзлим биектән,
Туган йорты биргән иман белән
Кеше мәңге җиргә береккән.

Килеп чыгам шәһәр өсләренә,
Тып-тын йөзгән Икар шикелле.
Торбалардан чыккан кара төтен,
Суырып алып, йотар шикелле.

Офыкларда тарих төсмерләнә,
Һәм ачыла... еллар капусы!
Мәгарәдән күчә-күчә килгән
Кеше рухы, кеше яктысы.

Алтын айлы манаралар белән

Идел-йортның күге яңара...
Чиркәү чаңы кыйный офыкларны —
Кайсы чор бу, кайсы замана?

## ТУГАН АВЫЛДА ОЧРАШУ

Мин туганны белгәч, әткәй
Карурманга юл тоткан.
Нәни миләш алып кайтып
Янбакчага утырткан.

Сал җилкәмә яшел кулларыңны,
Саумы, дустым — яшьтәш миләшем!
Дөнья күргән ир-егетләр сыман,
Бер утырыйк әле сөйләшеп.

Быел тагын җимеш өлгерткәнсең...
Безнең җимеш — эштә, шигырьдә.
Кылган эшең «сөт»кә китә барса,
Җанны борчу кыйнап тилмертә.

Кара көздә кырау алган саен,
Тәлгәшләрең тула балланып.
«Кырау төшмәс безгә», — диючеләр,
Вакытлыча яши алданып.

Минем дә бит күңел багындагы
Хыялларны, гамьне, гөлләрне
Көтмәгәндә тормыш кыраулары
Каплап киткән иде бермәлне...

Чәчләремә «көмеш» өсти-өсти
Чыныктырды салкын кыраулар.
Ачы җилләр сине йолкыган күк,
Мине көн дә талкый сораулар.

Үз-үзеңне югалтмаска теләп,
Мең терелеп, мең кат үләсең, —
Кеше булып яшәүләрнең хәлен
Тик бер тапкыр
Тойсаң иде икән, миләшем!

## СЕРЛӘР ЭЗЛИМ

Бер үк кояш яктыртса да шушы җирне —
Үләннәрнең яфраклары төрле-төрле.
Кара туфрак имеп үскән алмагачның
Алмалары нидән кызыл — шунсы серле.

Тузан баскан каберташлар көтеп тора
Яфракларның сыйпап-сыйпап киткән чагын.
Кая гына бакма — хикмәт белән,
Серләр белән тулып ята тирә-ягым!

Кешеләрнең йөзләреннән серләр укыйм:
Берәү моңсу, ә берәү шат атлый юлдан.
Агач битле, таш бәгырьле җаннар гына
Мәхрүм була сагышлардан, елмаюдан.

Киң күкрәкле ир-егеткә караганда
Ун мәртәбә катлаулырак хатын-кызлар.
Серләрнең дә иң серлесе, иң нечкәсе —

Күз нурыңны сындырырлык матур кызлар!

Серләр эзлим, серләр ачам — вакыт җиткәч
Сөйләр өчен оныкларга чын дөресен.
...Күзләремнән якты йолдыз яуган чакта,
Мин үзем дә сердер әле кемдер өчен...

## КЫЗЫЛ ҖӘЙ

Печәннәре уңган каерылып,
Җиләк исе аңкый җилләрдән...
Михнәтләргә сал син безне, язмыш,
Тик аерма туган илләрдән!

Кыштыр-кыштыр үсә карабодай,
Туган туфрак — серле, хикмәтле:
Кочагына алып тибрәтә дә,
Суза беркөн хәләл икмәкне.

Кояш байый. Офыклар ут яна —
Кызыл шәүлә бии алмада.
«Янгын!» — диеп, дәртле чикерткәләр
Берөзлексез кырда чаң кага.

Офык яна... Мәшәкатьле көннең
Итәгенә гүя ут капкан!
Сүндермәсме яңгыр — болытларны
Җыеп йөри җилләр ерактан.

Тарала да бетә вак болытлар,
Тынып кала дөнья берзаман.
Кызыл ялын шулай җилфердәтеп,
Кая табан оча бу заман?

## МИШӘ БУЕНДА УЙЛАНУ

Җирнең гади, тыйнак бер елгасы!
Зур кораблар синдә йөзмәгән.
Сал өстендә аккан балачагым
Балык тоткан, энҗе эзләгән.

Зур сугышлар тетрәтмәгән сине
Кырык бернең кара җәендә:
Төпләреңә кеше каны түгел,
Язгы ләмнәр, туфрак җәелгән.

Он тарткансың — арышлары белән
Дер селкенгән иске тегермән.
Улаклардан агып һәрбер өйгә
Капчык-капчык бәхет йөгергән.

Ачлык килсә, тешен шыгырдаткан
Тегермәннең салкын ташлары.
Шул хактамы әллә шыбырдаша
Карт тупылның ябалдашлары?

Ә болында һаман сулар шавы:
Торбалардан «яңгыр» бөркелә.

Һәрбер үлән, һәрбер тере чәчәк
Чыгып баскан кояш иркенә.

...Хәтер сыман убылды да төште
Кызыл ярның үзле балчыгы.
Антеннадай үрелеп, үткәннәрдән
Хәбәр ташый ярда талчыбык.

## ҺӘЙКӘЛ ЯНЫНДА

Азия материгының географик үзәген символлаштырган һәйкәл Туваның Кызыл шәһәренә, Енисей ярына урнашкан.

Күк гөмбәзе балкый киерелеп —
Якты җәйнең зәңгәр юртасы.
Көләч Тува! Синдә икән бит ул
Азиянең төбе, уртасы.

Гасырларны ерып бара имән,
Таза булса эчке катламы;
Һәм сәламәт орлыклардан гына
Борнап чыга чәчәк саплары.

Кыл уртасын күрдем Азиянең:
Барлык җисме, рухы сәламәт.
Дала белән таулар кардәшлеге —
Халыкларга гүя әманәт.

Тау башына хәреф тезгән яшьлек:
«Дуслык» диеп җырлый ак ташлар,
Күрше илгә төбәп беркайчан да
Хәтәр учак монда якмаслар!

Кодрәтеңне күрсәт әле, вакыт, —
Дәрьягка сөр сугыш алласын!
Чумрып ал да илләр саен өләш
Тынычлыкның татлы һавасын.

...Һәйкәл яны. Уйчан, карт тупылдан
Истәлеккә яфрак өзәмен.
Күңлем тагын китте сәяхәткә.
Күңел эзли җирнең үзәген.

## ТАШ ӨСТЕНДӘ — НАРАТЛАР

Саян тавы киртләч-киртләч,
Үрләр — зәңгәр камалыш.
Тып-тын яткан тауларда да
Минут саен яңарыш.

Вакытның авырлыгыннан
Чатнап куя мәгарә.
Һәм кукуруз басуына
Төшә ташлар тәгәрәп.

Самолетның күләгәсе —
Канатлы кош төслерәк:
Кыйгачлый да бәреп керә
Чал наратлар өстенә.

Ташта үскән наратларга
Карап тордым озаклап, —

Тамырлары белән тауны
Куйганнар бит «йозаклап».

Бардыр, Саян, серле капкаң,
Ачылсын ул, ачылсын.
Төптә яткан дастаннарың
Ак җыр булып чәчелсен!

## КЫЯГА САЛЛАР БӘРЕЛГӘН

Караңгылык агып төшә таудан,
Балчык исе ярда, төн исе.
Йөрәк серен сөйләп карурманга,
Пышын-пышын ага Енисей.

Су эчендә кыя төсмерләнә,
Әйтерсең лә иске тегермән.
Риваятьләр сөйли: аның, имеш,
Түбәсенә шайтан төкергән!

Җырлый-җырлый урман кискән ирне
Саклый икән язмыш корбаны:
Шул кыяга килеп төртелдеме —
Туктала, ди, саллар кәрваны.

Сүгенгән дә таза-таза ирләр,
Багор тотып инде аннары
Салны читкә этеп чыгарганнар,
Киемнәре — сыгып алмалы!

Өсләреннән пар бөркелеп тора,
Лачма юеш күлмәк-ыштаннар.
Уйнап-көлеп, кыя ташка алар
«Мунча» диеп исем кушканнар.

Таш «Мунча»ны еллар чәрдәкләгән —
Тыеп булмый вакыт агышын!
Төн эченнән карап тора кебек
Сал агызган ирләр сагышы.

## ТАШЛАНДЫК КОЕ

Үҗәтләнеп, җирне күләгәләп,
Кычытканнар үсә балчыкта.
Тып-тын гына сулып ята кое,
Күз яшьләре кипкән карчыктай.

Юлаучымы туктап чиләк сала, —
Шифа иде суы кемгә дә!
Төпләренә төшеп ак болытлар
Коена иде җәйге челләдә.

Суы киткән — каны кипкән инде,
Сагыш белән тулган бурасы.
Пәрәвездә чебен бәргәләнә, —
Шул аваздан тора дөньясы.

Куркуданмы — качыш уйнаганда
Читләп уза аны нәниләр.
«Суы йомшак иде», — дия-дия,

Сагынып сөйли кайчак әбиләр.

Бардыр бит ул безнең йөрәктә дә
Онытылган, сулган чишмәләр...
Сулар эзләп чапкан аргамагым
Авызлыгын әнә тешләгән!

## ЯЗЛАР КИЛӘ

Бөре саен күпме яфрак туа...
Һич ышанмас идем мин, әгәр:
«Бакый дөнья нык таушалган инде,
Картайган ул, тузган», — дисәләр.

Зәңгәр күктә картлык эзләренең
Әсәре дә юк бит, күр әнә!
Яңа язның яңа сыерчыгы
Йөрәкләргә кунып тирбәлә.

Күңел көн дә могҗизалар көтә,
Искәрмәгән хисләр, сагышлар.
Бозны ярып чыккан үләннәрнең
Һәр сабагы — яшел табышмак.

Сулык-сулык тибә гөрләвекләр,
Сызып кына аккан гомердәй.
Язлар саен мин мәхәббәт көтәм
Уналтысы тулган үсмердәй!

## СӨЙЛӘ, УРМАН...

Печән исе, җиләк исе сеңгән
Урмандагы дымлы һавага.
Күзне йомып бер сүз пышылдасаң,
Чәчәк атар төсле абага.

Сөйлә, урман, САК-СОК моңнарымы
Күтәрелә синең тамырдан?
Вакыт әнә каен тузларына
Күпме җырлар язып калдырган.

Әй, ромашка!
Багып бирче миңа:
«Яратамы... әллә яратмый...»
— Э-һе-һей-й!
Кайтавазлы кара урман шулчак
Сүзләремне минем кабатлый —
Исемеңне синең кабатлый!

## МӘХӘББӘТ ФАСЫЛЛАРЫ

### 1

Эзләмәгез! Бу — мин бит ул дөрлим:
Керфекләрем, эчем-тышым яна.
Йөрәк — утлы күмер... Күкрәгемә
Коеп-коеп яңгыр яуса кана!

Тик бер генә сыдырылсын яшен —
Ялмап ала күкнең чатырларын!

Сизми калдым шулай сөюнең дә
Йөрәгемә уклар батырганын!

Күзләреңә карап ял итим бер,
Бу күзләрең — мин тукталыр өчен.
Җирдән алып күккә кадәр булган
Һәр могҗиза — без сокланыр өчен.

Кая бакма — «яшел утлар» яна,
Җәйгә атлап керү нинди ансат!
Җитәкләшеп үскән кыр гөлләрен
Кем иркәләр иде без булмасак?

2

Ишетәсеңме, яфрак шавы булып
Урман эчләреннән бер моң ага.
Эчем тулы акыл иде. Хәзер
Охшап калдым тәмам диванага.

Юлларымда — сары шлагбаум.
Уза алмыйм синең назларыңа.
Сикереп чыгыйм салкын сентябрьдән, —
Туктап торчы, Вакыт, азга гына!

Узып китик көзнең кырауларын,
Тик кирәкми, бәгърем, күз яшьләре.
Фейерверк булып кабынган бит
Миләшләрнең утлы тәлгәшләре.

Ак каеннар, яфрак-яфрак итеп,
Җир-әнкәгә түли «алтын ясак».
Болытлардан шуып чыккан кояш
Нишләр иде икән без булмасак?

3

Кар пәрдәсен ертып поезд чаба,
Киләчәккә чапкан хыял кебек,
Тәгәрәтсәң, ап-ак шатлыкларым
Кочагына илнең сыяр кебек.

Яз каршына йөгерәсе таллар,
Көязләнеп, яулык ябынмакчы.
Рельсларга басып карап торам,
Хисләремә буран сарылмакчы.

Эзләр калыр безнең, сүзләр калыр, —
Мең елдан соң тагы шушы карлар,
Нәкъ бүгенчә итеп, колагыма
Исемеңне синең пышылдарлар!

Күктә әллә сихри болытлармы, —
Ак ромашка ява ак юл ясап.
Көрт эченә чумган әкиятләрне
Кемнәр табар иде без булмасак?

4

Күрәсеңме, ачы бал шикелле,

Боз-тактаны ватып чыкты инеш.
Буйга узган таллар саташтылар
Су эченә кереп баскан килеш.

Киек казлар, бәхет илчеседәй,
Баш өстендә безнең әйләнделәр.
Төннәр агып керде кочагыма:
Чәчләребез чәчкә бәйләнделәр.

Җиргә сынып төшкән яшь ботаклар
Ярсып-ярсып яфрак яра әнә!
Тере дулкын булып мәхәббәтем
Берөзлексез җанда бәргәләнә.

Күпме генә талкымасын вакыт —
Күзләреңнең төсе уңмый ласа.
Бу дөньяның яшерен сагышлары
Ятим калыр иде без булмасак!

## КЫШКЫ ФАНТАЗИЯ

Кышка керде авыл. Вак малайлар
Такыр юлда «шакмак» тибәләр.
Язылмаган дәфтәр битләредәй,
Агарынып ята түбәләр.

Селти агай кыска чыбыркысын,
Утырган да чана читенә.
Һәм яңа эз, ап-ак рельс булып,
Фермаларга табан «сүтелә».

Морҗалардан чыккан ялкау төтен
Чорнала да кинәт буранга,
Бәлешләрнең тәмле исен төяп,
Ял итәргә кача урманга.

Көрт эчендә авыл мунчалары
Паровоз күк сулый уфылдап:
Кайнар ташның, назлы хатыннарның
Бар җылысы монда кушылган...

Яшел җәйне төргәк-төргәк итеп
Элеп куйды икән кем анда? —
Кычытканнар, кипкән мәтрүшкәләр
Калтырана салкын чоланда.

Язга карый инде тәрәзәләр:
«Чәчәк аткан» бозлы пыяла.
Кош җылысын көн дә сагына-сагына,
Җәйне көтә карлы оялар!

jjj

Нинди көчләр сәях җанлы итеп
Яраткандыр адәм баласын?
Хыялында ул җәяүләп уза
Йолдыз белән йолдыз арасын.

Күктә кояш, җирдә утлар яна,
Гүя тормыш — төсле маскарад.

Шампан булып ташый ал бәхетләр,
Сагыш кына төптә, астарак.

Көпә-көндез ай тәгәри күктә —
Тәмам, ахры, чиргә сабышкан.
Качыш-качыш уйнагандай итеп
Йөгерешә кырда арышлар.

Буранлый да койма өсләреннән
Сикерә кыш — ап-ак «көнгерә».
Чәчәкләрен кысып күкрәгенә
Кар астында язлар өлгерә.

Таңнар алсу, күкләр бик ямансу,
Урманнарны серле моң баса.
Кемгә кирәк шушы матурлыклар —
Җирдә әгәр кеше булмаса!

## ҺӘЙКӘЛ

*Нәкый ага Исәнбәт белән очрашкач*

Халыкның бәгырь түреннән
Җыеп сүзне, фикерне, —
Халыкка һәйкәл салды ул
Оста сынчы шикелле.

Зиһен ягын Ходай биргән,
Гыйлем ягын — мәдрәсә.
Берүзендә әллә ничә
Институт лабаса!

Хәзинә булып тезелгән
Киштә-киштә томнары.
Һай, ашыгып ата да соң
Фани дөнья таңнары!

Нәкый ага күзләрендә
Күрсәк әгәр моңсулык —
Бу бөек бер сызланудыр,
Уйланудыр борчылып:

«Бар куәткә җиктем микән
Гомеремнең көчләрен?
Дөньялыкта ятып кала
Эшләнмәгән эшләрем...»

Халыкның үзеннән җыеп
Җырны, сүзне, фикерне, —
Үзенә дә һәйкәл салды
Оста сынчы шикелле.

## ЕЛАП ТОРГАН КЫЗНЫ ЮАТУ

Ник тетрәде әле керфекләрең,
Нинди җилләр узды кагылып?
Күк йөздәй төпсез күзләреңдә
Яшен эзе тора чагылып.

Син елыйсың...
Күктә кояш көлә,

Бал кортлары кайта басудан.
Карурманның яшел капкалары
Мәңгелеккә табан ачылган.

Елмаясың...
Күлдә аккош елый,
Дөнья елый аңа кушылып.
Зонтикларга, агач башларына
Яңгыр булып ява шушы моң.

Белми калсын, күрми калсын сөю
Чәчәк сабын җилләр кискәнне...
Ник тетрәде әле керфекләрең,
Әйтерсең лә дөнья сискәнде!

## ТӨНГЕ КАЗАН

Казанымда буран бии,
Шәһәр күккә тоташкан.
Кайда шәрык, кайда гареп —
Дөнья тәмам саташкан.

Алҗыган светофорның
Күзләрендә — кар табы.
Таш урамнар кочагында
Әй өлгерә кар тавы!

Буран эчләреннән кинәт
Саркып чыга ябалдаш.
Җиде юлның чатларында
Басып торам яланбаш...

Без яраткан кышкы төннәр
Ничек инде суынсын, —
Кар булып битне яндыра
Синең сулыш, синең сын.

Казанымның күкләрендә
Уйный төнге ак буран.
Тонык йолдыз булып әнә
Тәрәзәләр яктырган!

## ЧИСТАРТЫРГА!

*Бөек Ватан сугышы саперы*
*Рәшит ага Мәһдиевкә багышлыйм*

### I. Германия. 1945 ел

Европада кызыл шәүлә бии, —
Рейхстагның соңгы сәгатьләре...
Доллар исе килгән якка карый
Нацизмның канлы бәбәкләре.

...Атакага барган батальондай,
Сугышчылар тагын чыкты кырга:
Орлык көтеп яткан Герман җирен
Миналардан кирәк чистартырга!

Чистарталар — мина чокырында
Ромашкалар чәчәк атсын өчен;

Дары иснәп туйган игенчеләр
Кырларына кире кайтсын өчен.

Миналарда шомлы күләгә бар,
Курыкмыйча, имеш, тотын шуңа:
Гармун уйнап үскән егетләрнең
Уч төбендә... үлем тыпырчына.

Киеренке мизгел! Юк, кичерми,
Кичерми ул саксыз хәрәкәтне...
Көрәш бара — сабан тургайлары
Таймый калсын өчен һәлакәтне.

Сизеп тора сугыш беткәнлеген
Җиргә тезеп салган автоматлар.
Җиңү көннәренең төсе булып
Полосада әнә кешни атлар.

II. Татарстан. 1981 ел

Арча урманнары... Полосада
Шул ук атлар әллә кешниме соң?
Мина эзләп туңган бармакларның
Җәрәхәте искә төшмиме соң!

Таныптырмы, әллә танымыйча —
Яшел учын суза һәрбер арыш.
Ромашкалы кырны ера-ера,
Рәшит агай, кая китеп барыш?

Ничәнче яз, ничәнче җәй инде
Яшьлегеңне эзләп чыксаң кырга,
Иңә күктән сугыш кайтавазы:
«Чистартырга кирәк, чистартырга!»

...Доллар имеп үскән неофашист
Зур властька инде үрмәләгән.
«Чистартырга кирәк Җиребезне
Заговордан, канлы төрмәләрдән!»

«Першинг»лар чехол изүләрен
Ертып ачмак була тыныч кына...
Кара мишень булып Европаның
Күкрәгендә үлем тыпырчына.

«Җирне, суны, күкне — бомбалардан,
Сугышлардан кирәк чистартырга!»
...Җир шарының теләкләрен төяп,
Рәшит агай әнә чыккан кырга.

КОШЛАР МОҢЫ

Кошлар оча торган киңлекләрдә
Әллә каурый, әллә моң тирбәлә:
«Кунып сайрый торган талларымны
Җил аудармас микән соң иртәгә?

Гәүдәм мине җиргә таба тарта,
Канатларым — күккә, югарыга.
Канат очы белән сипли-сипли,

Оя кордым — бала чыгарырга.

Томшыгыма таң сулары җыям,
Дошман килсә — әзер тәпиләрем.
Миңа бүген кайтып җитү кирәк:
Азык көтеп ята нәниләрем».

Мәңгелектән килгән бер канун бар:
Яңгырың ни аңа, яшенең ни, —
Ана кошлар, үз баласын ташлап,
Чит ояга барып яшеренми!

Кош халәте — кеше халәтеме?
Кайгы килсә, елый белми алар.
Йөрәк серен, көн каршына басып,
Сайрар телдә бары аңлаталар.

## ШАГЫЙРЬНЕ КАРШЫЛАУ

Иж-Буби картларының сөйләвенә караганда, бу авылның халкы Тукайны яшел чирәм җәеп каршылаган.

Дәррәү купкан авыл! Кара фикер
Чатта калган нидер сөйләнеп.
Сәхнәмени — юлның уртасына
Сипкән халык илнең чирәмен.

Сеңдереп кал, Тарих, хәтерләп кал
Тукай йөзендәге балкышны.
Клячкинда, яшәү төсе итеп,
Юксынып ул шушы алкышны...

Килә Тукай, балачактан килә,
Бозлар җәеп язмыш каршылый;
Ятимлекнең салкын кулы белән
Битләренә гүя кар сылый.

Керә Тукай Казан урамына —
Күтә дошман, күтә дуслары.
Шигырь уты белән яндырган ул
Державаның салкын бозларын.

...Вакытларны бергә тоташтырып,
Ява карлар, яңгыр тамчылый.
Бара Тукай Яшәү урамыннан —
Кочак җәеп еллар каршылый.

Казан өсләрендә дөрли кояш,
Ул — шагыйрьне күргән утчәчәк.
Гасырларны ерып бара Тукай,
Һәм каршылый аны киләчәк!

## ОРЕНБУРГ ДАЛАСЫНДА

Соры нурлар айдан түгелгәнме
Оренбурның төпсез даласына?
Куркытылган кара чикерткәдәй,
Гильза ява үлән арасына.

Ут астында үскән кылганнарның
Тамыры нык икән, нәселе нык, —

Ярсый-ярсый «атака»га бара,
Танк чылбырына асылынып.

Йомраннарга, бәлки, күңелсездер —
Ач ядрәне үртәп сызгырмагач...
Таллармы соң яраланды икән:
Дала уртасында — кызыл агач!

## ХӘРБИ ЧАКНЫ ХӘТЕРЛӘҮ

Палаткада кара төн уздырам
Мендәр итеп шинель итәген.
Учагымнан утлы күмер чәчри —
Һәм йокыдан айнып китәмен.

Сызгыра җил... Басу уртасында
Атлар йөри сыман пошкырып.
Туган якта калган кайтавазлар
Буран аша килә кычкырып...

Тузына да карлар, палатканың
Ишекләрен ачып кергәли.
Таң алдыннан мичләр сүрәнәя,
Котелокка суык үрмәли.

Кар өстендә өр-яңа көн туган —
Нинди якты, нинди сөйкемле!
Кояш бүген, тимер каска киеп,
Йокысыннан торган шикелле.

## КАЙТАВАЗ

Үзгәрә гореф-гадәтләр,
Үзгәрә җанлы сөйләм.
Өр-яңа мезазойларны
Каплый да китә үлән.

Куәтле экскаватор
Тешләрен тирән керткән:
Катлам-катлам дәверләрне
Кубарып ала төптән.

Хәвефле, утлы гасырның
Җилләре булган зәһәр, —
Кайнар туфан асларында
Күмелеп калган шәһәр.

Агартып та, каралтып та
Дөньяны юган сулар.
Көл һәм туфрак арасында
Никадәр югалтулар!

Кайсының күз яше булып
Җемелди таң чыклары?
Зираттагы каберташлар —
Тарих кыйпылчыклары...

## ЯҢГЫР АСТЫНДАГЫ МӘХӘББӘТ

Гамьсезләрнең тәрәзәсен шакып,
Урамнарның ташын чылатып,
Көлә-көлә узып бара яңгыр,
Миллионлы шәһәр буйлатып.

Селтәнә дә яшен, кометадай,
Болытларны үтә яндырып.
Диңгезләргә киткән пароходның
Эзен юа Идел яңгыры.

Акчарлаклар килеп кунар төсле —
Учларыңны ачып куй гына!
Агачларның яшел зонтигыннан
Шыбыр-шыбыр тамчы коела.

Тамчыларны күккә чөйде егет,
Суырды да үпте сөйгәнен...
Яңгыр кылларына чиртә-чиртә,
Дастан сөйли сөю дигәнең!

## СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ

Антеннадай күккә чөелгән дә,
Көн каршына баскан Сөембикә.
Үз-үзеңне шулай мәгърур килеш
Тотып торулары кыен бит, ә?

Кыйбла якка авышкан ул, дибез —
Кыек тора, бәлки, заманасы?
Киләчәк көн татлы тоеладыр,
Ә үткәннәр ләкин һаман ачы.

Җир-су өчен көрәш барган чакта,
Яуга каршы яулар чакырылган.
Нигезеңдә кан-сөякләр ятса,
Авышырсың хәтта акылыңнан...

Кыршау белән билен чорнаганнар:
Гүя тарих аны кысып тора.
Һәр кирпече, күзәнәге саен
Күпме легендалар посып тора!

Ә кичләрен серле, сәер кошны
Хәтерләтә, бәлки, күпләр өчен.
Күр, томшыгын күккә таба сузган
Төнге йолдызларны чүпләр өчен.

Җим булырга теләмидер, ахры —
Күкнең читен йолдыз кыеп китә.
Шәһәр йоклый...
Айны томшыгына
Эләктерде әнә Сөембикә!

## СӘГАТЬ НИЧӘ?

«Сәгать ничә?» — сорый замандашлар,
«Сәгать ничә?» — сорый танышларым.
Дүрт күз белән көтеп тора дөнья
Сәгать укларының авышканын.

Сәгать суга! Шушы көмеш аваз
Каерып ача галәм читлекләрен.
Нинди өннәр алып килә безгә
Гап-гади бер җыры чикерткәнең?

Сәгать суга!
Зәңгәр сварканың
Очларыннан тама утлы нокта.
Философмы, күмер чабучымы —
Ә кемдер бит туды бу минутта...

Шагыйрь икән — булсын туры сүзле,
Полководец икән — мәрхәмәтле.
Кирәксә — сүз яки кылыч белән
Яклый белсен алар мәхәббәтне!

Кош очса да, күкләр тетрәп куя —
Кешелекнең киеренке мәле.
Ракеталы тешен шыгырдатып,
Корбан сорый сугыш тегермәне.

Зур «план»мы кора генераллар,
Рәсәй картасына сеңә-сеңә?
Кай минут бу? Бишектәге сабый
Үреләдер сөтле шешәсенә.

Йолдызларның күчешенә карап
Дөресләгән сыман сәгатьләрне,
Үзгәртәсе, дөреслисе килә
Тормыштагы яман гадәтләрне.

«Сәгать ничә?» Шул гадәти сорау
Искермичә көн дә кабатлана.
Планетаның зәңгәр чатырында
Гел бәхетле минут булса кана!

Казан урамында — татарчалап,
Истанбулда әнә саф төрекчә,
Лондон урамында — инглизчә
Сорый замандашлар:
— Сәгать ничә?
— Сәгать ничә?

## ГАДИ БЕР КӨН...

Болытларны сискәндереп,
Оча кошлар кәрваны.
Яңа көннең күкрәгендә —
Яшь егетләр дәрманы!

Кырларда арыш өлгергән,
Елгада — көмеш балык.
«Җирем-суым», — дия-дия,
Чәчкәнен ура халык.

Эштә ирләр бәхәсләшә —
Гүя кече парламент.
Кайнар цехлар кочагында
Пешә асфальт парланып.

«Чаллы» сүзе искермәде,
Саллы булып яшьнәде:
Африка чүлләре буйлап
Чаба «КамАЗ» гаскәре!

Кранчы кыз, көлә-көлә,
Болытны да каптырган.
Шуңадыр: салган йорты да
Ак болыттай актырган.

Шыбырдатып имәннәрне
Узды-китте яңгырлар.
Хет отып ал: яфрак саен
Җырлар элеп калдырган.

Тарих — уяу: кылларына
Бер кагылып ал гына,
Утлы елларның күмерен
Сибеп ташлый алдыңа...

Булмасын өчен сугышлар,
Булмасын өчен яра, —
Кояш әнә, байый-байый,
Тарихка кереп бара!

КЕМ БАЛАСЫ?

Сагышланып, атна саен өйдә
Көтә аны ата-анасы.
Кайта, китә... Шулай гомер итә
Шәһәрләшкән авыл баласы.

Таш урамнар, трамвайлар җыры
Сеңеп бара инде канына.
Кыен чакта туган яклар назы
Маңгаена килеп кагыла.

Төрле яктан җилләр кысып тора
Туган телнең чиста һавасын...
Урысчаны ватып-җимереп сөйли
Шәһәрләшкән авыл баласы.

Рок-музыка әле тилертмәгән,
Джинсылар инде үз иткән.
Тулай торак сыендырсын гына —
Бүгенгесе өчен шул җиткән.

Белми әле, белми чын бәхетне
Кайдан, ничек эзләп табасын.
Кино карый, тик ятудан арый
Шәһәрләшкән авыл баласы.

Кырлар көтә: ашар икмәгеңне
Үстерә бел, диеп, иң элек.
Кызыктыра шәһәр... Җаны шулай
Кыл урталай яши бүленеп.

Яшьләр китә...
Ни югалттың, авыл?
Син ни таптың, Казан каласы?
Кайта, китә — шулай дөнья көтә
Шәһәрләшкән авыл баласы.

## ӘНКӘЙГӘ КАЙТУ

Мин туганмын. Газиз әнкәй
Бишегемә иелгән.
Күз тимәсен балама, дип,
Биткә сөрмә тидергән.

Тагын мең кат иелгәндер
Куанып һәм шатланып.
Көләч йөзе хәтеремдә
Шулай тора сакланып.

...Килде авыр, кайгылы көн —

Тын гына, салмак кына
Дога сүзләрен кабатлап,
Бастым әнкәй каршына.

Ачыну һәм күз яшьләре
Тамагыма төелде...
Бу юлы әнкәй йөзенә
Соң тапкыр мин иелдем.

Шул иде, ахры, әнкәйгә
Бурыч кайтарган көнем.
Мең кат башлар иелсә дә,
Бурычым бетмәс минем!

Юллар озын, юллар ерак,
Тагын кайтып барышым.
Юл йөретә, баш идертә
«Әнкәй» дигән сагышым...

jjj

Ике күз биргән табигать —
Күбрәкне күрер өчен.
Ике аяк биргән — җиргә
Нык басып йөрер өчен.

Ике кул — анысы инде
Күбрәкне күтәрергә;
Тормыш йөген һаман саен
Алгарак этәрергә!

Бер баш биргән — берәгәйле
Уйлана белсен, диеп,
Икейөзле булулардан
Саклана күрсен, диеп.

Табигать бик дөрес иткән —
Йөрәк тә бит берәү җиткән:
Икеләтә сөяр өчен,
Гамь утында көяр өчен,
Иң хәсрәтле минутларда
«Уф, йөрәгем!» дияр өчен...

## КАБАННЫ ЯКЛАП БЕР СҮЗ

Кабан күле череп бара,
Балыгы — чирле, ябык.
Терелтәсе иде күлне,
Берәр дәвасын табып.

Чаң кагасың — ишетмиләр,
Белмим, кемгә язарга?
Бер «Черек күл» болай да бит
Җитеп ашкан Казанга!

## АРХИВТА УЙЛАНУ

Катлам-катлам кульязмалар монда —
Йөрим гүя тарих урманында.

Бер кайтаваз булып үткәннәрдән
Вакыт агып керә кулларыма.

Ак патшалар, байлар заманында
Мең ел элек нинди булган тормыш?
Кемгә каршы кемнәр кылыч тоткан —
Бөртеген дә түкми сөйлә, язмыш!

Кемдер әнә гарәп хәрефләрен
Үзгәртмәкче булып латинчага,
Кулындагы айбалтасы белән
Тарихымның тамырына чаба...

Тән түзәр ул, җан кыйналса читен,
Җанга суккан палач куштаннары.
Аралагыз безне ялганнан, дип
Эндәшә күк «халык дошманнары».

Юк, карадан гына тормый дөнья!
Якты сәхифәләр куя балкып.
Төн эченә йолдыз сипкән сыман,
Гәүһәрен дә күп кабызган халкым.

Сүзсез генә бер өн чыңлап тора —
Кичләрен дә шулай, иртәсен дә...
Сугылмаган арыш көлтәседәй
Ята Тарих архив киштәсендә.

ӘЙ, ТУГАН ҖИР...

Шушы җирдә канат чыгарганмын,
Туган ягым — Байлар Сабасы.
Безгә монда гомер итәселәр,
Безгә монда ямьнәр табасы.

Авыл-авыл булып сибелгәннәр:
Анда Шәтке, монда Иләбәр.
Иген иккән данлы якташларым
Алтын кисәгенә бәрабәр.

Булган заман, булган көмешчеләр,
Койганнары — балдак, беләзек.
Кая киткән шул борынгы һөнәр?
Үткәннәргә, ахры, юл өзек...

Болын буйлап якты Мишә ага,
Зурдан түгел үзе түгелен.
Балачакның көләч көннәрендә
Шул иде бит нәни Иделем!

Кая киткән теге тирәнлекләр,
Ах, саеккан Мишә, саеккан, —
Бездән калган ярның суларына
Тездән кереп баскан саескан.

Саба яктан саба җиле исә,
Туфрагыма, әйдә, баш идер...
Көмеш балдак кулда яшәгән күк,
Легендалар телдә яшидер.

«Байлар» сүзен һәрчак кушып әйтәм:
Туган ягым — Байлар Сабасы!
Безгә монда гомер итәселәр,
Безгә монда бәхет табасы.

АЛМАГА ҮРЕЛҮ

Ниндидер магниты белән
Кызыктырды түбәләрем.
Малай чакта түбәләргә
Бик еш кына үрмәләдем.

Агач башына мендемме,
Гел кояшка үрелдем мин.
Биеккәрәк ашкан саен,
Даһи сыман күрендем мин.

Җирнең әле тарту көче
Безнең өчен алда булган.
Ньютонның кулларында —
Без «татыйсы» АЛМА булган!..

СУ АСТЫНДА КАЛГАН БОЛЫН ҖЫРЫ

Мин кешеләр белән дус яшәдем,
Үзләре дә дус булдылар кебек.
Сөйгән кызын яшел тугайлыкта
Кысып-кысып кочкан иде егет.

Гармун тотып печәнчеләр төшсә,
Алар белән мин дә шаштым, көлдем.
Яшәү көче иде туфрагымда —
Курпы булып кабат күтәрелдем!

Килделәр дә җирне актардылар,
Кешеләргә, белмим, ни кирәктер?
Җаным уяу иде, су астына
Күмде алар тагын бер йөрәкне.

Һәр үләнем, тәнем карышса да,
Көчсез иде минем ялварулар.
Табигатьнең мең ел тырышканын
Бер тәүлектә суга батырдылар.

Хәзер бары төптә, караңгыда
Үле тамыр булып тибә инеш.
Җәйләр җитсә, яңгыр тамчысына
Сусап ятам су астында килеш.

Суларымда — күкнең чагылышы,
Ак болытлар гүя ертык җилкән.
Тояк тавышымы әллә дисәм,
Баш очымда дулкын шавы икән.

Мин төш күрдем... Кара ромашкалар
Каплап киткән, имеш, итәгемне.
Кайтып булыр микән дөньялыкка,
Ни язмышлар көтә иртәгемне?

МИЛӘШ ТУРЫНДА БАЛЛАДА

I

Җәй авышып бара иде көзләргә,
Ромашкалар бәрелеште тезләргә.

Кайнар иде кыз баланың кочагы...
Кабынды җилдә миләшләр учагы.

Мәрҗән ясыйм, диде егет, талпынып,
Кыз күкрәге җавап бирде калкынып.

Түшкәенә ятты кызыл муенса!
Китте алар яшьлек язы буенча...

II

Яңа җәйгә җитәкләшеп керделәр,
Миләш яшел, өлгермәгән — күрделәр.

Өлгергәнен көтәр чама калмады...
Офыкларны кара ялкын ялмады!

Кайчан гына җиңеп кайтыр сугыштан?
Кыз егетнең иңнәренә елышкан.

Басып калды яшел миләш төбендә,
Яшел миләш ачылары — телендә.

III

Алар бар да япь-яшь егет иделәр,
Утка-суга без керәбез, диделәр.

Сазлыкларга төште егет, батмады,
Саклый иде аны сөю хатлары.

Сукты әҗәл — ул монысын белмәде,
Хәтерендә кызыл миләш дөрләде...

Кайтмый калды егет туган йортына.
Каберендә миләш үсеп утыра.
jjj

«Куркынычлы» диеп, китапларны
Учакларга яктык.
Бөгәрләнеп сүзләр янган чакта
Кайда идең, хаклык?

Искелек дип, мәчет-чиркәүләрнең
Нигезләрен ваттык.
Айлы манаралар ауган чакта
Кайда идең, хаклык?

Туры сүзле асыл егетләрне
Сайлап-сайлап аттык.
Диварларга кан чәчрәгән чакта
Кайда идең, хаклык?

Ялган пәрдәләрне ертып атты
Илгә килгән аклык.
Мең газаплар аша эзләп таптык,
Китә күрмә, Хаклык!

ЧЕРНОБЫЛЬДӘН СОҢ...

Сызымнар сөйли, аңлата:
Шундый бер көн киләчәктер, —
Кама буендагы Алан
Илгә атом бирәчәктер...

Яшәү өчен торак кирәк,
Планнарны үтә генә!
Тиражлап-тиражлап әнә
Яңа йортлар күтәрелә.

Җирне казып керә-керә,
Тәмам түргә атлаганнар.
Кызыл авызларын ачып,
Өнсез ята котлаваннар.

Техниканың беләкләре
Тау-таш яра — ни горурлык!
Бер котлаван эчләренә
Авыл кереп утырырлык.

— Юк, кирәкми мондый хәвеф!
— Илгә кирәк энергия!

Әнә шулай дия-дия
Бәхәсләшә ике төркем.
Хакыйкатьнең чын дөресен
Әйтеп бирә алмый беркем.

Атом-сарай кирәктер ул —
Ышанычлы булса гына,
Яшәмәсә табигатьне
Рәнҗетүләр хисабына.

Күрсәтмәләр өстән килә,
Кысып ала тормыш астан.
Үз-үзеңә яман кабер
Казый күрмә, Татарстан!

ЯШЕЛ КҮЗЛЕ МАЛАЙ

Җәйне яратканга күрә
Күзләре яшел иде.
Чирәмнәрдә уйный-уйный
Тезләре яшел иде.

Суларга карап бакты ул,
Күкләргә карап бакты.
Җаны чиста булгангамы,
Дөньялар — гаҗәп якты!

Яфрактан яфракка тамган
Түгәрәк тамчы кебек,
Бөреләнде күңелендә
Түгәрәк кенә өмет.

Шул өмете коймалардан
Йолдызга кадәр чөйде, —
Чөнки күршедәге йортка
Кунак кыз килгән иде!

Бантиклап үргән чәчләрен
Тотып карыйсы килде.
Күбәләктәй чәчтасмасын
Сүтеп карыйсы килде.

Әллә ни булды малайга —
Үзгәреп китте кинәт.
Канатлы йолдыз җилләре
Кагылган аңа, димәк.

Койма ярыгыннан кызны
Көн саен күреп алды.
Кунак кызның елмаюын

Курайга төреп салды.

«Яшел» иде мәхәббәте,
Күзләре яшел иде.
Әйтер сүзләре, моң булып,
Курайга яшеренде...

## СЕБЕРЛӘРНЕ КИЧКӘН АЗАМАТ

*Хәсән Туфанга*

Әйтерсең лә бүтән җилләр исә,
Бүтән карлар күктән агыла, —
Теге якта — төрмә коймасының
Карцерлардан азат ягында...

Бер узар да китәр зарлы көннәр,
Үз үлемең чиксез күренә.
Эндәш, заман! Нинди сугымчылар
Оялаган илнең түренә?

Тәүлек саен төрмә капкалары
Кара китап булып ачыла, —
Язмышларны кемдер яза шулай,
Ә каләме... канга манчылган!

Мөмкинме соң сезнең туфанлыкны
«Таш капчык»ка ябып куярга —
Тукайлардан калган гамь барында,
Җанда әле якты уй барда?

Яза Туфан... Сакчы күзләреннән
Урлый-урлый яза шигырен.
Казанына таба баккан саен,
Уйлар азат, уйлар йөгерек.

«Эх, бер йотым ирек!» — дия-дия,
Җаны күпме бәргәләнмәсен,
Этапларны узган чакларда да
Югалтмаган асыл мәгънәсен.

Еллар үткәч, карыйм рәсеменә:
Ак чәчләре гүя ак җилкән.
Ирек эзләп киткән олпат иргә
Җырдан һәйкәл салыр чак җиткән.

Дөнья гамен тоя белүчеләр
Тукайлыкны үлчәп карасын:
Ак кәгазь һәм каләм — шагыйрь өчен
Яшәү белән үлем арасы!

## БҮГЕН!

Нинди була утның үлгән мәле,
Нинди була гүзәлләрнең тәне,
Нинди була хакыйкатьнең тәме —
Ахыргача белгәнем юк әле...

Үзең теләп, үзең сорап түгел,
Ходайныңдыр, бәлки, көче белән —
Яшәп карасын, дип, төрле холык,
Төрле гакыл безгә иңдерелгән.

Кемдер өчен күкнең биеклеге
Соры болытларга чаклы гына.
Ап-ак каен — кемдер өчен «утын»,
Күпләр исә
Табынып яши аның аклыгына.

Вәхши затлар, кара күзлек киеп,
Чыгып баса кояш каршысына.
Берәү ялгыш ботак сындырса да,
Урын тапмый яши намусына.

Өйрәтәләр: кеше күңелендә
Яхшылыклар уты мул, янәсе.
Ник соң өстен чыга көчлеләрнең
«Мин көчлемен!» дигән фәлсәфәсе?

Тигез түгел дөнья: көтмәгәндә
Коендыра язмыш — безга мана...
Җитмеш җиде катлы иләк аша
Узгармакта безне бу замана.

Хакыйкатьнең хакыйкатен эзлим:
Нәрсә соң ул — Туу, Яшәү, Үлем?
Ак һәм кара төсләр уртасыннан
Җавап табу кирәк миңа бүген!

## УТЫЗЫНЧЫ АВГУСТ

Әле сине өстән өркетәләр,
Тарткалыйлар сине әле астан.
Татар халкы дигән җисемеңне
Саклап кала килдең, ТАТАРСТАН!

Ут һәм кылыч белән куркытканнар:
Көл буласың яки кол буласың...
Шул чакта да югалтмаган халкым
Догасын һәм якты кыйбласын.

Дүрт гасырлык тарих катламнарын
Ватып-ярып чыкты байрагыбыз!
Яшь барстай япь-яшь Ватанымның
Мускуллары инде, ай-һай, тыгыз.

Рәсәй белән мөнәсәбәтләрне
Тигез итеп корыр чакларыбыз.
Берәүне дә рәнҗетерлек түгел
Мәртәбәле, горур хакларыбыз.

Сөембикә манарасы сыман,
Илем-җирем аягүрә баскан.
Йөрәгемдә бүген җыр тирбәлә:
Яшә, сөеклебез ТАТАРСТАН!

## ТАТАРСТАН ТУРЫНДА МОҢСУ ҖЫР

Дәүләтенме югалтканга күрә,
Көче беткән нәсел-ыруның.
Чикләрең дә тормый инде хәзер
Урал-Алтайларга орынып.

Күпме генә сулар бөркесәк тә,
Безнең хыял — шиңгән чәчкәдер.
Басуларны тимер тутык баскан,
Нефть байлыгыннан ни кадер?

Коттеджлар гөмбә сыман үрчи —
Кемнәрнедер байлык сикертә.
Илгә төшкән бөтен авырлыкны
Авыл халкы тарта кич-иртә.

Су астына салым итеп салдык
Бабайлардан калган урманны.
Балтыйк буе илләреннән әнә
Ишетәбез бүтән җырларны.

Җилләр безне юатмакчы була:
Тәкъдиреңә, туган, түз, диптер.
Бу Рәсәйне бурлак сыман тартып,
Сөйрәп бару — бәхетсезлектер.

И котлыйсы һәм сөйлисе иде
Бәйсез Татарстан турында!
Танк тавышларын күмә-күмә,
Өмет кайный әле җырымда...

ИКЕ БАШЛЫ!..

Байгуралар балда-майда йөзде,
Хәерчеләр үсте җил кыйнап.
Дөньяларны әйләндереп салды
Унҗиденче елгы инкыйлаб!

Авып төште тарих чүплегенә
Ике башлы тугра-каракош.
Вәгъдә яуды: Рәсәй халыкларын
Без ирекә алып барабыз.

Тел вә лөгать, икмәк уртаклашып
Яшәп алдык шулай җитмеш ел.
Чабатадан — космосларга кадәр:
Бер уйласаң, алга китмеш ел...

Империя! «Женең» йокламаган,
Рәсәй тагын дулый, үртәлә —
Ике башлы тугра-каракошын
Дәһшәт белән өскә күтәрә.

«Демократик» кыланышларына
Карап тора дөнья шаккатып:
«Empire of evil»[1] яңабаштан
Гайрәт чәчә, туплар шартлатып!

Ике башлы «кош»ны терелттеләр,
Күз төбәгән болар кай якка?
Ике башлы усал каракош күк
Ике башлы була таяк та!

ИСӘНМЕ, САБАНТУЙ!

Җырлары һәм гармуннары белән

Сабантуйлар килде әйләнеп.
Ап-ак һәйкәл гүя калкып чыккан:
Авыл саен — сөлге бәйләме!

Тамаша кыл, күңел ач син бүген,
Биеп җибәр, әйдә, булмаса!
Болынлыкны яшел постау итеп,
Табын кора туган-тумача.

Бабалары, моңы — Иделдәндер,
Сибелгән шул татар, сибелгән.
Туган җирен сагынып кайта алар
Донбасслардан, ерак Себердән.

Туган якның чишмәләре тәмле,
Җилләренә хәтле, һәй, тыгыз.
Кардәшләрем, кунак булып түгел,
Бөтенләйгә инде кайтыгыз!

«Бу бит безнең Ватан!» — дия-дия
Шатланыйк без, уйныйк, гөрләшик.
Татарларым!
Сабантуйда сыман,
Яшәүдә дә мәңге берләшик!

## ЯЗГЫ СУРӘТ

*...гә*

Калкып чыктың кайсы елның языннан,
Ни язмыш ул — учларыңда язылган...
Күңелне уятыр, сызлатыр өчен
Килдеңме әллә йолдызлар багыннан?

Чәчкәйләрең агып төшкән — билеңнән,
Сүз әйтергә сусап торган иреннәр...
Синме бу ерып киләсең язларны —
Бер чәчәк — Яшел Үзәннәр иленнән.

Нурларың тылсым-кояшка тиң генә,
Язларны, ахры, китерден син генә.
Мин ышанмас та идем могҗизага —
Күр: чәчләреңнән йолдызлар сибелә.

Нинди гамьнәр кунды: дөнья үзгәрде,
Бар галәм тутырды минем күзләрне.
Ах, каләмем төште-китте кулымнан!
Җан белән уеп язамын сүзләрне.

Офыкларда өр-яңа көн кабынган,
Кул болгыйм сиңа мәхәббәт тавыннан.
Күңелне уятыр, егълатыр өчен
Төштеңме әллә йолдызлар багыннан?

## АЛМАГАЧ

Күр: загс баскычларыннан
Бергә атлап төшкәннәр...
Сөю агачы утырта
Яңа өйләнешкәннәр!

Кулларында, үзләре күк,

Алма бирер алмагач.
Икесенә — бер мәхәббәт,
Икесенә — бер агач.

Бәхетле парлар туфракка
Сала күңел яктысын:
Сулыйсы сулышларыбыз
Гомергә уртак булсын!

«Сукыр» дисәң дә, мәхәббәт
Алдамас ул, алдамас:
Ак бөркәнчек япкан кәләш —
Шау чәчәкле алмагач.

Кояшлы, алмалы көннәр
Якындадыр, якында.
Бөрегә узган һәр агач
Сөйли яшәү хакында.

Яшәргә һәм нык торырга
Тиешлеген аңлагач, —
Еллар җебен чорный-чорный
Үсеп җитәр алмагач.

Сизгер җаннар тояр беркөн
Күз китергән чынлыкны:
Өзелеп төшкән алма шавы
Сискәндерер тынлыкны!

Ә хәзергә... кулларында
Алма бирер алмагач.
Икесенә — бер мәхәббәт,
Икесенә — бер агач...

ТУГАН ЯК КАДЕРЕ

Сагынулар чорнап алган чакта,
Белмим, нинди дәва табасы?
Ярты җаным һаман синдә яши,
Туган ягым — Байлар Сабасы!

Алмаларның исе нидән татлы,
Әрем исе була ник әче?
Шатлыгым да, сагышым да булып
Син яшисең җанда, Теләче!

Гомер диген —
Арта гына бара
Туган якларымның кадере.
Ике яктан кушуч туфрак белән
Ныгыталар минем каберем.

ТӨН

Башкаеңны иңнәремә салдың —
Җиңел, татлы иде бу мизгел.
Шушы кичтә кайнар иреннәрне
Сөю шәрабына тигездем.

Чәчкәйләрең биткә сибелде дә
Урап алды мине «буран»га.
Өр-яңадан мин әйләнеп кайттым
Яшьлек диган якты урамга.

Кулларыңны күкрәгемә куйдың,
Сагышларны читкә таратып, —
Йөрәгемне гүя сыйпап узды
Карлыгачның нәфис канаты.

Башкаеңны күкрәгемә куйдың,
Бар дөньяма ялкын сикерде.
Җир шарына тәңгәл авырлыкны
Мин күтәреп тордым шикелле.

Назга юлыктымы, ирләр җаны
Яхшылыкка таба үзгәрә.
Хатын-кызның серен аңлар өчен
Серле булу кирәк безгә дә...

## НИШЛӘТТЕҢ?

*Мәхәббәт фасыллары*

Челтер-челтер сулар типкән чакта,
Элек язлар бүтәнчәрәк иде.
Гөрләвекләр тулып йолдыз ага —
Син нишләттең мине?

Шомырт ботагында тибрәп үстек,
Шомырт ашап теш камаша иде.
Шомырт күзләреңнән җан камаша —
Син нишләттең мине?

Урманнарда яфрак яуган чакта,
Элек көзләр бүтәнчәрәк иде.
Сары яфрак булып күктән тамам —
Син нишләттең мине?

Узып бозлы тәрәзәләр аша
Синең сулыш битләремә тиде.
Кар өстендә гөлләр чәчәк ата —
Син нишләттең мине?..

## ТӨНГЕ СӘФӘР

Автобусның җылы салонында
Төнге сәфәр. Йоклый юлдашларым.
Күңелемә тынгы бирми һаман
Тун эченә поскан иңбашларың.

Чит күзләрдән яшеренеп кенә
Бармакларны тешләп карасак та,
Киртә корып, безнең арабызда
Язмыш үзе уяу тора сакта.

Тәрәзәнең пыялаларына
Тияр-тимәс кагылышып әнә,
Күрәсеңме, ап-ак карлар булып,
Минем җаным шулай бәргәләнә!

Эзләр калыр, сүзләр калыр безнең —
Мең елдан соң тагын шушы карлар,
Нәкъ бүгенчә итеп, колагыма

Исемеңне синең пышылдарлар...

Үткәннәргә кайту микән соң бу,
Киләчәккә әллә барышыбыз?
Ни булса да, безнең күңелләрне
Бәйләп тора уртак сагышыбыз.

Безнең күзләр әле очрашырлар,
Сабыр итик таңга чаклы гына.
Бармак түгел, хәтта йөрәгем дә
Килеп капты сөю капкынына!

## КОЯШ ТУРЫНДА ҖЫР

Син миңа әнидер, әнидер...
Күңелең еш кына әрнидер.
Булды бит хәсрәтле чакларым —
Син мине давылдан сакладың.

Син миңа ападыр, ападыр...
Уйларың үткәнгә кайтадыр.
Кул селтим дөньяның малына,
Чын бәхет китердең җаныма.

Син миңа сеңелдер, сеңелдер...
Гомерләр мәңгелек түгелдер.
Алдыңа моң булып түгеләм:
Син — кояш! Мин — тамчы, мин — үлән.

Син миңа кыз бала, кыз бала...
Мең төрле гамьнәрем кузгала.
Сөюнең мәгънәсен бел икән —
Яшәүләр, уйласаң, гөл икән.

Янартау йокламый, йокламый,
Кирәксә, йөз елдан уяна.
«Белегез, мәхәббәт бар ул!» — дип,
Чаң сукты йөрәгем дөньяга...

## СИН ӘЙТТЕҢ...

«Кояшым!» — дип, син эндәштең миңа...
Үз-үземнән торам оялып.
Дөнья чаклы шундый олы сүзне
Ничек уйлап тапты хыялың?

Син барында — ничек инде мине
Кояш белән мөмкин тиңләргә?
Ай шикелле салкын планета мин,
Серле язмыш минем иңнәрдә.

Үз-үземнән сорау алам бүген,
Һәм орышам мәҗнүн-егетне, —
Ничек итеп ычкындырдым икән
Сүз әйтүдә беренчелекне?

Эзләп табып синең күзләреңне
Миллионлы шушы шәһәрдә.
«Кояшым!» — дип, иң беренче булып,
Мин тиешле идем дәшәргә!

Шулай балкый алыр идеммени —
Син нурыңны сирпеп тормасаң.
Бары синең, синең нурланыштан
Мин яктырам, мине моң баса.

«Кояшым!» — дип, мине газаплама,
Мин Ай булып барыбер калырмын.
Чиләк-көянтәле Зөһрә итеп
Үз яныма тартып алырмын.

Мең йолдызлы Галәм сукмагыннан
Барасы да безгә барасы...
Нинди якын
Һәм нинди дә ерак
Кояш белән Айның арасы!

«ТОТКЫН»

Ничәнче көн, ничәнче төн инде
Бәргәләнә җаным, үртәлә —
Үзем теләп, үз кулларым белән
Килеп каптым менә төрмәгә!

Чәнечкеле тимерчыбык белән
Чорналмаган юкса көннәрем.
Йөрәкне тик кадап-кадап ала
Роза гөлнең чәнечкеләре...

Бар гаебем шунда булса кирәк:
Сикергәнмен кайнар упкынга, —
Мәхәббәткә дучар ителдем дә
Әверелдем сәер тоткынга.

Тоткын икән, тоткын язмышыдыр —
Тамчы суга көн дә тилмерәм.
Бер тамчы су белән гомеремне
Озынайтсаң икән, бер генәм!

Сакчылар юк, әмма билгесезлек
Басып тора безнең арада.
Коткар мине сөю төрмәсеннән,
Әсирлектән, зинһар, арала!

Хәер, нигә мине араларга
Тоткынлыктан, мондый газаптан?
Мең кат янгач кына
Үз-үземә
Хөкем чыгарырмын азактан...

МӘХӘББӘТ МӘРҖӘННӘРЕ

Малай чакта мәрҗән тезгән идем,
Тезгән идем яшел миләштән.
Үзем генә белгән мәхәббәтем
Әй, «яшел» булган соң ул яшьтә!

Егет чакта мәрҗән тезгән идем
Күк тутырып, кайнар йолдыздан.
Әле дә булса йолдыз сәламнәре
Килеп тора миңа ул кыздан.

Инде менә тагын мәрҗән тезәм,
Берәм-берәм тезәм сүзләрдән.
Җанда сөю — һаман шул ук икән!
Еллар гына бары үзгәргән.

Мәрҗән-мәрҗән тезәм елларымны:
Мин ни кылган, ниләр майтарган?
Күңел — һаман унҗидедә икән,
Еллар гына — бераз картайган...

## СИНЕҢ ҖАВАП

Мин елмаеп кына дөнья үзгәрерме?
Шундый сорау бәргәләнә җанда.
Бер уйласаң, тормыш — соры агым,
Матурлыклар юктыр кебек анда.

Урамнарга чыксаң, сүрән йөзле
Бәндәләргә бик еш юлыгасың.
Билен бөгеп михнәт куа халык,
Түрәләрнең гәүдә туры да соң!

Кая барма, кыса соры ташкын:
Трамвайлар — гүя шырпы кабы.
Ишетелә дөнья арбасында
Мең-мең язмышларның кыштырдавы.

Кояшлы җыр эзләп килә-килә,
Байтак канаттым мин тезләремне.
Үз-үземнән сорау алам бүген:
Мин елмаеп кына
Яхшырырмы дөнья, үзгәрерме?

Үзгәрер!
Шулай җавап бирә күзләрең...
Һәм яктырып китә көзләрем.

## СЕЗГӘ МӘДХИЯ

Бәхетле яшәсен Идел-йорт,
Хәвефсез йокласын бәбиләр.
Язларны, назларны дөньяга
Сез бүләк иткәнсез, ӘНИЛӘР.

Гасырлар түрендә җемелди
Беләзек, хаситә, алкалар.
Сез дә бит, кояштай нур чәчеп,
Бизисез тормышны, АПАЛАР.

Без дә бит сөюгә сусаган,
Канатлы — безнең дә күңелләр.
Мәхәббәт бакчасы багында
Иң матур чәчкә сез, СЕҢЕЛЛӘР!

## ИЛБАШЫНА БЕЗНЕҢ ТЕЛӘКЛӘР

Әле сине өстән өркетәләр,
Тарткалыйлар сине әле астан.
Татар халкы дигән җисемеңне
Саклап кала килдең, Татарстан!

Бездән соң да бик күп язлар килер,
Тарих кайнап торыр, әлбәттә.
Әмма ләкин бүген СИН кирәкле
Татарстан дигән дәүләткә.

Мәскәүлеләр әнә яңабаштан
Эләктермәк була якадан.
Дәүләтчелек дигән хәзинәбез
Кайтыр кебек әле яңадан.

Исемеңдә тимер чыңлап тора,
Җисемеңдә — мәрмәр ныклыгы.
Туган телдә сөйли белгән өчен
Тыңлау рәхәт сине йотлыгып.

Милләтебез, дәүләтебез өчен
Син җаваплы. Без дә җаваплы!
Шушы юлда фидаилар булсак,
Кызганмастыр Ходай савапны.

Балкып торган, үзенә тартып торган
Татарстан дигән бу алмаз —
Хәтәр елларда да югалмады,
Президентлы чакта югалмас,
Югалмас!

ТЕРЕКӨМЕШ

Кушаматлар бакчасында беркөн
Миңа да бит урын таптылар:
Дус-ишләрем, Терекөмеш диеп,
Тоттылар да исем тактылар.

Бармак төртә-төртә куаналар,
Туры килә, имеш, мәгънәсе, —
Тормышта мин, терекөмеш сыман,
Бик йөгерек кеше, янәсе.

Туган якның йөгерек суларыннан,
Җилләреннән алдым җитезлек.
Эчке яну ашыктырган саен,
Бөтреп ала мине бу тизлек.

Бардыр миндә, бардыр кабалану,
Һавалану бардыр кайвакыт.
Энҗе дигәннәрем таш булса да,
Юк, йөрмәдем сару кайнатып.

Күктә түгел, күкрәк читлегендә
Яшәгәнен белдем яшеннең...
Чөйде язмыш, җиргә атып бәрде —
Терекөмеш сыман чәчелдем!

Караңгыда калсаң, чәчелгәнне
Ничек кенә җыеп аласы?
Үз кояшын тагын эзләп килә,
Эзләп килә адәм баласы.

Чыңлый-чыңлый алга дәшә еллар,

Чү, йөрәгем, булчы түземле.
Чәчелдем дә... инде яңабаштан
Мин бөртекләп җыям үземне.

ЧУКЫНДЫРУ

Империя!
Күпме халыкларның
Маңгаена кылыч тидергән.
Идел-йортта үскән ирекленең
Кулларына богау кидергән.

Богау нәрсә — ул да шартлап сына,
Үч һәм нәфрәт әгәр дуласа!
Халык бетсен дисәң, туган телнең
Тамырын кисү кирәк лабаса...

Ильминский әнә китап яза,
Фәннилеккә дәгъва кылмакчы:
Җирен генә түгел, «инородецлар»ның
Рухын-җанын буйсындырмакчы.

Ул елларда мәчет кенәме соң
Туздырылган, төптән кырылган...
Бу Рәсәйнең һавасына тикле
Сөрем белән чукындырылган!

...Үзгәргәндер, бәлки, елмаюлар,
Дипломатик алым, кыяфәт;
Тик бүген дә Рәсәй кулларында —
Шул ук ладан, шул ук сәясәт.

Урыс телле интерсөйләм белән
Чуарланды туган йортыбыз.
Кайчан, кайчан саф татарча итеп
Сөйли башлар парламентыбыз?

Попларны күр — татар хәятына
Сөйрәп керә тәре сурәтен.
Ике динне чәкештерү өчен
Форсат эзләп йөри, күрәсең.

Мәскәүгә ни — читтән көлемсерәп,
Мыштым гына карап торалар...
Әй, татарым! Көпә-көндез сине
Икенче кат чукындыралар!

БЕЗНЕҢ ЗАМАН

Дөнья аек, шулкадәрле аек —
Таңнар ата нәкъ вакытын белеп.
Сары шәлен сөйрәп көзләр китә,
Җылы якка киткән кошлар кебек.

Тормыш аек, шулкадәрле аек —
Кулалмашка компьютерлар килде;
Ничек-ничек яшәү таблицасын
Алар яттан әйтеп бирә инде.

Эчәр суларыбыз агулана,
Үлә намус, үрчи кыңгыр эшләр.
Дөнья сәрхуш, шулкадәрле сәрхуш —
Анда сугыш, монда түнтәрешләр.

Тормыш сәрхуш, шулкадәрле сәрхуш —
Министрлар эчә, эчә тиречеләр.
Илне кая илтеп терәр икән
Балда-майда йөзеп йөрүчеләр?

...Дөнья аек, шулкадәрле аек —
Таңнар ата нәкъ вакытын белеп.
Көн дә иртән кояш калкып чыга
Биш тиенлек бакыр акча кебек!..

## КЫЗЫЛ ТАМЧЫЛАР

*Донор хатын монологы*

Якадан тотып сорый замана:
«Малыңмы, — диеп, — әллә җаныңмы?»
Җавабым әзер — үз иркем белән
Мин тапшырырга тиеш канымны.

Кызыл җеп булып сызыла язмышым,
Ап-ак халаттан мендәрдә ятам.
Тәнемне түгел, яшәү хакына
Мин бит нибары канымны сатам.

Ашатасым бар, яшәтәсем бар
Газиз баламны — күзем карасын.
Байбәтчә үзен хет бер минутка
Минем урынга куеп карасын!

Без инде күргән, күргән-кичергән,
Читен — илеңне тулгак тотканда.
Ничекләр шулай үтеп керде соң
Шөкәтсез заман безнең йортларга?

Берәм-берәмләп хәтергә тама
Кызыл тамчылар — кызыл калкавыч.
Чалыш көзгеләр илендәме мин, —
Бии каршымда мираж-алдавыч!

Рәхәт күрәләр бездә түрәләр —
Бүгенге көннең «яңа» байлары...
Бер чиртсәң әгәр маңгайларына,
Чәчрәп чыгарга тора каннары.

## БАШ МИНИСТРГА АЧЫК ХАТ

Килде заман: акча көшелләрен
Кайберәүләр үзенә көрәп ала.
Кемдер — «иномарка», кемдер исә
Бакча казыр өчен көрәк ала.

Кая гына китеп олагадыр
Хәрәм акча — ансын шайтан белсен.
Эшләп тапкан хәләл акчам исә
Китеп бара салым түләр өчен.

Салымчылар акча җыя бездән —
Юлларыбыз булсын диеп такыр.
Бактың исә тирә-ягыбызда
Ватык асфальт һәм дә чокыр-чакыр.

Сәламәтлек саклау фондларына
Салым итеп салам байлыгымны.
Шулай булгач, кешеләрчә итеп
Сез саклагыз инде саулыгымны.

Милиция көн-төн тәртип саклый —
Монсына да, әйдә, салым давай!
Тик кемнәрне күбрәк яклый икән
Безнең кызыл фуражкалы агай?

Тагын әнә кеше үтергәннәр,
Ил өстендә тагын кайгы туе.
Без түлибез... Безнең иминлекне
Шулмы — хөкүмәтнең кайгыртуы?

Салымчылар — оста «савымчылар»,
Илдә һаман туксан тугыз тишек.
Шул тишекне томалаучылардан
Сорасалар икән: «Хәлең ничек?»

Сорамыйлар...
Халык кына бары
Янәшәмнән агыла төркем-төркем.
Гаҗәпмени: сулар һаваң өчен
Салым тота башласалар беркөн!

ФЕВРАЛЬ

Түбәгә җиткерде көртләрне,
Лапаска качырды этләрне.

Инешләр-елгалар боз гына,
Урамда җил-буран сызгыра.

Калтырый сыерчык оясы —
Кар белән тулгандыр дөньясы.

Бакчада шыкырдый саескан,
Көн инде язларга авышкан.

Усал кыш күтәрер чаңгысын,
Песнәкләр җырында — язгы чың!

jjj

Бәгырь катты минем бу тормышка:
Учак ягыйм дисәң — чи утын.
Чүкеч белән чигәләргә сугып,
Уйны изә һәрбер минутың.

Ак төсләрне җилләр урлаганмы?
Соры төсләр итә тантана.
Ничек итеп җырлар язмак кирәк —
Аккош каурыеннан кан тама...

Кинәт кенә күкләр почмагыннан
Сикереп төшә өмет йолдызы!
Учындагы алтын Кояш шарын
Суза миңа шулчак таң кызы.

Сулык-сулык бәгырь бәргәләнә,
Дөрләп янып китә чи утын.
Гасырга тиң озынлыклар белән
Уза башлый, гомер, минутың.

## АЙ БАРЫБЕР ӨСТӘ!

Нинди өннәр килә
Туфрактан һәм таштан?
Чиркәү тәреләре
Аягүрә баскан.

Килмешәкләр килеп
Чиркәү салдырганнар.
Ватанымның күген
Айсыз калдырганнар.

«Тавык тәпиләре»
Күкне чукындырган.
Ялгызак бер болыт —
Чираттагы корбан.

Күңел бәргәләнә:
Чынмы, әллә ялган?
Ай сурәтен тәре
Аска егып салган.

Бәхәсләшә алам —
Юк, тутыкмый алмаз!
Ислам мәгыйшәте
Аста ятып калмас.

Иман нуры безгә
Кайта яңабаштан, —
Күпме манаралар
Зәңгәр күккә ашкан.

Син кизәнмә, кяфер,
Татар дигән көчкә...
Төнге күккә кара —
Ай барыбер өстә!

## КӨТҮЧЕ СУМКАСЫ

Исеме дә сәер бу үләннең,
Ә җисемен инде кем белгән...
Бер йолдызлык булып тәлгәшләре
Зәңгәр күккә әнә чөелгән!

Басу юлларында йөргән чакта
Юлыктым да шулай мин аңа, —
Кайтып төштем Балачагым дигән
Хыялый һәм татлы дөньяга.

Күршедәге Хаҗиәхмәт абый
Көтү көтә... Авыл малларын.
Чыбыркысын айкап шартлата да
Уята ул авыл таңнарын.

Чыбыркысы кичен юашланган —

Бөгәрләнеп ята тын гына.
Безне дәшеп, Хаҗиәхмәт агай
Күн сумкасын ала кулына.

Күчтәнәчләр насыйп икән безгә:
Берсен-берсе шулай җитәкләп, —
Сумкасыннан килеп чыга аның
Ак сабаклы кызыл җиләкләр.

«Куян күчтәнәче» дия-дия
Суза безгә икмәк катысын.
Учак исе сеңгән ипекәйнең
Валчыгына кадәр татлы соң!

Ә кайчакны сумка кесәсеннән
Балтырганы чыга, какысы.
Кыр-болында үскән һәр үләннең
Телен белгәндер ул, ахрысы.

Гап-гади бер авыл көтүчесе —
Арыш серкәсенә буялган.
Сумкасына түгел,
Җанына да
Ярты дөнья кереп сыялган.

...Әй, үләнем!
Очраттым да сине
Кыр читендә, басу юлында,
Якты истәлекләр кузгаттың син
Хаҗиәхмәт абзый турында.

## БУЛАЧАК РӘССАМ

Дөнья аңа карыйдырмы-юкмы,
Ул — дөньяга гаҗәпләнеп карый:
Бал кортлары әнә чәчәкләрнең
Һәрбер таҗын берәм-берәм саный.

Чикерткәнең әзерләнгән чагы
Скрипка уйнау хәстәренә.
«Музыкант»ның яшел канатларын
Төреп салды күңел дәфтәренә.

Күбәләкләр нәни җил чыгара,
Нәни канатлары белән тирбәлешеп.
Җирдән алып күккә кадәр булган
Бөтен матурлыклар — зәңгәр бишек.

Табигатьнең күчеш-әйләнешен
Кемнәр аңлый икән, кем соң белә?
Үлән арасында үскән Чәчәк
Кояш булып күккә күтәрелә.

...Тормыш безне әле өскә чөя,
Кайчагында йолкып ала аска.
Куркып калдым: ничек тә бит кирәк
Бу малайга үзен югалтмаска!

## УРМАН КОШЫ

Бакчадагы җиләкләрне
Чукып-чукып киткәнсең.
Кызгылт чияләремнән дә

Бераз авыз иткәнсең.

Үпкәләмим, безнең өчен
Калганы да җитәрлек.
Ләкин талантыңа синең
Тәмам исең китәрлек!

Рәхмәт инде, «рәхмәт»еңне
Җырың белән кайтардың.
Таңнар саен сайрый-сайрый
Хәйран эшләр майтардың.

Сайрауларың һәр чәчәккә
Шифалы тәэсир итте, —
Һәммәсе дә бал кортларын
Үзенә әсир итте.

Җырың белән баеткансың
Чәчәкләрне нектарга.
Урманыңда насыйп булсын
Сиңа тыныч йокларга...

## ЮКСЫНУ

*Олы Мишә авылына кайткач...*

Гади генә агач мәктәп иде,
Күпме шунда белем эстәдек,
Ил кайгырса, без дә кайгырыштык,
Шатлык килсә — шатлык өстәдек.

Дәфтәр битләренә яза идек
Фәлән сыйныф, мәктәп, башлангыч...
Еллар үткәч, күрәм: һәр почмагы,
Төсе-кыяфәте — ташлангыч.

Кемнәрдер бит бүрәнәсен өйгән,
Кемдер япкан такта түбәсен.
Йөз ел яшәр диеп уйласак та,
Вакыт барыбер талкый, күрәсең.

Бу тормышта сагыш-моңсулыклар
Килә безгә бары соңыннан.
Күрче, мәктәп тәрәзәләренә
Аркылыга такта сугылган.

Бушап калган кәрәз эчләредәй,
Тәмам бушап калган бүлмәләр.
Безнең күңел тәрәзәләрендә
Якты утлар исән, сүнмәгән!

Таш мәктәпнең диварлары биек,
Кирпеченнән күзләр камаша.
Киндер букчалардан йөресәк тә,
Кеше була алдык лабаса.

Чү, кыңгырау таккан атлар узды,
Сискәндереп күңел урманын.
Бертуктаусыз чыңлый бүген җанда
Кыңгыраулы мәктәп елларым...

## ТУПЫЛ МАМЫК ОЧЫРА

Табигатьнең шундый вакытлары —
Әй котыра тупыл мамыклары!

Ничек ычкынырга белми, каһәр, —
Ак җәтмәдә бәргәләнә шәһәр.

Сабагыннан өзелгән дә бары —
Оча гүя тузганаклар шары.

Нәни көчекне син күрче-бакчы —
Шушы шарлар белән уйнамакчы.

Тула мамык бакча эчләренә,
Ханымнарның бөдрә чәчләренә.

Ир уйланып, туктап калды бертын —
Ак чыбылдык итеп
Юксынадыр авылдагы йортын.

Күзли ГАИ юллар бәрәкәтен,
Тик тыялмый мамык хәрәкәтен.

Уйный алар җилдә әйлән-бәйлән,
Малайларга исә ап-ак бәйрәм!

Кырысланган урам себерүче —
Кая бакма, шунда мамык көче.

Исе китми генә мамыкларга,
Шаулый Идел, сугылып бетон ярга...

## ТАМГА ТУРЫНДА БАЛЛАДА

*(1942 ел фаҗигасе)*

### I

Фронт икмәк сорый!
Ил язмышын
Кайгыртырга кирәк иң элек.
Һәркем бүген сугыш йөген тарта,
Колхоз тәртәсенә җигелеп.

Рәис итеп сайладылар аны,
Миннехуҗа — юньле хуҗа, дип.
Һәм, чыннан да, шактый тиз арада
Күтәрелеп китте хуҗалык.

Белеме юк. Эшкә җикте ләкин
Игенчелек серен, кодрәтен.
Култамгасы итеп сайлады ул
Урак белән чүкеч сурәтен.

Кул куясы булса кәгазьләргә,
Рәхим итеп сала тамгасын.
Көне-төне кырдан кырга чапты,
Берүк, диеп, бездән калмасын.

Вакытында төште яңгырлары,
Вакытында исте җилләре.

Кайтты ашлык ындыр табагына —
Өлгер генә бары җилгәреп!

Колхоз рәисе Миннехуҗа
Исәп-хисап корды төн ката.
Фронт өчен план үтәлә, дип,
Үзен-үзе эчтән юата.

Киләсе ел өчен амбарларга
Фәлән центнер орлык-симәнә...
«Иген иккән авылдашларыңны
Оныта күрмә инде син әнә».

Ындырдагы ашлык көшелләре
Әнә шулай итеп бүленде.
Ул йокларга яткан гына иде,
Кандай кызыл таң да беленде...

II

Берәрсеме барып әләкләгән,
Көнләшепме хәбәр иткәннәр —
Колхоздагы хәләл «урожай»ны
Тикшерергә килеп җиткәннәр.

«Йә, җавап бир, илнең байлыгына
Син хуҗамы, дәүләт хуҗамы?»
Шулай дия-дия караңгыда
Апкиткәннәр Миннехуҗаны.

Иманыннан кире кайтмаган ул,
Кыйнаулардан гәрчә егылган.
Шул минуттан, «халык дошманы» дип,
Яңа тамга аңа сугылган.

Ак-караны оста бутаганнар!
Кая инде халык дошманы —
Җиңү өчен, авыл өчен иде
Бөтен җаны-күңеле кушканы.

Колхоз малын симәнәгә түгел,
Үзе өчен, имеш, яшергән...
Чәнечкеле ГУЛАГ өсләрендә
Ике яклап уйный яшеннәр.

Култамгасын безнең Миннехуҗа
Хәтәр сайлаган шул ул чакта:
Чүкеч аны чүкеп кенә тора,
Урый урак үткер кочакка.

Мәңгелек туң катламнары белән
Җелегеңә үтә Колыма.
«Сезгә монда череп каласы...» дип,
Тоз сибәләр көн дә каныңа.

Илнең җинаяте, өстерәлеп,
Еллар аша әле барачак.
Кешелекнең тарих битләрендә
КАРА ТАМГА булып калачак!

## БЕРӘҮ ГЕНӘ

Күк гөмбәзе күпме йолдызларны
Кысып-кысып тоткан күкрәгенә.
Бу галәмнең төпсез коесында
Йолдызлар күп, Кояш берәү генә.

Сине күрдем, диванадай йөрдем —
Дөрләп утлар капты йөрәгемә.
Аллы-гөлле сөю бакчасында
Чибәрләр күп, ә Син берәү генә!

## ЯЗГЫ ТАЙГАК

Очты, очты, каргалар очты.
*Халык иҗатыннан*

Иртәләрен чытыр салкын
                    була,
Ә көндезен кояш кыздыра.
Казан урамнары, ай-һай,
                    хәтәр —
Аяк асты тоташ боз гына!

Кыз-җилкенчәк хәтта таеп
                    китә,
Таеп-таеп китә инвалид.
Һәм сукрана: «Ниләр диеп
                    кенә
Чыктым икән бүген
                    юлга?» — дип.

Мәскәүдә дә эшләр хөрти
                    бүген:
Берәүне дә тормый
                    кызганып, —
Түрәләрнең шанлы урамына
Һөҗүм итә әнә бозлавык.

Хакимият коридорларында
Юллар тайгак, юллар бормалы:
Кемнең ничек итеп очканнарын
Безгә бары карап тормалы...

Очты, очты, министрлар очты —
Черномырдин очты берочтан.
Рәсәй мәңге чыга алмас, ахры,
«Скандаллар» белән бурычтан.

Тайгак өсләренә ком
                    сибәләр —
Җәяүлеләр егылмас өчен,
Сәясәттә исә
Күзгә ком сибәләр —
Ил эшенә тыгылмас өчен!

## ИДЕЛДӘ КӨЗ

Икәү йөргән яр буйларын
Юксынып килгән идем.
Гаҗәпләнеп карап торам:
Көзләргә кергән Идел.

Кара-кучкыл дулкыннарда —
Арыганлык билгесе.
Үзгәрешсез калган бугай
Комнарның гына төсе.

Сыңар акчарлак талпына,
Канатларын уйната.
Ике канат асларында
Идел җәелеп ята.

Акчарлак та авырайган,
Каерып ишә җилне, —
Аның канат кагышлары
Элекке түгел инде.

Кояш белән су арасын
Җәй буена гизгән ул.
Акчарлакның төсе уңган —
Китеп барыр тиздән ул.

Ике канат асларында
Иделне тоеп кара!
Ямансу, гүя акчарлак
Мәңгегә китеп бара.

Көзнең бу югалтуларын
Син нигә кызганасың?
Китерер безгә Табигать
Язларның өр-яңасын!

Кошлар китә, яфрак китә —
Кем гаепле, эзләмик.
Китмәсен сөю! Аңарга
Сәҗдә кылып тезләник!

## ӨР-ЯҢАДАН!

*Нәсирәгә...*

Алмагачтай кердең күңелемә,
Алма тәме килгән иреннәр.
Алма күкрәк... Ходай тарафыннан
Күпме байлык сиңа бирелгән!

Мәхәббәттән бирнә булды безгә
Икәү генә белгән тугрылык.
Шуңа күрә дә бит йөрмәдек без,
Читләр капкасына сугылып.

Елларыбыз чатнап китте кинәт!..
Чәчрәп чыкты үпкә-сапкалар.
Хәтта төсен үзгәрткәндәй булды
Икәү үтеп йөргән капкалар.

Саташасың Күкләр белән, диеп
Гаеплисең булыр син мине.
Их, чынлап та, хаталарым белән
Мин рәнҗеттем бугай Сөюне.

Тыңламадым әйтер сүзләреңне,
Шуңа күрә язмыш таш атты, —
Бәхет алмаларын тартып алып,
Кыргый алма миңа ашатты.

Яңабаштан барлыйм үткәннәрне —
Ни чәчкәнбез, ниләр урганбыз?
Өр-яңадан гашыйк булыйк, әйдә!
Без бит —
Сөю өчен яратылганбыз...

## СИНЕ ЭЗЛӘГӘНДӘ

Калдым ике утлар арасында,
Йөрәккәем тибә тып та тып:
Китәм икән — нәфрәтләнеп китәм,
Кайтыр булсам — кайтам яратып.

Мин шәһәрдә сукбай булып йөрим,
Светофорда сары ут яна.
Янәшәмнән әллә кемнәр уза —
Кайсы көләч, кайсы дивана.

Салкын рельсларны сискәндереп,
Үтеп китә төнге трамвай.
Кем өчендер, бәлки, мин үзем дә
Диванадай басып торам, вай...

Уты сүнгән тәрәзәләреңнән
Карап тора кебек күзләрең.
Үткәннәрдән мин ярлыкау сорыйм,
Сары яфракларга тезләнеп.

Сукбай сыман тагын китеп барам,
Дөньясына җаным үртәлә.
Сине эзләп мин ялгышмыйм микән,
Ниләр көтә безне иртәгә?

Калдым ике утлар арасында,
Гүя «сугыш» бара күңелдә:
Китәм икән — мин мәңгегә китәм,
Кайтыр булсам — кайтам мәңгегә!

## МОҢСУ ХАЛӘТ

Җилләр сыман, су агышы сыман
Хәрәкәттә узды көннәрем.
Йолдызларга якын булыйм диеп,
Мин биеккә таба үрләдем.

Фани дөнья кайнап кына тора
Бәгереңә синең төртелеп.
Бер уйласаң, гел тупаслык анда,
Бер уйласаң, үзе — гөл кебек.

Уйландыра күкләр зәңгәрлеге,
Моңсулата шәфәкъ балкышы.
Имән әле, имән яшәп ята,
Кочагында — яфрак алкышы.

Яшен бит ул чәчәкләрне түгел,
Имәннәрне сугып аудара.
Яшен суккан кәүсә төпләрендә
Кырмыскалар гына сау кала.

Табигатьтә — шундый кырыслыклар,
Ә тормышта — ничек, ни-нәрсә?
Ил күзендә җавап тотасы бар,
Сынамакка сине җибәрсә.

Сынган чагы була күңелләрнең,
Сүнгән чагы була учакның.
Көл астыннан яшәү чаткылары
Бәреп чыга барыбер шул чакны!

Йолдызларның кинәт атылуы
Тынгы бирми миңа кич-иртән.
Беркем ишетмәгән авазларны
Нигә икән ешрак ишетәм?..
ЗИРАТТА КИЛГӘН УЙ

Үлгәч тә адәмгә башлар иелә,
Яхшы кеше иде мәрхүм, диелә.
Сызлана җан, әрни-сыктый исәннәр
Күкләрдән агылган матәм көенә.

Баласынмы, әллә парын югалткан —
Бер кош аваз биреп куя таллыктан.
Кеше гомерләре булып зиратта
Күпме әнә каберташлар калыккан.

Кыска да соң адәмнәрнең гомере!
Дөрли, сүнә — гүя утын күмере.
Туган елы, үлгән елы — бер сызык,
Бар гомере сыйган шунда «чүкелеп».

Яши-яши талмасын күз карасы,
Безгә фәкать алга таба барасы.
Туган елың, үлгән елың язылыр,
Безнең гомер — шушы сызык арасы.

ЮЛАУЧЫ

Тәгәри китте йомгагым,
Ул бит язмыш йомгагы.
Күңелемнең, кояш эзләп,
Карурман кичкән чагы.

Үлем бар, дип сөйләнмәгез,
Ышанмыйм үләремә.
Җыр белән ялгыйм гомерне
Алдагы көннәремә.

Тәгәри китте йомгагым —
Өзелмәсен җепләре.

Идел кичәм... чәчри биткә
Чал дулкын күбекләре.

Ярый әле, ышанычым
Сөеп калды аркамнан,
Ирек бирсәң, бу дулкыннар
Куячак бит арканлап!

Әле чорныйм, әле сүтәм
Язмышымның йомгагын.
Эндәшегез, минем кебек
Сәфәр чыкты кем тагын?

## ӘНКӘЙ ГӨЛЛӘРЕ

Яңгыр юып киткән тәрәзәгә
Шомырт яфраклары ым какты.
Тәрәзәне әй ачарга тели
Чүлмәктәге гөлләр шул чакны!

*Балачак хатирәсе*

Шыбыр-шыбыр яңгыр тамчылары
Төшә башладымы аз гына,
Тезеп-тезеп куя иде әнкәй
Һәрбер гөлен яңгыр астына.

Тезелешеп гөлләр чыкканнан соң,
Ишегалды китә ямьләнеп.
Кул чәбәкләп котлый гөл-яфраклар
Кинәт килгән яңгыр бәйрәмен.

Белгән әнкәй: чыныксыннар диеп,
Яңгыр асларына җибәргән.
Шуңа да бит кайчак яшен исе
Аңкый иде безнең гөлләрдән.

Төрле якка атылышып киттек,
Атыныша торгач таганда.
«Хәерле юл, балам!» — дигәннәрең
Истә, әнкәй, истә һаман да.

Кар-бураннар, яңгыр асларында
Без дә байтак йөрдек чыланып.
Башын түгел, ташын әйләндердек
Әлмисактан калган дөньяның.

Битләр пешә иде эсселектән,
Туңган чаклар булды суыктан.
Аягүрә басып кала белдек —
Без чыныккан инде, чыныккан!

Тормыш яңгырлары юды безне
Камчылап та, кайчак назлап та.
Рәхмәт, әнкәй, дучар иткәнсең син
ЯШӘҮ дигән татлы газапка.

...Тәрәзәмдә яңгыр. Таң җилләре
Туган яктан сәлам китергән.
Тормыш тагын үзенә дәшә мине,
Без яшәргә дучар ителгән!

## ФАТИХ КӘРИМ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Берәм-берәм татар егетләрен

Күңелемнән бүген барлыймын.
Беларусьта ятып калган әнә
Композитор Фәрит Яруллин.

Концлагерь тимерчыбыклары
Бар Европа буйлап җәелгән.
Шул чыбыкны җыры белән өзде
Алиш, Курмаш, Муса Җәлилләр.

Шагыйрьләрнең күңел капкасына
Афәт җиле һәрчак бәрелгән!
Рәсәй өчен сугыш утларында
Дөрләп янды Фатих Кәримнәр.

Күпме җирне мәскәүлеләр өчен,
Әй, татарым, сугышып алдың син.
Өзелә үзәк: нигә инде хәзер
Үз-үзеңне яклый алмыйсың?

Әй, син, халкым,
Шундый егетләрең,
Батырларың була торып та,
Кайчан инде, кайчан үз хакыңны
Даулый белерсең син тарихта?
Тарихта...

## ТӘКЪДИР

Мин китмәкче булам... Тормыш исә
Үҗәтләнеп тота якадан.
Ничәнче кат инде шушы көрәш
Сүнә, туктый, дөрли яңадан!

Сары таңнар чорнап алган чакта,
Әвереләм сырхау кешегә.
Ут эчендә әрнеп тибә йөрәк,
Йә суыктан җаным күшегә.

Еш сискәнеп китәм юлыкканда
Агач битле сөмсез бәндәгә.
Кинәт кенә Җирнең киләчәге
Шулар сурәтендә шәйләнә.

Тук чырайлы, шома битле затлар
Бәйрәм итә, көн дә туй ясый.
Ил түрендә мыжгып тора әнә
Мәкер, ялган, иблис оясы.

Мәңгелектән очкын чәчри безгә —
Кыелып кына йолдыз атыла.
Илләр белән илләр бер-беренә
Канлы кылычларын батыра.

«Ахырзаман!» диеп өркетәләр,
Уйный күктә тәкъдир камчысы.
Җәмгыятьтә — бушлык, битарафлык,
Ахырзаман шулдыр, ахрысы.

Заман йөген кемнәр тартып бара,
Татар йөген кемнәр тартачак?
Туган телне, җирне коткармасак,
Ил корабы төпкә батачак.

Туу белән авыр сәфәрдә без,
Барыр юллар — ташлы, бормалы.

Дөнья буйлап
Үземне дә тартып барам
Гап-гади бер татар бурлагы.

Җилкәләрне кисеп керә аркан,
Күкрәкләргә тозлы җил бәрә.
Офыкларда — кара болыт явы...
Ниләр көтә безне иртәгә?

## ПЕЧӘНЧЕ КАРТ

Чалгы эленеп тора келәттә,
Дәрман посып ята йөрәктә.

Вакыт, ахры, шактый «каклаган» —
Чалгы сабын тузан каплаган.

Башакларга дип сөт төшсенгә,
Бии рәшә кырлар өстендә.

Урманнарда — алсу бөрлегән,
Болыннарда — печән өлгергән...

Чү, ни хикмәт булды соң бүген?
Өзде чалгы пәрәвез җебен!

Печәнчебез киерде түшен,
Кырын салды ак кәләпүшен.

Комлы кайрак тәмам очынган —
Сибелә йолдыз чалгы очыннан.

Гүя скрипка кыллары —
Чеңли җирдә чалгы чыңнары.

Кояшны да хәтта тирләтеп,
Печән чаба бабай гөрләтеп...

## БОЛЫТЛАРЫҢ, ЯҢГЫР, КАЙ ЯКТАН?

*Баллада*

*Иваново егетенә...*

Иван солдат, бурыч үтәдем, дип,
Үз-үзеңне бары алдыйсың.
Чечняларда калды сул аягың,
Хәзер инде
Култык таякларда атлыйсың.

Шәһәреңдә кыйгач яңгыр ява,
Кыйный-кыйный ява ташларны.
Иван солдат, синең өчен тагын
«Каһәр суккан» минут башланды!

Сөякнең һәм тәннең сизгерлеген
Яңгырлардан булмый аралап:
Тагын сызлый, әрни актарылып
Аяктагы «теге» яралар.

Диварларга кыйгач яңгыр бәрә,
Ишекләргә усал җил бәрә.
Сынып төшкән сугыш байрагыдай
Сыңар балак җирдән сөйрәлә.

Йодрык янап, күккә кизәнәсең:
«Болытларың, — диеп, — кай яктан?»

Баскыч буйлап кыен күтәрелү,
Алга бару — сыңар аяктан.

Иван солдат, егет чакларыңда
Бии белә идең өздереп!
Шинель кидең... Аягыңның берсен
Чечняларда кайттың өздереп.

Ут чәчтегез...
Монда — Мәскәүләрдә —
Акча урды корал Хуҗасы.
Суза-суза култык таякларын,
Килде сиңа дөнья нужасы.

Гариплеккә таба атлагансың,
Чыгып китеп туган йортыңнан.
Сезнең каннар хәрби штабларда
Кызыл шәраб белән юылган.

Ярый әле, Ходай дигәннәре
Ике аяк биргән бәндәңә.
Баш бит бирәү генә!
Өзелә ул
Беренче һәм соңгы мәртәбә...

Үзең күрдең: күпме иптәшләрең
Канлы юлда башын югалтты.
Күз яшьләре белән сугарылган,
Цинк белән тулган
Россиянең һәрбер зираты.

...Нервыларың тоташ әрни бүген,
Сызлый ярaң, шайтан алгыры!
«...Мин гаепле түгел...» дигән сыман
Бәргәләнә июнь яңгыры.

Иван солдат,
Бурыч үтәдем, дип,
Үз-үзеңне юкка алдыйсың.
Оныкларга сөйләп бирер өчен
Күңелеңдә
Юньле хатирәләр барлыйсың...
Бармы соң?

— Болытларың, яңгыр, кай яктан?
— Чечня тауларыннан, Кавказдан...

## ҮЗЕМ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

Кычыткaнлык уртасына чумам —
Аңлар өчен, имеш, дөньяны.
Балачакта балачагым мине
Кайчак шулай
Кычытканнар белән кыйнады.

Мин болында ятам. Борыныма
Килеп куна ялгыз күбәләк.
Түбәләргә, елгыр мәче сыман,
Бик еш менә идем үрмәләп.

Табигать бит әнкәй сыман икән:
Үзе кырыс, үзе юмарт та, —
Көтә безне урман чикләвеге,
Балга баткан яшел умарта.

Ә кичләрен Айны күрер өчен
Чыга идем болдыр катына.
Айның борынына чиртә-чиртә,
Шаярышып, йолдыз атыла.

...Нигә әле шулай сагындыра
Ерактагы якын балачак?
Кемгә ничек, минем өчен исә
Ул — баллычак булып калачак!

Табигатьтә хөсетлелек булмый,
Зур тормышта төсләр башкарак:
Өскә таба күтәрелгән саен,
Өстериләр сине аскарак.

Чү!
Нигә соң болай зарланамын,
Еракларга әнә Күк дәшә.
Бу дөньяны кабат аңлар өчен
Үзем белән үзем сөйләшәм.

## КАР АСТЫНДА ЧИШМӘ

Кар астында калды безнең чишмә,
Кар астында калды көзләребез.
Хыялларда гына бер-беренә
Орынышып тора тезләребез.

«Сөям сине...» диеп пышылдаулар
Булды микән әллә сүздә генә?
Шыбыр... шыбыр...
Каен очларыннан
Яфрак тамды чишмә күзләренә.

Ә чишмәгә нәрсә — тып-тын гына
Китеп барды инеш-диңгезләргә.
Син дә киттең...
Ерак офыклардан
Тиеш булдым сине мин эзләргә.

Кешни-кешни, еллар каршысына
Актарылып чапты акбүз атым.
Көзләрдә дә, кышларда да һаман
Төсен югалтмады ак сурәтең.

Кар өстендә синең исем яна —
Үзем генә белгән серле тамга.
Кар астында калган чишмә кебек,
Тып-тын гына челтерисең җанда...

## ИНЕШТӘ — КАУРЫЙ КАЛӘМ

Тамчы-тамчы яңгыр яуган чакта,
Су өстендә калка бөтеркә.
Әйтерсең лә шаян күбәләкләр
Шаярышып канат җилпетә.

Күпер бүрәнәсе өсләренә
Җигүле ат керә дөбердәп.
Кәгазь көймә сыман йөзеп йөри
Инеш өсләрендә каз-үрдәк.

Ә түрдәрәк — буа бусагасы,

Хәтәррәк монда бөтеркә.
Суларыңны, көннәр-айларыңны
Йотып кына тора кич-иртә.

Бездән өзеп, көннәр-яфракларны
Җилгә сибә вакыт агачы.
Казлардан да каурый тузгып кала —
Кирәк бары канат кагасы.

Инештәге суның бөтеркәсе
Нәрсә уйлый икән бу хакта:
Ап-ак казның ап-ак каурыйлары
Агып китте әнә улакта.

Каурый каләм, сүзен язалмыйча,
Мәңгелеккә китте микәнни?
Шуның эзләреннән барыр өчен,
Мин күтәрәм бүген җилкәнне!

## ЯҢА ГАСЫР БУСАГАСЫНДА

Очсыз-кырыйсыз Күк бит ул...
*Г.Тукай*

Һәм, чыннан да, күктә ниләр булмый:
Кинәт чәчрәп йолдыз атыла.
Амур-малай күпме гашыйкларның
Йөрәгенә уклар батыра.

Тулы чагы Айның...
Көн вә төннәр уза,
Гаҗәпләнеп тагын карыйсың —
Урак итеп кемдер уеп алган,
Урлап киткән Айның яртысын.

Борынгыдан килгән күренешне
Белгән халык, әйткән: ярым ай.
Безнең өчен — ул бит милли кәгъбә,
Ә гашыйклар өчен — сары май.

Тик... булалмый күктә ярты кояш,
Ярты кояш җанда булалмый.
Нәҗесләрдә күпме аунатсаң да,
Хакыйкать ул барыбер югалмый!

Кояш һәрчак бөтен килеш кирәк,
Шуның белән ул бит кадерле.
Камиллеккә әгәр кизәнсәләр —
Шунсы телеп ала бәгырьне.

Нигә әле ярым дөреслекне
«Манчып» тора безгә замана?
Кан чәчрәтеп, әнә дөреслекне
Кыздыралар утлы табада.

Тирә-якны әгәр чорнап алса
Ярым ялган, ярым дөреслек, —
Түрәләргә, димәк, без колларча
Бил бөгәргә тагын керештек...
Бирештек?

## АВЫРГАН ЧАКТА...

Галәмнән коела йолдызлар тузаны,
Сау чакта сизелми гомерләр узганы.

Чорналды тәнемә сырхаулык пәрдәсе,
Айларым, елларым —
Гарешкә очтылар һәммәсе.

Ерып, атлап барамын Вакыт урманын,
Типтем дә очырдым язмышым юрганын!

Тау чаклы гамәлләр башкарган дигәнем —
Очына да тормый икән ич энәнең.

Уйландым: дөньяда мин ниләр майтарган,
Үземме, әллә соң елларны картайган?

Күтелгән шатлыклар киләдер кичегеп...
Ни көчләр шакый соң замана ишеген?

Һич теләмим үземне кызгануларын,
Барлык чирдән хәтәр
Милләт өчен сызлануларым.

Халкым чирле — югалткан шанлы дәүләтен,
Ни көчләр белән кайтарыйк соң шәүкәтен?

Еллар һәм көннәрем артымнан ияргән.
Тезгенне тот, егет, егылма иярдән!

## ҖИР КЫЗЫ БУЛ!

*Кызым Айсылуга*

Караңгы төн буразнасын ерып,
Бар Җиһанга нурын өләшеп,
Галәм кочагында Ай тирбәлә —
Гашыйкларның якты сердәше.

Бәхет мизгелләрен күзли бугай:
Нинди халәт җанда, ни вакыт?
Шуңа да бит йә тулышкан була,
Китек чагы була кайвакыт.

Татар халык әкиятләрендә
Зөһрә кызга урын тапканнар, —
Чиләк-көянтәсе белән Ай түренә
Элеп куйганнар да,
Сагышланып, аңа бакканнар.

Син дә Айга бик еш карыйсыңдыр,
Тоеп кичнең җылы рәхәтен.
Күкләр биек, күктә — билгесезлек...
Җирдән эзлә ЯШӘҮ бәхетен.

Романтика, яшьлек уты белән
Мөлдерәмә тулы йөрәгең.
Исемең Ай белән башланса да,
Җир кызы бул! — шулдыр теләгем.

## ХУШ, ЮГАЛГАН ВАУЧЕРЫМ...

*(Ун еллыгына мәрсия)*

Чубайсның бу ваучеры —

Булды чып-чын дау чоры.
Түрәләрнең кесәсенә
Яуды акча яңгыры!

Фондка сал, дип кыстадылар
Безнең кебек юләрне.
Ә акылы башлар аны
Сатып кына җибәрде.

Дүрт ваучерымны кочаклап,
Фондларга барган идем.
«Процентлар» үрчер диеп,
Кассага салган идем.

Синең сукыр тиеннәрең
«Рубль» булыр, диделәр.
Акчасы юк... Ә вәгъдәне
Тау-тау итеп өйделәр.

Такыр калды шул кесәләр,
Анда җилләр исәләр.
Ышанмагыз: бер ваучерга
Бер «Волга»ны
Алып була, дисәләр.

Хрущев дәдә бозауларны
Талап-тартып алдырды.
Рәхмәт инде Чубайска,
Ыштансыз да калдырды.

Алай димик, тормыш бит ул
Әллә ниләр эшләтә:
Завод-фабрик сатып алды
Шома куллы эшмәкәр.

Хәтерләсәм кинәт кенә
Шул чактагы дау чорын, —
Әрни-әрни әйтеп куям:
«Хуш, югалган ваучерым...»

## КАЛТЫРАНА ЙОЛДЫЗЛАР...

Әй, Ханкала, шомлы Ханкала,
Бөтен дөнья сиңа таң кала!

Булгансыңдыр ханнар каласы,
Хәзер бит син — урыс «баласы»...

Сөйләшәләр синдә мат белән,
Кяфер сүзләр сиңа — ят, беләм.

Дер калтырый күктә йолдызың,
Аэродромнар гүли көнозын.

Ни хакыйкать булсын бизмәндә —
Танк чылбырлары изгәндә?

...Сугышканда аклар-кызыллар
Бар мәгыйшәт илдә бозылган!

Берсен-берсе тоташ кырганнар,
Тыныч йокы сезгә, корбаннар...

Мәскәү тагын тешен агарта —
«ИРЕК!» дисәң, йонын кабарта.

Тезләндермәк була Чечняны:
Кан-яшь анда... Сугыш тузаны...

Кирәк, имеш, тыныч йокларга —
Сугыш ачтык «террористлар»га.

Таныш инде безгә «бу көйләр» —
Тарихтагы канлы бүкиләр.

Заманында издек «кулак»ны
Һәм җимердек мәчет-пулатны.

Шәрыкъ илен сугып ектылар,
«Басмачы» дип мөһер сuктылар.

Үтәп Сталинның кушканын,
Кырып салдык «халык дошманы»н.

Калса кала өнсез, сулышсыз,
Яши алмый Рәсәй сугышсыз!

Илдә — гражданнар сугышы...
Хөкүмәтнең анда юк эше, —

«Держава» дип, текә түрәләр,
Кызганмыйча, акча түгәләр.

Сайлап «вертикаль»нең кәттәсен —
Үзгәртәләр
Конституция маддәсен.

Терроризм — әйе, кәсафәт,
Империя — явыз, кабахәт.

Күптән вакыт: тыныч сөйләшү,
Халыкларга ирек өләшү!

Үз иленДә сугыш барганда,
Тыныч йоклап ята кем анда?

Кыза бара илдә ут-кузлар,
Калтырана күктә йолдызлар...

## УРМАНДАГЫ БЕР КӨНЕМ

Яшел урман...
Яшел тугайлыкта
Печән чаба егет, җилкенеп.
Күңелендә йөрткән догасы да
Тирбәлешә җәйге җил кебек:

«И Ходаем, хәзинәңдә барын
Бирче безгә, иман, иминлек.
Ерак кына йөри күрсен бездән
Хөсетлелек белән мин-минлек!»

Нигә бүген кояш шәп кыздыра,
Нигә бүген уйлар яктырак?
...Билдән киселеп ава җир җиләге

Язмышына үзенең аптырап.

Печән асларына керә чалгы,
Яшен кебек яшьни ул анда.
Яшәп була, яшьнәп була шулай
Беләгеңдә дәрман булганда.

Карт имәннәр колак салып тыңлый:
Чү, ни сөйли чалгы чыңнары?
Бер каңгырыш булып зеңләп тора
Әкияттәге Сак-Сок моңнары.

Әй, син, күке, ниләр юрыйсыңдыр,
Урман өсләрендә кычкырып?
...Аландагы богыл өсләренә
Кояш килеп куна кичкырын!

## ҮЗЕМНЕ КАМЧЫЛАУ

Мин туганмын...
Сыңар куллы әткәй
«Малай...» диеп тәмам очынган!
Тик аңламыйм: нигә икән миңа
Рашат диеп исем кушылган?

Яши-яши бераз төшендем мин
Исемемнең хикмәт төбенә:
Бер ягында кояш төсмерләнсә,
Бер ягыннан шатлык күренә.

«Ра» дигәнең — кояш мәгънәсендә,
«Шат» дигәнең — шатлык сүзеннән.
Шул сүзләрне аклар өчен генә
Никадәр көч кирәк үземнән!

Гарәпчәдән әгәр күчерсәкме —
Туры юлдан булам атлаучы.
Бардыр мине сүгеп ташлаучылар,
Бардыр, әлбәт, мине мактаучы.

Кылганнарым — яманлыкка түгел,
Яхшылыкка таба төбәлгән.
Биеккәрәк күтәрелер өчен
Кайнап чыктым астан, түбәннән.

Гөнаһ чаклар булмый калмагандыр —
Урталайга төшәм киселеп:
Шундый дәрәҗәле исемемә
Туры килә микән җисемем?

## МАГЕЛЛАН ШИКЕЛЛЕ

*Айдар Хәлимгә*

Юлларда күлләр бар,
Юлларда силләр бар.
Кичәсе үрләр бар —
Юлларда кемнәр бар?

Сәфәрләр, һай, озын,
Атлыйсың көнозын.

Кичләрен «күз кыса»
Күктәге йолдызың.

Йолдызлар мәрҗәне —
Галәмнең бар яме.
Ә җирдә гөр килә
Үләннәр бәйрәме!

Юлларда баш түгел,
Таш кына шомара.
Күн итек табаны
Юкарган кай ара?

Яңгырда кыйналып,
Бозларда кыйралып,
Барса да ир заты,
Югалтмас иманын.

Әйләнә яз-кышлар,
Әйләнә язмышлар.
Җаныңа чорнала
Өр-яңа ачышлар.

Куй җилгә күкрәгең,
Идел-йорт — терәгең.
Сыешмый җиһанга
Теп-тере йөрәгең...

Юлларда ни булмас,
Тәкъдирең ни кылмас.
Иманы сау чакта
Ир-егет егылмас!

Син һаман һимматкә,
Җан сөйгән милләткә, —
Магеллан шикелле
Әйләнеп кайтасың...

## ГАҖӘПЛӘНҮ

Эштән арып беткәннәрнең
Кулларында — су чиләге.
Шул хатыннар кулын көтә
Тугайлыкта җир җиләге.

Эштән арып беткәннәрнең
Куллары да — эш балтасы.
Бу тормышның бүрәнәсен
Әле күпме шомартасы!

Эштән арып беткәннәрнең
Кулларында — елтыр көрәк.
Бер башлаган буразнада
Меңәр орлык үсү кирәк.

Яргаланган бу кулларга
Мәхәббәт кошы куна да,
Яшәү дигән яшел агач
Нурын сибә бу дөньяга...

## МИШӘ БУЙЛАРЫННАН МАНЗАРА

Бал һәм чәчәк исе килә кырларымнан,
Сез аңларсыз мине ихлас җырларымнан.
Таңнан торып бабам буразналар уйган,
Элек заманнарда әбкәм көлтә куйган.

Җырларыма кадәр килә күтәрәсем
Туган якның һәр чәчәген, бүдәнәсен.
Күктә кояш нурын эчә тургайларым,
Җитү кызлар сыман балкый тугайларым.

Әйтерсең лә кояш минем авылдашым —
Сыйпап китә әнкәемнең кабер ташын.
Җәяүләшеп чаба җилнең малайлары,
Урак өстен көтә авыл агайлары.

Саф татарча безнең телдә кычкырышып,
Тәкәрлекләр әйләнешә болыт кочып.
Сазлыклардан башын төртеп калкалар да,
«Үз җырларын» сузмак була бакалар да.

Шундый рәхәт туган якның мендәрендә —
Мин болытлар булып ауныйм күкләрендә.
Бу әкиятне урман каян табып тора:
Мең яфрактан меңәр тамчы тамып тора.

Арышларым башын иеп яктан якка,
Әйтерсең лә дога укый туган якка.
Күпме башак туп-турыдан, әй, ыргыла
Комбайнның елтыр-елтыр урагына!

...Көзен кошлар җылы якка очкан булыр,
Комбайннар ял итәргә поскан булыр.
Кибән асларында — ни ул кыштыр-кыштыр?..
Монысы инде гап-гади бер тычкан булыр.

## АҢЛАУ МӨМКИН...

Умом Россию не понять...
*Тютчев*

Коммунизмга дип барган шәпкә,
Өзелсен дә китсен әле лепкә!
Корыч фундамент, дип лаф орулар
Уратылган булган черек җепкә!

Кара халык эшкә карышмады,
Үстерде ул бодай, арыш, тары.
Шигарәләр чөеп җилгә очты
Россиянең күпме алтыннары!

Тирән тамырларда сут калырмы,
Илнең амбарында кот калырмы?
Батып бара торган албастыны
Иганәләр генә коткарырмы?

Белем кыяларын кимерсәк тә,
«Тимер диварлар»ны җимерсәк тә,
Шовинизм дигән кара чуан
Гел кычытып тора бу терсәктә...

«Үткәннәр»не тоташ сагыну бар,

«Яңа чор» дип дөрләп кабыну бар.
Халыкларны кая таба илтер
Демократик битлек ябынулар?

Космосларга, әйе, менгән чакта,
Завод-фабрикларны бүлгән чакта,
Ни дәүләт бу — эзсез, бихәбәрсез
Бер кешесе хәтта үлгән чакта?

Кече парламентлар хокук сорый,
Башларына суксаң — йокымсырый.
Берни аңламыйча яшәп ята
Йә Машенька шунда, йә Шәмсурый.

Гөрләп кенә бара дисәң эшләр,
Буып ала яңа үзгәрешләр:
Камчаткадан алып Кавказгача —
Забастовка, утлы түнкәрешләр.

Киллерларга ирек биргән чакта,
«Держава!» дип, күкрәк төйгән чакта,
Халыкларга татлы Азатлыкны
Тамчы-тамчы итеп бүлгән чакта,

Россияне...
Әйе, аңлау мөмкин
Фәкать кан һәм күз яшьләре аша...

## КЫСКА ХӘТЕР

Агачлар тамырын оныткан,
Шуңарга черек ул тубыктан.

Сәфәри кыйбласын оныткан —
Җил уңай шуыша болытлар.

Нәселен-нәсәбен оныткан —
Маңкортка әйләнә оныклар.

«Уян!» дип, туган тел чаң кага
Хәтернең күзеннән яшь ага.

Үрчесә, ишәйсә хәтерсез —
Дөньялар калачак кадерсез.

Тарихи хәтернең кузлары
Сүнмәсен, катмасын бозланып!

## ЧАТЫРТАУГА КҮТӘРЕЛҮ

Язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин, Марсель Галиев, Илдус Гыйләҗев һәм мин 1995 елны атаклы Чатыртау түбәсенә күтәрелгән идек.

*Автор искәрмәсе*

Чыкмадык без мылтык тотып ауга,
Күтәрелдек бары Чатыртауга.
Үзенекен һаман тукый Марсель:
— Иң матур як кайда?
Аз-на-кай-да!

Без торабыз аягүрә басып,
Манзаралар аста — шәрран ачык.

Урал-таудан килгән биеклектә
Үз-үзеңнән булмый кебек качып.

Бәләкәй дип, юкка оялабыз,
Һәркайсыбыз — бәлки, Алып батыр?
Биеклеккә менгән кеше генә
Азатлыкның җилен, тәмен татыр.

Күзләрендә Мөсәгыйт агайның
Дөрләп китә тарих очкыннары...
Кубрат ханга тәмам охшап калган —
Кием белән корал бир син бары.

Илдус Гыйләҗине күр син әнә,
Кунаклары диеп өтәләнә.
Гүя Сократ: авыл фәлсәфәсен
Сибеп кенә сала өстәленә.

Марсель — вәзир...
Сөйләп кенә тора,
Бер алдыңа төшә, биш артыңа.
Кай арада гына өлгерә ул
Төрләнергә шулай биш-алтыга?

Ә мин нәрсә? Гап-гади бер кунак,
Тыңлаганым, сөйләгәнем — тыйнак.
Ә мин — сакый, җилгә атланам да
Аркадашларымны йөрим сыйлап.

Безгә нинди ямьнәр кирәк тагы —
Тургайларның өзеп сайрар чагы.
Чү, егетләр! Калкып чыкты әнә
Чатыртауның соры байбаклары...

Серле сурәт... Гүя үзәнлектә
Балбал ташлар аягүрә баскан.
«Орхон язмалары истәме...» дип,
Тарих текәп карый сыман астан!

Гасырларны ерып, бу үләннәр
Яуга чыккан — гүя вавилоннар...
Туфрак булып, йөгерек үлән булып
Һаман яши бугай бакый җаннар!

## ХАКЫЙКАТЬ ЭЗЛӘГӘНДӘ

Нинди көчләр куәт бирә безгә —
Яшәп туеп булмый дөньялыкта!
Әй, син, тәкъдир, гозерләнеп сорыйм,
Калдырмачы соры урталыкта.

Бөтен курыкканым — пыскып яшәү,
Яшим икән, яшьнәр утым булсын.
Юлга чыксам — кабарыма икмәк,
Учак ягарыма утын булсын.

Хакыйкатьнең хакыйкатен эзлим:
Уч төбенә сыяр энҗе микән?
Әллә инде, кешеләрдән качып,
Күкләр катламына менде микән?

Туу белән үлем якалаша —

Ишетәмен оран тавышларын...
Зәңгәр чәчәк, кояш!
Мин бит сезгә
Күпме җырларымны багышладым.

Түм-түгәрәк сезнең дөньягызны
Бөтенләйгә инде калдырыйммы?
Бөтен тәнем гүләп торган чакта,
Соңгы күлмәгемне салдырыйммы?

Ни аяныч — йөрер туфрагыңны
Каплап китсә әгәр ачы әрем...
Куркытамы? Әйе, нык куркыта
Үтәлмичә калган вәгъдәләрем.

Егылса да кеше, торып басып,
Максатына һаман барачактыр.
Бер кешесен генә югалтса да,
Ярты җиһан ятим калачактыр.

Төш һәм үлем патшалыкларын да
Ерып чыга торган татармын мин.
Җиргә иңсәм, каберем өстендәге
Каен шавын тыңлап ятармын мин.

## КЫРДА – КАЗЛАР ӨНЕ

Өзеп кызыл тәпиләре белән
Камылдагы пәрәвезләрне,
Теләченең ялан кырларына
Кыр казлары килеп тезләнде...

Берәү... Өчәү... Бишәү... Әллә ничәү!
Саный китсәң, ике йөзләп бар.
Шушы казлар белән күтәрел дә,
Әйдә, романтика эзләп бар.

Мәрмәр сынлы чибәр киек казлар!
Хушлашырга диеп килгәнсез.
Никадәрле азат кошлар бит сез —
Богауларсыз, бәйсез, йөгәнсез.

Күпме әнә бала үстергәнсез,
Сыгылмаслык булсын канатлар.
Очар юлың буталмасын дисәң,
Йолдызларга, айга карап бар.

«Кыйгак... кыйгак...» Кырда — казлар өне,
Моңсу булып китә күңелгә.
Сәйдәш белән Бах моңнары гүя
Кырларыма бүген түгелгән...

Кошлар китеп бара җылы якка,
Кышлар килеп ята котыптан.
Ник өзелеп калдың, каурый каләм,
Ак җилпәзәң әнә тутыккан...

## УЙМАК СУРӘТЛӘР

***Яңа елга кергәндә***

Чыңлый бокаллар —
Кулларда гүя көмеш кыңгырау!
БӘХЕТ авазлары була күрсен.

***Яз башы***

Кагылды яз
Трамвайның бозлы тәрәзенә...
«СӨЯМ» дигән сүзләр
Акты нәни гөрләвек булып.

***Беренче төн***

Баш өстендә йолдызлар чыбылдыгы.
Төн юрганын яба тәнебезгә...
Сөю тәхетендә — БЕЗ икәүдән-икәү!

***Солы алкалары***

Чит күзләрдән оялышып,
Тыйнак кына аска иелгәннәр, —
Әйтерсең лә безнең мәхәббәтнең
ӨНДӘҮ билгеләре!

***Туган нигездә***

Таңнар аткан саен,
Әткәй утырткан КАЕННАР
Сәҗдә кыла кыйбла якка карап.

***Июнь, 1977 ел***

Күбәләкнең канатлары,
Кайчы-кайчы булып,
Җәйнең ГОМЕРЕН кисә...
***Су чебене***

Йөзә, этелеп китә
Һәм сөенә:
ДАВЫЛ ясадым, дип, инештә.

***Мишә буенда***

Алтын балык ярга чыкса,
Ниләр сорар идем?
БАЛАЧАКНЫ кире кайтарсын!..

***Әнкәй чикләвекләре***

Ашый идек тешне канатып...
ТОРМЫШ дигән «каты чикләвек»не
Ватам хәзер — маңгай канатып.

***Өлешемә тигән көмешем***

Тормыш диңгезендә
Төпкә чумып МӘРҖӘН эзлимен...
Кулда кайчак — бака кашыклары.

***Зиратта***

Ирләр кабер казый...
Менә-менә авам, диеп,
Төптән шыгырдый иске КАРТ ИМӘН.

***Вакыт сурәте***

Кояш мөнбәренә
Ай-йолдызлар менеп кунаклады...
Тагын БЕР КӨН үлде галәмдә.

***Хәвефле дөнья***

Меридианнар — җәя,
Ракеталар — тартылган ук!
Кыл өстендә тора Җир шары.

***Айсбергка бер сүз***

Йөзә, океаннар гизә...
Шәҗәрәне «укып» карыймчы —
Безнең чишмәдә тугансыңдыр, бәлки?

***Юану***

Көнбагыш — кояшка карап,
Флюгер — җилгә карап борыла.
Ярый әле, безнең башлар флюгер түгел!

***Автотрасса***

Чаллы юлындагы карлар,
Кузов артына сыланып,
Мәскәү капкасына хәтле барып җитте!

***Гомер озынлыгы***

Еллар гына акрын мүкәли,
Поезд сыман чаба көннәрем.
Калган гомерем исә — бер саплам...

***Шатлана белү***

Юллар картайган,
Еллар муртайган...
Ә күңелдә барыбер җыр калган.

***Янә мәхәббәт хакында***

Йөрәк — кан савыты?
Чәчрәп бәхәсләшәм:
ЯШЕН ЯШЬНИ анда көнозын...
ТУЗГАНАК

*(Җыр)*

Мин болынга диеп килгән идем
Күрер өчен якын кешемне —
Тузганаклар, йомры тузганаклар
Балачакны искә төшерде.

Кушымта:

Әй, тузганак, синең дә бит бардыр
Үзең генә белгән моңнарың.
Мине исә шунсы моңландыра —
Тузганактай тузгый елларым.

Еракларга очып китсен диеп,
Өрә идек сиңа тын белән.
Вакытның һәм алтын балачакның
Кире кайтмаслыгын мин беләм.

Кушымта.

Тузганаклар шары каршылады
Болындагы яшел үзәндә.
Сөю безне эзләп тапкан икән,
Сагынуларга кирәк түзәргә.

Кушымта.

КАРУСЕЛЬ

Әйләнә, яфраклар әйләнә, әйләнә,
Офыкта инде көз шәйләнә.
Без икәү янәшә булганда, булганда,
Көзләрем язларга әйләнә.

Әйләнә, карусель әйләнә, әйләнә,
Чәчебез чәчләргә бәйләнә.
Без икәү канатлы очышта, очышта,
Карусель — тылсымлы әйләнә.

Куыша-куыша бар дөнья әйләнә,
Пышылдап тик бер сүз әйтсәнә!
Дөньяга кушылып минем дә,
минем дә
Сөюдән башларым әйләнә,
Сөюдән башларым әйләнә.

Әй, карусель, карусель...

МИНЕМ БАШКАЛАМ*

*(Җыр)*

Ничек итеп аңлатырга икән
Күңелдәге хисләр давылын?
Якты җырым булып йөрәгемдә
Яшисең син, туган авылым.

Кушымта:

Өй түрендә үскән каен белән
Туган йортым минем башлана.
Синдә тудым, синнән илһам алам,
Туган авылым — минем башкалам.

Безнең якны, әй, күрсәгез иде:
Мишә буйларында тал гына.
Мәхәббәтен көткән егет өчен
Кызлар иреннәре бал гына!

Кушымта.

Дөнья сиңа таулар бүләк иткән,
Шунда үтте безнең балачак.
Сөю сүзен әйткән минутларым
Мәңгелеккә истә калачак.

Кушымта.

САБА ЧИШМӘЛӘРЕ*

*(Җыр)*

Синең аваз, синең балкыш булып
Туган якта җырлый чишмәләр.
Тынмый тибә, чыңлый-чыңлый тибә, } 2 тапкыр
Бу йөрәгем, белмим, нишләгән?

Кушымта:

Челтер-челтер Саба чишмәләре,
Җилфер-җилфер Саба җилләре.
Мишәсендә таллар су коена —
Шулдыр минем туган җиркәем.

Саба җиле, диләр, — таң җиле ул,
Туар таңнар саен көт мине.
«Бәхет» дигән сүзнең үзеннән дә } 2 тапкыр
Бәхетлерәк итәрмен сине.

Кушымта.

Мишә тугайлары борма-борма,
Бормаларын булмый турайтып.
Яшик, дуслар, туган ягыбызның } 2 тапкыр
Җирен, күген, данын зурайтып.

## СЕРЛЕ ЙОЛДЫЗ*

*(Җыр)*

Кызларның бар төрлесе,
Йолдыз сыман серлесе.
Йөрәгеңнең тибешләрен
Аңлый алсын тик берсе.

Исемнәрен яза-яза
Кызлар яулык чигәрме?
Матур кәләш сайлап алыр
Үзе кебек чибәрне.

Туй атлары, һай, гайрәтле —
Таптап уза гайбәтне.
Асыл егет сайлап алыр
Үзе кебек һәйбәтне.

Сәлам бирик дус-ишләргә,
Күктәге йолдызларга.
Бәхет телик килен булып
Сәфәр чыккан кызларга!

## СЫЕРЧЫКЛАР КИТКӘНДӘ

Инеш буйлап каен тузы
Китеп бара диңгезгә.
Ап-ак кына сәламнәрен
Әйтеп кала ул безгә.

Һаваларда — кошлар өне,
Кырларда салам исе:
Килешеп тора бу көзгә
Хәтта моңсулык хисе.

Сыерчыкның үз җыры бар,
Ул соң нинди җыр икән?
Сайраганы, сөйләгәне —
Урман микән, кыр микән?

Ни турында сөйләсә дә,
Кабатлый алмас беркем.
Буш кырларны үзе белән —
Алып китәр бу төркем.

Ялан кырның уртасында
Ялгыз бер учак яна.
Әллә инде еллар яна —
Көлләре генә кала...

Күләгәләр, мыштым гына,
(Ничек шулай өлгерә!)
Куак асларыннан чыгып,
Көзгә таба йөгерә!

## АК БАЙРАГЫН ТОТЫП КЫШ ЧАБА

Өр-яңа кыш!
Салкын йолдызларны
Коя буран, чәчә, әй, тарата.
Авылымның сабыр иңнәренә
Төн буена калын карлар ята.

Таңга кадәр буран капчыгыннан
Күпме әкиятләр түгелгәндер;
Тыкрык саен зәңгәр көрт астына
Без эзлисе йолдыз күмелгәндер?

Күз алдымда: кар эченә чумып,
Утырганы авыл йортларының.
Мин беләмен аның һәммәсендә
Яшәү барын, иман, ут барының.

Әйтерсең лә дөнья читлегеннән
Качып чыккан мәҗрүх бер җанвар, —
Иртәләрдән алып кичкә кадәр
Бертоташтан гүләп тора гыйнвар!

Ак байрагын төшермәкче бу кыш:
Кулын селтәгән дә барчасына,
«Парламентер» булып чаба әнә
Килер язларының каршысына...

## ЯШЬЛЕКНЕҢ БЕР КӨНЕ

Күзләреңдә — таң сурәте,
Анда вакыт кабатлана.
Ул керфекләр!.. Әйтерсең лә
Карлыгачлар канат кага.

Күзләреңдә — көн яктысы.
Анда нурлар тулышкандыр.
Сине матур итәр өчен
Бар табигать тырышкандыр.

Күзләреңдә кояш байый,
Нәрсә булды сиңа кинәт?
Ачы сөю тәлгәшләрен
Татыгансың бүген, димәк...

## ҖӘЙГЕ ЧЕЛЛӘ

Утлы дуга сызды кояш,
Туфракка сеңде җылы.
Шаулады галим-голәма:
«...Кояшның актив елы!»

Кайтып төштем дә авылга,
Тукталдым таныш ярда.
Хәл-әхвәлне белешкәндәй,
Кул бирдем арышларга.

Һай көннәрнең кайнарлыгы!
Дөнья кыза, яна күк.
Җәйге чиллә кояшыннан
Утлы тамчы тама күк.

Җир һәм сулар мәмләкәтен
Кыздыра утлы чыраг.
Ярдагы талларга хәтле
Ялвара яңгыр сорап.

Кыр юлында — кайнар тузан,
Аяк төртсәң пешерә...
Гамьсез калу мөмкинме соң
Йөрәге бар кешегә?

Тузанга баткан башаклар,
Күр, ничек әлсерәгән?
Чакырыр идем яңгырны —
Тылсымын белсәм әгәр.

Сусап яткан басуларга
Ничек дәва табасы?
Бәрәкәтле яңгыр булып
Килә күкрәп явасым!

## СОРАУЛАР

Шаккатамын:
Нинди генә көчләр
Элеп куйган күккә Кояшны...
Кемнәр анда чөеп-чәчеп уйный
Метеорит дигән бу ташны?

Күрә белсәң әгәр, көндезен дә
Күреп була, бәлки, йолдызны.
Хыялында яки чынбарлыкта
Кем эзләмәс үзенә тиң кызны.

Төнлә түгел, кайчак кичкырыннан
Тәгәрәпләр чыга Ай шары.
Ялварасың: безне Зөһрә-кыздан
Мәхрүм итә күрмә нибары...

Мәхәббәт ул космик күренешме,
Әллә инде җирдә яралган?
Ак тәнлеләр, кара тәнлеләр дә
Җиде кыйтга буйлап таралган.

Мәхәббәтне сугыш егып салса —
Анда ызгыш, анда багана.
Чәнечкеле тимерчыбык белән
Уратылган безнең замана.

Шаккатамын: шушы илләр чиген,
Рөхсәт-фәлән сорап тормыйча,
Ике яктан да бит болыт агыла,
Канатларын кагып кош оча...

## ВАКЫТ СУРӘТЕ

Җәйләр килсә —
Җиләк пешә
Алсуланып, алланып.
Җәйнең гомере озын диеп,
Яши күрмә алданып.

Көзләр килсә —
Көзге тирли,
Адәмнәр чирли башлый.
Кайларга куясы шулчак
Сагышлар тулы башны?

Кышлар килсә —
Кыштыр-кыштыр
Карлар ява ишелеп.
Яшьлегенме, картлыгынмы
Эзләп бара кешелек?

Язлар, язлар...
Алда — назлар,
Алдагысын кем белгән?
Тәлгәш-тәлгәш булып әнә
Күктә йолдыз өлгергән!

## ИЛАҺИ ЗУРЛЫК

Иделдә йөздердем
Яшьлекнең җилкәнен.
Һәм белдем җилләрнең
Ник тыгыз икәнен.

Туфракка сиптем мин
Мәхәббәт орлыгын.
Һәм тойдым яшәүнең
Илаһи зурлыгын.

## ЯҢГЫР БӘЙРӘМЕ

Җилдә әллә җен гайрәте? —
Толым-толым салынып,
Күкләрдән агылып төшә
Яңгыр... җирне сагынып.

Бу яңгыр минем йөрәккә
Бәрә дә бәрә генә!
Яшенле сурәтләр ясый
Күңелем тәрәзенә.

Кинәнә шифер түбәләр, —
Шаулый барабан булып.
Кабат-кабат яшен уйный
Офыкларны яндырып.

Мин мәхәббәт мизгелләрен
Көткән идем көнозын.
Ниһаять, килдең син миңа
Ерып яңгыр диңгезен!

Тәүлек, бәлки, кыскарактыр,
Тик беләмен: таң озын.
Синең коңгырт күзләреңдә
Мин үземне таныдым...

## ЯНАР УЧАК

Кояш батты, кошлар йоклый инде,
Ә мин һаман янам утларда.
Еракта бер йолдыз бәргәләнә —
Тынгы бирми миңа йокларга.

Хыялымда чыгып китәм шулчак
Бу дөньяның серен эзләргә.
Вакытара кавышу мизгелләре
Кереп тула минем күзләргә.

Таң алдыннан сүнә якты йолдыз,
Нуры кала җиргә коелып.
Үлән-яфракларның кавеме дә
Яшәмәскә тиеш боегып.

Кушучыма алып саклыйсым бар
Җиргә төшкән йолдыз яктысын.
Мә, йөрәкне, яшәү!
Синең офыкта ул
Янар учак булып балкысын...

## АКЧАРЛАКЛАР

*Реквием*

Китмәгез сез, акчарлаклар...
*Рәшит Әхмәтҗан*

Акчарлаклар...
Кеше җаны булып
Офыкларда гүя тирбәлә.
Тормыш кырыс: кинәт бозлар ява,
Көтмәгәндә кайнар җил бәрә.

Яшеннәрне кыеп ала белгән
Акчарлакка — диңгез тубыктан.
Күпме күзләр, күпме фидаилар
Карап тора безгә офыктан.

...Диңгезченең каләм тотулары
Бик табигый иде, табигый.
Кара төндә палач кулларыннан
Авып төште Фаил Шафигый.

Нигә икән әҗәл дигәннәре
Талантларны һаман чамалый?
Шигърияте чәчәк аткан чакта
Сулды кинәт Тәүфыйкъ Камали.

Түзмәдеме тормыш басымына,
Әллә инде шигъри басымга, —
Җилләр генә бары укыдылар
Җеназасын Фәннур Сафинга.

Рәсем-сурәт ясауларга дисәң,
Коеп куйган маһир, оста син.
Кайсы болын чишмәсенә төшеп
Югалдың син, Эдуард Мостафин?

Өстәлендә елап ята әнә
Язылмыйча калган әсәре.
Ялталарга китеп, ялт-йолт итеп,
Күккә ашты Мәхмүт Хәсәнов.

Җырның бугазына басмады ул,
Алга барды һаман юл ишеп.
Мәңгелеккә сагыш сәхнәсендә
Басып калды Хәйдәр Бигичев.

Тыңла, заман, татар егетләрен
Исреклектән, зинһар, айнытсын.
Пычак өсләреннән узып китте
Ир уртасы Хәйдәр Гайнетдин.

...Акчарлаклар китеп баралар да
Язлар саен кабат кайталар.
Офык белән кояш арасында
Иңрәп тора серле кайтаваз.

Акчарлаклар —
Китеп барганнарның
Төсе булып уйный күңелдә.
Бу кошларның гомре үлемсездер,
Акчарлаклар оча Иделдә!

## ТӨЕН

Кайта-кайта
Балачакка кайтам...
Чыр-чу килеп иске буада
Су кергәндә бездән бәхетлерәк
Кемнәр булды икән дөньяда?

Чебиләгән аякларны сөйрәп
Чыктың исә елга буеннан,
Менәтерә! Шалкан тиклем итеп
Күлмәк җиңе... төйнәп куелган.

«Йә, нишләрсең?» Көлемсерәп кенә
Карап тора шаян язмышың.
Теш казнасын ертып-авырттырып
Кимерәсең шулчак «каз ботын».

...Үсеп җиткәч, үзенең кочагына
Суырып алды тормыш дәрьясы.
Шатлыклар да, кырыс кануннар да —
Көтеп кенә торган һәммәсе.

Сукмагыңны, барыр юлларыңны
Төйнәп куя икән бу тормыш!
Вәйран калып, кояшлы як эзләп,
Юл чатында менә утырмыш.

Көннәреңне, хәтта елларыңны
Төйнәп куя тәкъдир тыгызлап.
Өлешеңә тияр көмешеңне
Яулап алу кирәк бугазлап.

Тәсбихемдә — төен арты төен,
Юл сабамын тешне канатып.
Дөньялыкта яшәп ятам шулай,
Матурлыкка фәкать җан атып.

Узып киткән алтын вакытларым
Юк-бар сүзләр кайчак сөйләнеп.
Әйтер сүзләремнең иң татлысы
Тел очында калган төйнәлеп...

## СЫНАЛУ

Хәтеремдә:
Көзге бозлар көзге кебек...
Кырпак карлар бәгыремне өзде кебек.
Чәчрәп кердем шул бозларның уртасына,
Таза дисең, әмма ләкин ул да — сына!

Көзге бозлар, ни әйтсәң дә, чыртлап тора,
Ничә адым атлавыңны чутлап тора.
Аяк асты чатыр-чотыр чәрдәкләнә —
Яшькелт сулар алда әнә көтеп тора.

Язгы сулар хәтеремә төшә минем,
Туган ягым — карлы-бозлы Мишә минем.
Ургып-ургып ташу төшә басулардан,
Калын бозлар сәфәр көтеп тәмам арган.

Балачакның саф акылы хәтерле шул,
Язгы бозлар, ни әйтсәң дә, мәкерле шул:
Ул, пышылдап, кинәт кенә ярыладыр,
Чоңгыл булып чабуыңа сарыладыр.

Тормышның да фасыллары кайнамакта,
Тайгак бозлар безне һаман сынамакта.
Әй, син, язмыш, дөрес итеп атлар өчен
Без бәндәңә мәдәт бирче шундый чакта!

## АЗАТЛЫК ТӘМЕ

Ут һәм кылыч белән куркытканнар:
Көл буласың яки кол буласың...
Шул чакта да югалтмаган халкым
Догасын һәм якты кыйбласын.

Утызынчы август...
Байрак булып
Балкый Татарстан күгендә.
Легендага тиң булырлык көннәр
Истә һаман, истә — күңелдә.

Яңгырады сүзләр: «Азатлыкны
Алыгыз сез күпме телисез».
Татар халкы өчен Азатлык ул —
Мәңге тере, мәңге үлемсез!

Алтын Урда чиста алтын төсле
Яшәп яткан тарих багында.
Алтын сәхифәләр язганбыз ич
Ирекле ил — Болгар чагында.

Демократик җилләр дигән булып,
Заманалар шактый үзгәрде:
Кайберәүләр бутый сәясәттә
Язлар белән кара көзләрне...

Утызынчы август хәзинәсен
Китеп-китеп алган елларда,
Мин һаман да телим Ватанымның
Азатлыгын бары җырларга!

## КҮҢЕЛ ЯШЬЛЕГЕ

*Равил Фәйзуллинга*

Мин дөньядан качып китмәк идем,
Ә ул — качып бара үземнән...
Тәлгәш-тәлгәш энҗе миләш булып
Күз яшьләре ага күземнән.

Нигә, әнкәй, сагышлы җан итеп
Яраткансың мине дөньяга?
Еллар аша карыйм:
Синең ак яулыгың
«Матурлык!» дип, һаман чаң кага!

Кабереңдә — миләш...
Миләш ачылары
Ачыттыра кайчак күңелне.
Без яшәгән саен яшәрәбез,
Әллә картаябыз түгелме?

Кеше булып яшәү җиңел түгел,
Мең кат үләм, мең кат терелә́м:
Яки чәчәк булам буразнада,
Кирәк икән — гади бер үлән.

Кырларымны бик еш сагынамын,
Сагына булыр мине дә күкчәчәк.
Үләм икән, минем белән бергә
Ярты дөнья җирдә үләчәк.

Шундый яратабыз сине, тормыш,
Килми синнән, килми китәсе.
Бар бит әле бәхет капкасыннан
Шаулап-гөрләп бергә үтәсе.

jjj

Араннарда күрдем моңсу атны,
Шомырт кара ялы — катлы-катлы.
Нинди сагыш урап алган аны,
Керфек йомар микән таңга чаклы?

Моңсу кызны күрдем тын бакчада,
Атлап йөрешләре бигрәк садә!
Дидем: шөкрана, югалмас бу
Хәсрәт чоңгылына эләксә дә.

Бакчы моңсу сулар агышына:
Тәңкә-тәңкә төсләр алышына.
Күпме тылсым сыйган —
балыкларның
Суны чупылдаткан тавышына.

Кояш нурлары, әй, бәйрәм итә
Җиһан өстәлендә корып табын.
Күктә таган атына алсу кояш,
Күргәнем юк аның моңсу чагын.

## ОЗАК ЯҢГЫР

Казанымда яңгыр ява,
Күкнең илаһи чагы.
Күк болытлар арасыннан
Яктыра кояш табы.

Күрәсеңме, бәллүр тамчы
Ява урам ташына.
Сагышларын кичке Идел
Ташый синең каршыңа.

Казанымда тагын яңгыр,
Эңгер-меңгер һәм томан.
Айның йөзен бүз пәрәнҗә
Каплап торадыр сыман.

Казанымның күкләрендә
Кояшсыз моң ачысы.
Ә йөрәктә чеңләп тора
Һаман яңгыр тамчысы!

## АВГУСТ УРТАСЫ

Урман юлы ешлык арасына
Кереп чумган йомгак оясыдай.
Бик биектә алтын яфрак оча
Әкияттәге бәхет кошыдай.

Очкын булып оча якты уйлар,
Сәер сагыш җанга чорнала.
Көзнең алтын яфракларын чүеп,
Уйнап йөри гамьсез бер бала.

Бу бит минем ерак балачагым,
Табанында чыклы иртәләр.
Ул килмәсә, кем соң бу талларның
Яшел толымыннан иркәләр?

Балачакта — хыял канатлырак,
Балачакта — уйлар татлырак.
Балачагым каршы алгангамы —
Бүген көзләр, күкләр яктырак!

Бүрек-бүрек учлыйм яфракларны,
Гүя кайнар — кулны пешерә...
Гомер шавын тыңлап карар өчен,
Көзләр дә бит кирәк кешегә.

## ВАКЫТ ДӘРЬЯСЫ

Тыеп булмый вакыт аргамагын —
Җилдерә ул дөнья буйлатып.
Һәйкәлләрнең намын укый-укый,
Илләр гамен йөри уятып.

Елъязмалар чорны яктырталар,
Еллар яна анда, шәм яна.
Чөйязуның серле тамгаларын
Сөртә-сөртә укый замана.

Ничә яшьтә Тарих?
Әйтче, Кояш,
Күкрәгеңә куеп кулыңны:
Син — Вакытның үлмәс яшьтәшеме,
Бабасымы, әллә улымы?

Уклар атып кеше берсен-берсе
Үтерергә күпме теләгән?
Җирдә һаман кара шәүлә йөри —
Ракеталар күкне терәгән.

Ә таллыкта, берни булмагандай,
Су коена әнә коңгызлар.
Мәңгелектән бер кыйпылчык булып
Карап тора безгә йолдызлар.

Яшәешнең алтын хакыйкатен
Эзли вакыт, эзли чаң кагып!
Күктә кояш йөзә — адәмнәрнең
Кылган гамәленә таң калып...

## КҮКТӘН КИТҮ

*Очучы Рәшит ага Ибраһимовка*

Күктән киттем...
Таныш болытларым
Кагылмаслар инде иңемә.
Соңгы самолетның канат җиле
Бөтенләйгә алып кайтты мине
Тәпи атлап киткән Җиремә.

Гаепләргә ашыкма син, дустым,
«Хыянәтче, куркак» бу диеп.
Минем өчен күкнең кануннары,
Мәхәббәтнең тирән тамырлары —
Элеккечә изге һәм бөек.

Яшеннәрне кичкән йөрәгемнең
Күктә калган, ахры, яртысы.
Мин утырткан тупыл очларына,
Штурвалны кыскан учларыма
Килеп куна йолдыз яктысы.

Шау-шу белән дер селкетеп җирнең
Шәһәрләрен, нәфис гөлләрен, —
Минем җанда гүли аэродромнар,
Елый, дәшә алар төннәрен...
Газапланып туа көннәрем.

Таулар җилен җиңмәк булып менә
Чаңгыларга бастым бу кышта.
Канатланып яшәү хасияте
Бирелгәндер безгә тумыштан —
Мин һаман да әле очышта!

## МИНЕМ УРМАНЫМ

Орларында уйный төлке киек,
Имәннәрнең очы, ай-һай, биек:
Чайкалышып торган минутларда
Тиеп-тиеп китә болытларга.

Эләктерәм диеп кояш нурын,
Суза үлән нәни яфракчыгын.
Сыенган да усак кочагына,
Баскан миләш аяк очларына.

Биек абагалар һәм үләннәр
Бер-беренә килеп сөялгәннәр.
Күзгә бәрелеп тормаса да гәрчә —
Яши, сулый монда һәрбер нәрсә.

Син мактаган сазлы әрәмәдә
Бар микән соң чикерткәләр җыры?
Биредәге чыршы төн эченнән
Дүшәмбегә очып чыга туры!

## ДӨНЬЯ УРАМЫНДА УЙЛАНУ

Бар сәгатьләр дөрес йөри бугай,
Камиллеккә дөнья ирешкән.
Берәүне дә рәнҗетмичә генә
Агып ята елга-инешләр.

Дөнья урамына чыктым әле
Язарыма азык табарга.
Үлчәүләр дә кайчак дөрес үлчи —
Кибетләрдә булсын, базарда.

Дивардагы авыр маятниклар

Уңга-сулга дөрес чайкала.
Чал болытлар күпме капламасын,
Күктә кояш барыбер сау кала.

Миллионнар бәхет эзләп әнә
Таптый илнең такыр идәнен.
Менделеев таблицасыдай
Шаулап тора тормыш дигәнең.

Трамвайлар юлдан дөрес бара
Шыгырдатып тимер рельсны.
Ә син, кешем, әйтеп бирче менә:
Кылган эшең — бар да дөресме?

Шахта арты шахта авып төшә,
Шәһәрләрне ташкын су баса.
Нишләр идек, илнең лабазында
МЧСлар әгәр булмаса!

Тагын кайда, нинди шартлау булган?
Бюрократлар, зинһар, азмагыз:
Фәлән кадәр зыян килде, диеп,
Суга сәнәк белән язмагыз...

Төрмә диварлары чалыш әнә,
Чалыш язмыш белән тутыргач.
Терәү арты терәү салыйк әйдә,
Инде килеп эшкә тотынгач.

Илдә бәя күтәрелгән саен,
Дөреслекнең төшә бәясе.
Нинди генә микроүлчәү белән
Үлчәргә соң яшәү мәгънәсен?

Бар да дөрес бара бугай бездә:
Ак-карадан төсләр кабына.
Тик нигә соң дөнья урамында
Хакыйкатьләр ешрак абына?

## ТӘЭССОРАТ

Алма пешә эрмәкләнеп.
Алма кебек кызлар күрсәм,
Телем кала көрмәкләнеп...

*(Эпиграф урынына)*

Җәй уртасы...
Алма бакчасына
Килеп кердем — гади очраклык.
Ни могҗиза: кояш асларында
Кыз-алмагач сынын очраттым.

Нәфистән дә нәфис аяклары
Бил түбәнтен бергә береккән.
Шул ялангач «байлыклары» белән
Басып тора җирдә сылу тән.

Тын бакчада аягүрә килеш
Кояш нурын эчә кыз бала.
Иңнәренә чәче ташып төшкән...
Әрсез күңел, ә син кызма ла!

Күзләр йомык — чиллә кояшына

Мөмкин түгел туры карарга.
Оятымнан минем үземә дә
Туры килде дөрләп янарга.

Күз тимәсен сиңа, «куш-алмагач»,
Йөрмисең ич кеше көлдереп, —
Күкрәгеңдә әнә кемдер өчен
Ике алмаң җиткән өлгереп!

Дәшми генә китеп бардым шулай,
Җанда калды якты истәлек.
...Еллар аша карыйм тын бакчага:
Шул тәэссорат һаман истә ник?
ПАРАДОКС

Менә сиңа табигатьнең галәмәте —
Иркенлектә яшәп ята гавамәте.
Кирәк түгел акча йөртү кесәләрдә,
Бушка килеп тора һәммә нәрсәләр дә:

Көн тудымы — кояш бушка нурын чәчә,
Болыннарда сәлам бирә һәрбер чәчәк.
Саф һаваны тутырып сула үпкәләргә,
Гайрәт иңсен эшләп арган лепкәләргә.

Чишмә ага урман-кырны туендырып,
Яңгыр уза игеннәрне коендырып.
Чикерткәләр эскерипкә кылын тарта,
Гашыйкларның барыр юлын ай яктырта.

Ә тормышта бу хәлләрнең гел киресе —
Адым саен аңкып тора акча исе!
Җиләк-җимеш ашыйм дисәң, бакча кирәк,
Моның өчен, әлбәт инде, акча кирәк.

Күрдең исә алыш-биреш мәгыйшәтен,
Тел очына килә бер сүз: «фагыйләтен...»
Кайберәүләр сатып ала бәхетен дә,
Өч аршынга җитәр-җитмәс ләхетен дә.

Аңгыралар намусын һәм мәнен сата,
Гашрәт сөйгән мәгъшукалар тәнен сата.
Дәрәҗәсен белеп кенә яшел доллар
Каһкаһәләп көлә-көлә түрдә ята.

Ярый, димен, бу шаукымга бирелмимен,
Җир җимертеп эшләр чакта — иренмимен.
Алларымда сикәлтәле юл ятса да,
Ирекләмен — күңелем көр, рухым таза!
БАУМАН УРАМЫ

Иреннәрен кершән белән буяп
Чыкканнар да тулай торагыннан,
Күкрәкләре белән һаваланып,
Кызлар уза Бауман урамыннан.

Атлаулары кылтый-мылтый үзе...
Килештереп вак-вак адымнарын,
Урамдагы гавам ташкынына
Күрсәтәләр итәк-чабуларын.

Ярымачык түшләренә кереп,
Җилнең, ахры, килә ял итәсе.
Урам иңләп, җилләп бара әнә
Бүгенгенең яңа Лолитасы.

Җәйге кафе.
Сыра чатларында
Туздыралар кайсы атай малын?
Беләләрме — бу урамның элек
«Проломная» диеп аталганын...

Кара көннәр...
Шәһәр өсләрендә
Яңгыраган чакта канлы азан,
Телен, җирен, күген саклар өчен
Ут эченә кергән шәһре Казан!

Вакыт усал: тирән катламнарга
Яшереп куйган утлы күмерләрне...
Кем ул Бауман — сорап кара шуны,
Анысын да, ай-һай, белерләрме?

Сай фәлсәфә белән туклаunion:
«Яшәп калыйк дөнья иркен чакта».
Ниләр тутырсаң да ярыйдыр шул
Иске барабандай буш корсакка.

Аңлау кыен: төшеп калган болар
Кайсы гына заман арбасыннан?
Күкрәкләре белән һава чөеп
Атлый кызлар «Казан Арбаты»ннан...

## САЙЛАУ АЛДЫ ТАКМАЗАСЫ

Сайлау үзе шактый кызык нәрсә:
Кем икәнен кемнең белмисең.
Тавышыңны ләкин сал тартмага,
Синең тавыш чөнки — үлемсез!

Бер атнадан, бәлки, өч атнадан
Кемнең кем икәнен күрерсең,
Арысланнан карга килеп чыкса,
Менә шунысы булыр күңелсез...

## ЧИШМӘЧЕ КАРТ

*Сибгат ага Хәкимгә*

Яшь-җилкенчәк карап кала,
Сихерче, дип, тылсымчы.
Ә ул йөри: «Чишмәләрнең
Ташы җырлап торсынчы!»

Ил таңнарын уяу килеш
Каршылау — чын сәгадәт.
Җир-суыңны барлап тору —
Әүвәлдән килгән гадәт.

Чүбен, ташын, балчыкларын
Таяк белән актарып,
Кайтара ул чишмәкәйнең
Җырлап аккан чакларын.

Күзләре дә — чишмә кебек:
Нурлы карый, мөлдерәп.
Бу дөньяда — һәммәбезгә
Кояшлы көннәр кирәк.

«Бер тауда — ун чишмә...» диеп
Җырлады ул халкына.
Туган җиргә мәхәббәте
Кошлар булып талпына!

Офыклардан — еллар ага,
Күзләреннән моң ага...
Ил картлары якты чишмә
Калдыралар дөньяга.

## ӘЙТ СҮЗЕҢНЕ, ЯҢА ПАРЛАМЕНТ!

Мин халкыма үткәннәрдән түгел,
Киләчәктән урын барлыймын.

*Нури Арслан*

Парламентның мәрмәр диварыннан
Эзләмәгез ядрә эзләрен.
Катлы-катлы тәрәзәләр аша
Карап тора Өмет күзләре.

Өметебез мәңге тере безнең,
Өметсез бит — шайтан, дигәннәр.
Вулкан булып, татар катламнары
Кайнап-кайнап чыга тирәннән.

«Бәйсез Татарстан!» дия-дия
Оран салып чапкан чакларда,
Кирәк булган япь-яшь Азатлыкны
Корыч куллар белән сакларга.

Юк, йокламый безнең парламент та,
Туа анда яңа кануннар.
Тик нигә соң аяк-кулларына
Мәскәү тышаулары салынган?

Милләтемә аркан ташлый әнә
Чуардан да чуар Думалар.
Безнең «үрдәк-депутатлар» исә
Арты белән суга чумалар.

Әйтерсең лә кирпеч суга Мәскәү:
Кануннары кыса, шомарта.
«Тәңгәлләшү фарыз...» дигән саен,
Эңгер арта илдә, шом арта.

Булгач булсын: тәңгәлләшик әйдә,
Хокукларда, дәүләтчелектә!
Шовинизм дигән кара елан
Утырмасын сезнең җелектә.

Рәсәй буйлап яңа шәүлә йөри —
Ике башлы козгын шәүләсе.
Тырнак асларында калмасмы соң
Ак барсның елгыр гәүдәсе?

Әле дә шөкер — әләмебез балкый,
Дөбер килә Казан метросы.
Насыйп булсын шуның эргәсенә
Йомарланып кереп утырасы!

Ирек мәйданының өсләрендә
Биеп-уйнап оча карлыгач.
Ядрә сыман ярып бара күкне,
Канатлары шулай пар булгач.

Пар канатлар безнең имгәтелгән,
Сулыш алчы, кардәш, син бераз.
Без очышка әзер түгел икән,
Көтеп тора соңгы инкыйраз.

Парламент һәм иске таш диварлар
Әллә бары — декорация?
Еламсырап басып тора чатта
Ак күлмәкле Декларация...

Алтын чорлар кичкән халкыбызга
Үткәннәрдән урын барламыйк.
Туры Тукай сыман, бар дөньяга
Әйт сүзеңне, яңа Парламент!

## СИН ҺӘМ МИН

Калдырдым да трамвайлар шавын,
Ялгызлыкка бүген ашыгам.
Сары шәлен болгап, тын бакчадан
Көз йөгереп чыга каршыма.

Учларыма сары яфрак ята,
Тоям күктә серле моң барын.
Аһ, алтын көз!
Якын сердәш сыман
Син җилкәмә салдың кулларың.

Әй, сөйгән яр!
Син дә мине шулай
Каршылаган идең бүлмәңдә.
Яфрак төсле учларыңны кыстым,
Бусагаңнан атлап кергәндә.

Катлаулы соң сөю баскычлары:
Анда — шатлык, сагыш, гарасат.
Якты көз бит, беләм,
Синең сыман
Дәшми генә китеп барачак...

## ТУГАН ТЕЛГӘ МӘДХИЯ

Икмәкнең үзе шикелле
Гади син, туган телем.

Идел-йортның михрабында
Нур чәчеп торган көнең.

Үлемсез дастаннар кебек
Моңлы син, туган телем.
Чишмә-чишмә җырлар белән
Мөлдерәп тулган көнең.

Дәверләр аша узгансың,
Син исән, туган телем.
Тукайлар чиккән байракны
Югары тоткан көнең!

## ТӨНГЕ ТАЛПЫНУ

Күзәтәм: күкләрнең түрендә
Тын гына Ай-балык йөзгәнен...
Йолдызлар яшертен үбешә —
Бардыр бит синең дә күргәнең?

Атылган йолдызның эзләре
Акбурдай сызылып калганда,
Нәрсәдер сызылып кала бит
Шул вакыт безнең дә җаннарда!

Әллә соң бу шулай галәмнең,
Кешенең үзара сөйләше?
Миллион чакрымнар эченнән
Кардәшем куя күк эндәшеп.

Таралып китә дә гамьнәрем,
Әйләнеп кайталар кабаттан.
Арышлар исемә төшә дә,
Җирдәге хисләрне яңартам.

## АБЫНУ

Күзләремне текәп бер карасам,
Мин шигырьгә килеп абынам.
Илдә берәр ялгыш җибәрелсә —
Дары кебек дөрләп кабынам!

Нигә һаман бәя күтәрәләр,
Илне күтәрәсе урында?
Салымнарның әллә ничәмәсе
Чиртеп кенә тора борынга.

Чиновниклар чинап симерәләр,
Ә халыкның тишек кесәсе
Җилфер-җилфер килә...
Бу хәлләргә
Син, хакыйкать, ничек түзәсең?

Тукта, каләм! Мондый моң-зарлардан
Тетрәп тора инде һавабыз.
Чөкердәшеп яшәсеннәр, диеп,
Җиргә безне яраткан бит ласа
Адәм белән Хәвабыз.

Ил ялгышса, имеш... Уйлап баксаң,
Үземдә дә хата җитәрлек.
Һәм синдәге хаталарны кушсак,
Башың, бәлки, Себер китәрлек!

Эшчеме син яки депутатмы,
«Тәртип!» диеп чакыру ташларга, —
Астан алып өскә кадәр, димәк,
Үзебездән кирәк башларга.

Күз текәп бер карыймын да кайчак
Матурлыкка килеп абынам.
Ә шулай да илдә хата китсә,
Дары кебек дөрләп кабынам...
jjj

Орлык чәчәм...
Гөлләр урынына
Калкып чыга кайчак кыргый әрем.
Һәр үзгәреш, һәр тирбәлеш саен
Сүз сорыйлар яңа шигырьләрем.

Үкси-үкси елап кала чатта
Бу дөньяның имеш-мимешләре.
Хәсрәт килсә, шигъри тәлгәшемдә
Өлгерәләр кайгы җимешләре.

Өр-яңа бер җыр язмакчы булсам,
Каләмемә килеп куна кояш.
Шатлык иңгән сихри минутларда
Күк гөмбәзен бәреп вата бу баш!

Ялганчылар аяк баскан җирдә
Көн караңгы икән, су болганчык.
Хаклык эзләп мең таш актарасың,
Бармак тиреләрең суелганчы!

Күкрәгемә уклар яуганда да
Дезертирдай артка чигенмәмен.
...Йөрәгемнән кысылып чыккан бит ул
Таң шикелле алсу шигырьләрем.

БЕРЕНЧЕ КӨРТЛӘР

Ноябрьнең кыл уртасы иде,
Ә кыш җиргә карлар йөгерткән.
Йорт-рәшәткә буйларында инде
Балкып тора беренче көртләр.

Кичке тынлык... Эңгер-меңгер иңгән
Авыл читендәге йортларга.
Ай тулышкан чакта кыз балага
Кирәкме соң ятып йокларга?

Утларыңны кабыз, әйдә, кызый,
Карамыйча гайбәт-чүпләргә.
Кеше күләгәсе төшсен әле
Тәрәз каршындагы көртләргә!

Тәрәзәгә якын килә егет,
Капшап карый аның йөзлеген.
Ник дәшми кыз... Грипп котырган чак,
Ята микән әллә өзлегеп?

Көрт эчендә аунар иде егет,

Татлы-уртак сүзләр табылса;
Бер могҗиза булыр иде — әгәр
Бармаклары белән кагылса!

Бу — мин идем. Сине саkладым,
Унсигез яшь, юләр чакларым...

## ЯЛГЫЗЛЫК

*Сиңа*

Үз-үзеңә патша булып
Яшәп кенә ятканда,
Әллә ниткән бер кигәвен
Килеп керә арага.

Бызылдый, аркага куна,
Тынгы бирми уеңа.
Очлы борынын батырып,
Каның белән туена.

Яшертен бер көч җаныңны
Урталай ярып төшә!
Алсу-якты хыялларың
Упкынга барып төшә.

Ашауның тәме китә дә,
Яме китә яшәүнең.
Беркемгә дә кирәкмәс күк
Синең күкрәп яшьнәвең.

Нәрсә бу? Куркып калумы,
Әллә сагыш ташлары
Рухны сындырмак буламы
Кинәт шулай ташланып?

Башымнан сыйпады бугай,
Рәхмәт инде дөньяга, —
Аудым дигәндә, чү, миңа
Бер могҗиза елмая!

Мин керәсе карурманда
Учаклар күп, күрәсең.
Могҗиза булып елмая
Ерактагы сурәтең.

## УЗЫП БАРЫШЛЫЙ

Киндери. Яшел чирәмлек.
Беләкләрен уйнатып,
Бар дөньясын оныткандай,
Керләр элә бер хатын.

Кояшка үрелгән саен
Итәгенә җил бәрә.
Керләре белән гүяки
Уйларын да җилгәрә.

Җәймәләрен ап-ак иткән —
Күпме көчен түккәндер!
Җир шарында басып тора
Кояш белән бермә-бер.

Уйнак-җитез кулларында
Күпме гайрәт бар сыман.
Кирәксә, нәҗес дөньяны
Агартып юар сыман.

Өендә ни: балалары
Караватта тәгәрәп
Ята микән?.. Мәхәббәте
Була күрсен түгәрәк.

Ә ире яшрен ләззәткә
Качырып төрә микән, —
Шундый япь-яшь хатынының
Кадерен белә микән?

Киндери. Яшел чирәмлек.
Китkән идем күз атып,
Ак җилкәндәй җәймәләре
Калды мине озатып...

## ТОРМЫШХАНӘ

Гомер булмаганны, чирләп,
Кердем сырхауханәгә.
Мин бер кеше — әверелдем
Әллә ничә данәгә.

Берсе аның — авырудыр,
Икенчесе — сәламәт.
Үзара, әй, тартышалар,
Карап торсаң, галәмәт.

Тагын берсенә карыйсың —
Коеп куйган пессимист.
Сытык-мытык: әйтерсең лә
Җимерелгән иске мич.

Икенчесен күр син әнә —
Балкып торган оптимист!
Тамчы да зарлана белми:
«Кая килеп каптым ич...»

Бары сөенә: тиздән дип
Терелеп чыгачакмын.
Алда торган киртәләрне
Сугып сындырачакмын.

...Сырхауханәдән чыктым да
Кердем сыраханәгә.
Карыйм: тормыш-яшәештән
Болар хәттин канәгать.

Елмаялар, көлешәләр,
Телләре телгә йокмый.
Берәү хәтта башын куеп
Өстәл өстендә йоклый...

Дидем: фәлсәфә корырга
Мин бик оста, янәсе.
Орып та бирми — үзенчә
Яши Тормышханәсе!

## ҮТКӘННӘРДӘН ИСТӘЛЕК

Куе чәчләрендә синең
Коенган чак бар иде.
Бөтен тылсымнарың белән
Сөеп туймас яр идең!

Күпме еллар үтелгән —
Толымнарың сүтелгән...

Күпме юллар үтелгән —
Алар бар да сүтелгән...

Йолдызлар адашып беткән,
Тоныкланган ае да.
Сүтелгән, ахрысы, безнең
Мәхәббәт сарае да...

## СЫЕРЧЫК ОЯСЫ

Бүрәнәле агач йортның
Түбәсендә, очында
Чут-чут итеп сайрый-сайрый
Бер сыерчык очына!

Хуҗа — балта остасыдыр:
Тактасын мач китереп,
Нинди оя ясап куйган
Көнләшерлек иттереп.

Көнләшә чыпчык: күзләрен
Сыерчык китү белән,
Шул тирәдә кайнашалар
Парлап йә көтү белән.

Егыла чыпчык, сыерчыкның
Каурыена абынып.
Һаман сакау килеш кала
Сыерчыкның оясында
Яшәсә дә ябынып...

## jjj

Рәшә кебек алдавычлар була,
Тормышта да азмы миражлар!
Ялган дигән эреле-ваклы нәрсә
Үрчи бездә кайчак тиражлап.

Дөреслек ул — кайнар бәрәңге күк:
Ташлап булмый, тотсаң — пешерә.
Дөрес яшәү фәнен кабат-кабат
Өйрәтәселәр бар кешегә!

Кемнәр нинди хәлдә калыр икән
Сирень агачыдай талангач...
Бозлар кебек бар да эреп бетә,
Бер хакыйкать кала ялангач.

jjj

Печән чабам. Уйлар ерак китә...
Күңел сагыш белән тулганда,
Мин — яраткан аланыма киләм,
Чишмә исе аңкый урманда.

Тешне сындырырлык суларыннан
Авыз итәм. Битне чайкыймын...
Тоям — агачларның шаулавында
Гасыр моңын, еллар шаукымын.

Фәлсәфи бер уйга баткан сыман,
Абагалар гына тын тора.
Җилләр түгел, корыган агачларны
Еллар авырлыгы сындыра.

Яшәү — гаҗәп серле. Язмыш сиңа
Шундый итеп кайчак тондыра!
Кешеләрне, йомшак кешеләрне
Тормыш авырлыгы сындыра.

## МӘРСИЯ

Вакытсыз киткән җаннарны,
Әй, киләә кайтарасым!

*Харрас Әюп*

Ходай рәхмәт бирсен хатын-кызга:
Эштән бушап тормый куллары.
Таңнан торып, алар эзе белән
Чуарлана ферма юллары.

Өйдә тагын мең мәшәкать көтә,
Кышын — маллар, җәен — чебиләр.
...Офык буйлап кая таба бара
Бәхет күрми калган әниләр?

Шәһре Казан.
Мәчет эргәсендә
Басып тора әби-карчыклар.
Өметләре — сыңар бер сәдака,
Күзләр арган, йөзләр талчыккан.

Окоп казып сугыш елларында
Аяк-куллар чыккан «чебиләп».
...Шәфәкъ буйлап кая таба атлый
Бәхет күрми калган әбиләр?

## КҮЗЛӘРЕМ СИНЕ СӨЯ

*(Җыр)*

Җәйләрдән сине эзләдем,
Син көзләрдә булгансың.
Ике битең — пешкән алма,
Син алмадай тулгансың.

Кушымта:

Күзләрем сине сагына,
Күзләрем сине сөя.
Гомер буе яратырмын,
«Кадерлем» дия-дия.

Көзләрдән эзләдем сине,
Син кышларда булгансың.
Алмадай алсу битеңне
Кар-буранда югансың.

Кушымта.

Кышлардан сине эзләдем,
Син язларда булгансың.
Алмагачның чәчкәседәй
Күңелемә кунгансың.

Кушымта.

# ИКЕ МӨҺАҖИР

*Сәяси поэма*

### *1. Сүзнең башы*

Мәгърифәт — азатлык юлында беренче адым.

*Гаяз Исхакый*

Ни кызганыч: туган туфрагымда
Бер тупыл да үстерә алмадым.

*Назыйм Хикмәт*

Тормыш бит ул чуар калейдоскоп —
Кайда золым, кайда тамаша...
Яшәү серен күбрәк аңлар өчен
Без туганбыз җиргә ләбаса.

Син төрекме, үткен яһүдиме,
Әллә урыс, яки татармы, —
Күкрәк куеп без якларга тиеш
Үзебезнең газиз Ватанны:

Ана сөте белән язылгандыр
Табигатьнең шушы кануны.
Син саналсаң азамат ир булып,
Күрсәт, әйдә, дөрләп януны!

Күтәрелә кемдер Гареп яктан,
Күтәрелә кемдер Шәрыкътан.
Туры Тукай сыман шәхесләргә
Егерменче гасыр зарыккан!

Патшалар һәм кара диктаторлар
Тарих чүплегенә очканда:
— Азатлык! — дип оран сала гавам,
Иманнары шулай кушканга.

Көрәш, ләкин көрәш җиңел түгел,
Язмышларны бүлә урталай.

Синең язмыш белән
«Шаярырга» мөмкин
Ататөрек[1] яки Николай[2].

Шәхесләрне корыч-калкан итеп
Әзерләгән Вакыт, чарлаган.
Көрәшләрнең кыл уртасын сайлап,
Һәммәсенә урын барлаган.

Һәр халыкның асыл егетләре
Дисбе-мәрҗән булып тезелгән.
Нишләтәсең,
Гел кирәкле чакта
Милли тәсбих безнең өзелгән!

Таркатырга ярыймы соң шулай
Мең гасырдан килгән дисбене?
...Ир-егетләр атны иярләгән,
Кулларында — язмыш тезгене.

***2. Чистай зинданы. 1907 ел***

Төрмә, әлбәттә, куркаграк кешеләрне куркытыр өчен, йомшаграк кешеләрне кылган эшләреннән тәүбә кылдыру өчен ясалган.
*Гаяз Исхакый*

Тоткын хәлен тоткын гына белә:
Ялгыз калу — хәтәр бер нәрсә.
Ярый ла бит, шундый чакларыңда
Күршең сиңа
Дивар аша «сәлам» җибәрсә.

Шакып-шакып әллә ниләр сөйли
Күрше камерадан утырдашың.
Тик Исхакый өчен иң кыйммәте
Кәгазь, каләм һәм дә ялгыз башы.

Татар өчен җаны актарыла,
Уйный канда фикер хәрәкәте.
Җай чыктымы, их, язасы килә!
Бу — бердәнбер төрмә бәрәкәте.

Ул бит тоткын — кирәк санасалар,
Төн эчендә бәреп керәләр дә,
Бер сүз өчен аяк-таяк белән
Тотыналар сине типкәләргә.

Һай, бу кяфер, нәкъ кирәксез чакта
Ишек тибеп өскә ябырыла.
Ялтыр очлы винтовкасы белән
Кул тыкмакчы милләт тамырына.

Алар өчен тик бердәнбер ләззәт —
Винтовка һәм пычак кулларында.
Без дә шулай корал тоттырыйкмы
Әллә инде татар улларына?..

Гаҗәеп хәл: төрмә сакчылары
Бар да ямьсез, бар да кызыл күзле.

Менә шушы ямьсез дөньялыкта
Югалтмаска кирәк үзебезне!

Кояшы да юньләп чыкмый аның,
Рәсәй өсләрендә — кара болыт.
Шәм яндырып, ладан бөркеп кенә
Таралырмы мондый караңгылык?

Патша китәр...
Совет килеп җитәр —
Большевиклар көрәш башлаячак.
«Халык дошманы» дип, Тинчуринны,
Бурнашларны кыйнап ташлаячак.

Ә хәзергә — рәшәткәле тәрәз,
Лампа уты — тычкан уты сыман.
Халык күптән уянырга тиеш
Инкыйраздан, гафләт йокысыннан!

Караңгылык пәрдәләрен ертып,
Яктылыкка бары омтылырга.
Ничек итеп яшәү кирәклеген
Күрсәткән бит юкса Алтын Урда!
Яшәгәнбез ләса алтын чорда...

### *3. Истанбул төрмәсе. 1939 ел*

*(Назыйм Хикмәт монологы)*

Йөрәгемнең ярасында,
Чал чәчләрем арасында —
Ватан, ватан...

*Назыйм Хикмәт*

Нишләп соң бу илдә һаман да
Гел төрмә хәлләре?
Азатлык юлында, ахрысы,
Ут көтә бәндәне.

Яратыйк Ватанның һәр гөлен,
Үләнен, туфрагын.
Иректән татлырак, затлырак
Ни-нәрсә бар тагын?
Коммунист булганга гаепләп,
Иректән, хакымнан сөрделәр.
Төрмәсе-зинданы күп күбен,
Тик Ватан бер генә!

Шулай да кадерле Ватаннан,
Әй, килә качасы.
Чит илдә татлыдыр шикелле
Азатлык һәм Ирек һавасы.

Язмышны, тәкъдирне сайладык,
Утларда без хәйран кайнадык.
Алланың бирелгән бүләге —
Хакыйкать кайда соң?

Төрмәләр шулпасын мул итеп
Эчерде замана.
Сынады, бастырды ул безне
Гел утлы табага.

Рәсәйдә ачлык, дип, ул чакта
Кемнәрдер сөйләнде.
Без исә курыкмый ашадык
Ямь-яшел үләнне.

Төрмәләр коймасы яз көне
Бай иде үләнгә.
Икмәкле, хикмәтле Рәсәйне
Бирмиктер үләргә!

Унөч ел төрмәдән төрмәгә
Тоткында йөрдем мин.
СССР — алсу төс икәнен
Ишетеп белдем мин.

Исемем, җисемем тапталган
Болганчык бу илдә
Шатлыклар, куаныч бар микән
Кояшка һәм җилгә?

Сәясәт өченгә, әнкәем,
Җәзалар күп килде.
Догадан догага көн саен
Кабатлыйм исмеңне.

Безнеңчә исемең чук матур,
Әнкәем Җәмилә!
Шулай дип эндәшсәм, күңелгә
Һәрвакыт яз килә.

Күңлемә кадерләп салдым мин
Ватанны һәм Сине.
Кәгазьгә, шигырьгә батканга
Кичерә күр мине...

Төшемдә еш кына мин күрәм
Ут-кызыл миләшне.
Булсаң да син кырыс һәм ачы,
Бир юньле киңәшне!

Тынычмы сәясәт мәйданы,
Кем йөри капкада?
Ни уйлый икән соң кешеләр
Мылтыктан атканда?

Фюрерның яшертен нияте,
Беләбез, һай, яман, —
Тупларын җай гына бора ул
СССРга табан.
Шигърият, азатлык җиленә
Сусадым мин тәмам.
Мин фәкать җыр белән барырмын

СССРга табан.

Илемдә, һай, тынчу, һай, борчу,
Күңелгә бигрәкләр кысандыр.
Мәскәүнең кып-кызыл миләше,
Син мине
Матурлык җиңәр дип ышандыр!

Тупыллар толымын сыйпарга
Вакытны берзаман табармын.
Ә күңел һаман да ашкына
Советка табан гел.

Зинданның бетонлы биленә
Йодрыклап сугармын.
Күңлемнең кошлары һаман да
Очалар югартын.

Кичерә күрче син, әнкәем,
Язмышлар тулгагын.
Улыңның бу фани дөньяда
Ник шагыйрь булганын...

***4. Гаяз Исхакый монологы***

Чит илләргә чыгып киткәч кенә,
Мин милләтче дигән ат алдым.
Туган телне, илне кыскан өчен
Нишләтергә урыс Ватанын?

Туган илдән качып китмәдем мин,
Ирексездән бары сөрелдем.
Ауропаны үз күзләрем белән
Күргәч кенә рухым терелде.

Россиядә шундый тынчу иде,
Туры килде күбрәк туңарга.
Туфрагымны, эчәр суларымны
Ташлап киттем менә шуңарга.

Мин — большевик, коммунист та түгел,
Шуңа күрә читкә сөрделәр.
Хакыйкать ул халык кулында дип,
Әй, ышанып йөрдем мин юләр.

Ир-егеткә мохтаҗ икән милләт —
Бер затка да, тагын мең затка.
Азатлыкка мәйдан эзләп, илне
Ташлап киттем озын-озакка.

Истанбулның өсләрендә болыт,
Казаннарга барып җитәрме...
Йоклап яткан татар улларына
Миннән сәлам нурын илтәрме?

Ишетегез, татар угланнары, —
Дәүләтчелек, диеп чаң кагам.
Кан көрәшле Ватан азатлыгын

Сатып алып булмый акчага.

Бу дөньяны ничек төзәтәсе.
Кяфер явы — яман, куркыныч.
Ярый әле, саклап калган безне
Туган телебез дигән ут-кылыч.

Һаман бер сүз — «Единая...» диеп
Кабатлыйлар, гүя попугай.
Безнең өчен шушы сүзләрдән дә
Хәтәррәк нәрсә юк бугай.

Шовинистны күбрәк белгән саен,
Кояш белән ныграк дуслашам.
Әйтер сүзләремне әйткәч кенә,
Мин дөньялык белән хушлашам...

### *5. Идел белән Урал арасы*

Россия — халыклар төрмәсе.
*В.И.Ленин*

Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле!
*Наҗар Нәҗми*

Кояш асларында
Җәйрәп ята
Идел белән Урал арасы.
Сибелешеп шунда дөнья куган
Кыпчак-болгар-татар баласы.

Бөтенесе безгә кайнашканнар —
Галим, итче, җайдак, узаман.
Бөек Кытай диварына хәтле
Барып җиткән алар берзаман.

Гөр-гөр килеп бердәм яшәгәннәр,
Дер-дер килеп дошман яшәгән.
Тарих битләреннән кан ага да,
Адәм күзләреннән яшь ага.

Чабаталы мужик, көнләшүдән,
«Ах» дигән дә, аннан «вах!» дигән,
Болгар дигән яугирләрнең чөнки
Читегенә хәтле сәхтиян.

Сәүдә юлларына карый-карый,
Билен бөккән Шәрык, Көнбатыш.
Кызыл малың, кәрваннарың булса,
Ефәк Юлы дигән эзгә төш.

Күпме шәһәр, хансарайлар кулда —
Әчтерхан һәм Сембер, Самара...
Күрше илгә күз текәгән саен,
Мәскәүләрнең йоны кабара.

Явыз Иван саранчадай килгән,
Казан ауган, Казан егылган.
«Кол булмагыз!» —

Илнең капкасына
Ятим җилләр килеп сугылган.

Кадаклар һәм дага ясаулардан
Тыеп торган патша фәрманы.
Атны дагалаудан мәхрүм булгач,
Калырмы соң татар дәрманы?

Корылтайлар әзләп, Европаны
Айкап йөри Гаяз Исхакый.
Илдән илгә шулай куа аны
Туган тел һәм гадел сүз хакы.

Шуңа күрә чакыру ташлый Гаяз:
Кирәк милли автономия!
Төрмәләргә түгел, Азатлыкка
Күпме илләр әнә баш ия,
Аягүрә баса Азия.

«Коммунизм» дигән кызыл афәт
Европаны алса бугазлап,
Бергә-бергә канда коеначак
Немец, француз, поляк, югослав.
Идел белән Урал арасы ла,
«Өф-өф» итеп кенә барасы.
Чөкердәшеп шунда яшәсеннәр
Башкорт белән татар баласы.

Идел белән Урал арасы ла,
Гүя ике күзем карасы.
Бәйли-бәйли йөрәк яраларын,
Барасы да безгә барасы.

Вакытында әйтеп калу кирәк,
Күпме фикер үлә югыйсә.
Гаҗәпмени: «Идел-Урал» сүзен,
Байрак итеп,
Мәйданнарга халык түгелсә,
Феникстай кабат терелсә...

### *6. Казан. Ирек мәйданында уйлану*

Империя капкасында — йозак...
*Рәшит Әхмәтҗан*

Исхакыйны Назыйм Хикмәт белән
Куеп карыйм кайчак янәшә.
Назыйм Хикмәт — сәяси бер корбан,
Ә Исхакый —
Туры Тукайга тиң ләбаса!

Милләт өчен утка-суга кереп,
Күпме канаткан ул йөрәген.
Чорналышып, еллар һәм гасырлар
Күтеп торган аның кирәген.

Икесе дә туган илкәенең
Төрмә шулпаларын татыган.
Капма-каршы ике сәясине

Тарих, ахры,
Зур көрәшкә үзе чакырган.

Коммунист һәм антикоммунистлар
Алыш-биреш ясап караган.
Хәзер инде вакыт — икесен дә
Араларга актан, карадан.

Егерменче гасыр уртасында
Мин туганмын...
Менә шул чакта
Назыйм Хикмәт ачлык игълан иткән,
Йөрәк утын ташлап учакка.

Язлар гына түгел, бу дөньяда
Кабатлана бик күп нәрсәләр:
Ачлык игълан итә күпме татар,
Нәрсә булыр —
Арттан мылтык белән бәрсәләр?

Туган телне мәңге саклар өчен,
Тотар өчен илне гөл итеп, —
Бер тамчы да артык сорамыйбыз,
Кирәк бары суверенитет!

Палаткадан кинәт калкып чыга
Трибун шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан.
Эстәрледән — Зәки Зәйнуллиннар,
Калганнары тагын кай яктан?

Бәйрәмова — шактый агарынган,
Рәшит исә шактый ябыккан.
Татар илен саклап калыр өчен,
Алар ярдәм сорый халыктан...

Басып торам Ирек мәйданында.
Ах, йөрәкнең авыртулары!
Утызынчы август көннәредәй
Тыгызланып килә уйларым.

Ул чакларның кайнарлыгы истә:
«Дубинка»лар кисте һаваны,
Ак яулыклы әбиләре белән
Мәйдан тотты татар гавәме.

Кайтардыкмы илнең гасырлардан
Күчә килгән кодрәт-шәүкәтен?
Һаман әле камалышта яши,
Ут эчендә яши дәүләтем.

Җирләр уртак, язмыш уртак, диеп
Сөйләнмәгез, Ходай хакына.
Хәләл малларыбыз һаман әле
Рәсәйнең
Тишек кесәсенә агыла.

Шовинист та бер аңласа икән,
Акылы калган булса әз генә:

Империя упкан халыкларның
Күз яшьләре — милли хәзинә.

Без әйтәбез, дәүләтчелек, диеп,
Алар әйтә, милләтчелек, дип.
Бу Рәсәйнең милли сәясәте
Астан өскә кадәр черек бит.

Азатлыкның татлы икәнлеген
Аңлау кирәк инде, ниһаять.
Кешеләрне илдән, ирегеннән
Мәхрүм итү — иң зур җинаять.

Назыйм Хикмәт «коммунизм» диеп,
Үзенчәрәк шулай саташкан.
Ул бит — шагыйрь! Ул шигырьгә түгел,
Сәясәткә кереп адашкан.

Тоткын чакларында сизгәндер ул
Босфор бугазының тарлыгын.
Белде микән Исхакыйлар өчен
Татар бугазының барлыгын?

Татар исән!
Кирәк түгел ләкин
Бу халыктан «бүки» ясарга,
Бугазына, моңлы җырларына
Күн итекләр белән басарга.

«Урыслашып» бетте самавырлар,
«Урыслашып» бетте каеннар.
Күкрәк терәп милли хисләремне
Яклар өчен минем ваем бар.

Байрак тотып һаман алдан бара,
Оран салып бара Исхакый.
Ирек дигән дәрья кочагында
Аның гомере — түгел кыска көй!

Бумеранг сыман Илгә кайтты,
Кире кайтты безгә әйләнеп.
Яңа гасыр — Ике меңенче ел
Булсын бездә шатлык бәйрәме.

Көл-туфракта, бик еракта калган
Орхон-Енисейлар язмасы.
Бүтән җырны бүген яңгырата
Әрсез магнитофон тасмасы.

Тел югалса — илең югалачак,
Ил югалса, телең үләчәк.
Яңабаштан исән калу өчен
Мәдәт бир син безгә, Киләчәк!

Их, сөйлисе һәм җырлыйсы иде
Бәйсез Татарстан турында.
Танк тавышларын күмә-күмә,
Өмет кайный әле җырымда.

Азатлыкка юллар ярган чакта,
Милли көрәш кыза барган чакта —
Мин нишләргә тиеш?
Син нишләргә тиеш?..

Безнең халык кол булмаска тиеш:
Безнең — миссия бу,
Бу — безнең эш!

**ЭЧТӘЛЕК**

*Энҗе бөртекләрен эзләгәндә* .............

Тормыш трамвае .....................
Кояшка таба .......................
Ялгызлык ........................
Полигонда ........................
Толымнар ........................
Чит җирдә ........................
Буран ...........................
Сабантуйдан моңсу күренеш .............
Мәрсия ..........................
Синең гармуның .....................
Тайлар ..........................
Үз бизәге аның .....................
Зәңгәр шәм ........................
Тол хатын ........................
Көн уртасы ........................
Сабый чакның бер иртәсе ................
Әй, гармуным… .....................
Парадокс .........................
Чаган ...........................
Гомер ...........................
Диңгездә ........................
Телсез ..........................
«Була төрле...» .....................
Егет ............................
Көзге панорама .....................
Музейда .........................
Тетри тайга ........................
«Күктәге ак болыт сыман...» .............
Тополь ..........................
Сөю алмасы .......................
Кич ............................
«Күзләрем аера төсләрне...» ..............
«Тама торгач, нәни тамчы...» .............
Сөюне көткәндә .....................
Таныш түгел кызга ...................
Бирче, дөнья! .......................
«Син миңа күзләр бирдең...» .............
Эзләр ...........................
«Җир — автографлар китабы...» ............
«Мин авылда авырып ятам...» .............
Югалган төн .......................
«Азмы хәсрәтле уйларны...» .............
Идел ...........................
«Мин тауларга күтәреләм...» ..............
«Кададың шашкын йөрәккә...» .............
Вакыт белән бәхәс ....................
«Күз нурларын туфрак белән генә...» .........
Ярулла юкәсе ......................
«Әрәмәдә сәер кош авазы...» ..............
Яңгырларың — яшел дастан ..............
Икәү ...........................
Яра ............................
Авыл карты .......................
Кайта җавап .......................
Татарлык көзгесе ....................
Келәмдәге болан рәсеменә карап… ...........
Куркытылган поши ...................
Уен ............................
Очыш ..........................
Туган авылда очрашу ..................
Серләр эзлим ......................
Кызыл җәй ........................
Мишә буенда уйлану ..................
Һәйкәл янында .....................
Таш өстендә — наратлар ................

Кыяга саллар бәрелгән ................
Ташландык кое ....................
Язлар килә .......................
Сөйлә, урман… .....................
Мәхәббәт фасыллары .................
Кышкы фантазия ...................
«Нинди көчләр сәях җанлы итеп...» .........
Һәйкәл .........................
Елап торган кызны юату ...............
Төнге Казан ......................
Чистартырга! .....................
Кошлар моңы .....................
Шагыйрьне каршылау .................
Оренбур даласында ..................
Хәрби чакны хәтерләү .................
Кайтаваз ........................
Яңгыр астындагы мәхәббәт ..............
Сөембикә манарасы ..................
Сәгать ничә? ......................
Гади бер көн ......................
Кем баласы .......................
Әнкәйгә кайту .....................
«Ике күз биргән табигать…» .............
Кабанны яклап бер сүз ................
Архивта уйлану ....................
Әй, туган җир! .....................
Алмага үрелү ......................
Су астында калган болын җыры ...........
Миләш турында баллада ...............
«Куркынычлы» диеп...» ...............
Чернобыльдән соң ...................
Яшел күзле малай ...................
Себерләрне кичкән азамат ..............
Бүген! .........................
Утызынчы август ...................
Татарстан турында моңсу җыр ............
Ике башлы! ......................
Исәнме, Сабантуй! ...................
Язгы сурәт .......................
Алмагач ........................
Туган як кадере ....................
Төн ...........................
Нишләттең? ......................
Төнге сәфәр ......................
Кояш турында җыр ..................
Син әйттең .......................
Тоткын .........................
Мәхәббәт мәрҗәннәре .................
Синең җавап ......................
Сезгә мәдхия ......................
Илбашына безнең теләкләр ..............
Терекөмеш .......................
Чукындыру ......................
Безнең заман ......................
Кызыл тамчылар ...................
Баш министрга ачык хат ................
Февраль ........................
«Бәгырь катты минем...» ...............
Ай барыбер өстә! ....................
Көтүче сумкасы ....................
Булачак рәссам ....................
Урман кошы ......................
Юксыну ........................
Тупыл мамык очыра ..................
Тамга турында баллада ................
Берәү генә .......................
Язгы тайгак ......................
Иделдә көз .......................

Өр-яңадан! ........................
Сине эзләгәндә ......................
Моңсу халәт ......................
Зиратта килгән уй ....................
Юлаучы .........................
Әнкәй гөлләре ......................
Фатих Кәрим истәлегенә ................
Тәкъдир .........................
Печәнче карт .......................
Болытларың, яңгыр, кай яктан? (*Баллада*) .......
Үзем белән сөйләшү ...................
Кар астында чишмә ...................
Инештә — каурый каләм ................
Яңа гасыр бусагасында .................
Авырган чакта… .....................
Җир кызы бул! .....................
Хуш, югалган ваучерым… ................
Калтырана йолдызлар... ................
Урмандагы бер көнем .................
Үземне камчылау ....................
Магеллан шикелле ....................
Гаҗәпләнү ........................
Мишә буйларыннан манзара .............
Аңлау мөмкин... .....................
Кыска хәтер .......................
Чатыртауга күтәрелү .................
Хакыйкать эзләгәндә .................
Кырда — казлар өне ...................
Уймак сурәтләр .....................
Тузганак .........................
Карусель .........................
Минем башкалам ....................
Саба чишмәләре .....................
Серле йолдыз ......................
Сыерчыклар киткәндә .................
Ак байрагын тотып кыш чаба .............
Яшьлекнең бер көне ...................
Җәйге чиллә .......................
Сораулар .........................
Вакыт сурәте .......................
Илаһи зурлык ......................
Яңгыр бәйрәме ......................
Янар учак ........................
Акчарлаклар .......................
Төен ...........................
Сыналу ..........................
Азатлык тәме .......................
Күңел яшьлеге ......................
«Араннарда күрдем моңсу атны...» ...........
Озак яңгыр ........................
Август уртасы ......................
Вакыт дәрьясы ......................
Күктән китү .......................
Минем урманым .....................
Дөнья урамында уйлану .................
Тәэссорат .........................
Парадокс .........................
Бауман урамы ......................
Сайлау алды такмазасы .................
Чишмәче карт ......................
Әйт сүзеңне, яңа парламент! ..............
Син һәм мин .......................
Туган телгә мәдхия ...................
Төнге талпыну ......................
Абыну ..........................
«Орлык чәчәм...» ....................
Беренче көртләр .....................
Ялгызлык ........................

Узып барышлый ....................
Тормышханә ......................
Үткәннәрдән истәлек .................
Сыерчык оясы .....................
«Рәшә кебек алдавычлар була...» ...........
«Печән чабам. Уйлар ерак китә...» ...........
Мәрсия .........................
Күзләрем сине сөя ...................
Ике мөһаҗир (*Сәяси поэма*) .............

Литературно-художественное издание

Низамиев Рашат Мияссарович

Трамвай жизни

Стихи, поэма

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *А.С.Матвеева*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Г.Х.Сундукова, Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.01.2005.
Форматы 70г90$^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 8,78 + фор. 0,15.
Шартлы буяу-оттиск 9,51. Нәшер-хисап табагы 8,23 + фор. 0,26.
Тиражы 2000 д. Заказ А-17.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail:  tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе. 420066. Казан, Декабристлар ур., 2.